PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№6 (306) – ИЮНЬ 2017

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Татарстанның куәте нидә?

Чит балалар буламы?

Чын классик һәм интеллигент

– ТАЛАНТЛЫ ТАМАШАЧЫ ӨЧЕН УЙНЫЙМ

PRESSA.RU

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Сафа Гәрәев, Ксения Сёмина,
Гадел Хәеров, Фаяз Хуҗин
Фотограф: Ната Смирнова, Юлия Калинина
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Диана Сираҗиева

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-1388

Басарга кул куелды: 21.06.2017

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76

Коммерция директоры урынбасары:
Александр Березовский

Сату бүлеге белгече:
Гөлфия Фәттахова

Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

«ТАТАРСТАН» СЕЗГӘ ЮЛ КҮРСӘТЕРГӘ ӘЗЕР!

Әллә ни ашыкмыйча гына килеп яткан җәйне узып китәргә теләгәндәй, Казаныбызга Конфедерацияләр кубогына меңләгән турист белән җанатар агыла. Алар, әлбәттә, зур футболны карарга өметләнә. Футбол белән беррәттән, Казанны һәм республикабызны да. Татарстанлылар килгән кунакларга һәрвакыт шат, гомумән, кунакчыллык – безнең милли асылыбыз. Республикада яшәүче халыкларның барысы да кунакка килгән һәркемне колач җәеп каршы алырга, йортының түренә чакырырга әзер.

Бу күркәм традицияне дәвам итеп, «Татарстан» да кунаклар өчен махсус сан хәстәрләргә булды – менә дигән мавыктыргыч журнал да, юлкүрсәткеч тә. Казан һәм республика буенча иң кызыклы маршрутлар тупланган биредә. Татарстан районнары һәм авылларының күрми калырга ярамый торган почмакларына кадәр күрсәтелгән. Ә аларда сезне борынгыдан сакланып калган легендалар, риваятьләр, тарихи истәлекләр белән беррәттән, иң тәмле сыйлар да көтеп торачак. Татар халкының ничек яшәгәнен, көнкүрешен, йолаларын күреп-өйрәнеп китәр өчен дә – менә дигән мөмкинлек! Ә инде безнең ризыкларны авыз итеп, тәмам хушлангач, сәяхәткә чыгып, җилләнеп кайтырга да мөмкин. Үткән белән Бүгенге арасындагы сәяхәтләр дә – әкият түгел бездә, чынбарлык…

Озын сүзнең кыскасы, «Татарстан»ны кулга төшерегез дә рәхәтләнеп сәяхәт итегез ватаныбыз буйлап! Без сезне якын итеп, үз итеп сәламлибез – хуш килдегез, рәхим итегез!

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Рассам: Алексей Саврасов. 1872 ел.

ИЮНЬ. БОЛГАР

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Бетмәс-төкәнмәс капитал.
Ни өчен Татарстанга кризис һәм санкцияләр куркыныч түгел

8. Федератив мөнәсәбәтләр.
Россия белән яңа Шартнамәгә кул куелырмы

12. Мөселманча туризм.
Төбәккә 150 миллион хәләл сәяхәтчене ничек китерергә

24. Барыгыз да футболга!
Ни өчен уенны барып карарга кирәк

28. Марафон йөгерешләренә ... макраме белән.
Олимпия чемпионкасы булу серләре

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

36. Ятимнәр.
Республикада балалар йортлары нигә ябыла

44. Тарихка җәяүләп.
Казан урамнары нинди серләрне саклый

48. Тәмлеме? Искиткеч!
Татар сыйларының үзенчәлекләре

52. Эремчектән тәм-томнар.
Корт ясау остасында кунакта

56. Кече Ватан патриотлары.
Чын классик һәм интеллигент

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

62. Тарих битләре.
Идел Болгарында кайсы кала «гаять зур шәһәр» саналган

66. Наил Дунаев.
«Талантлы тамашачы өчен уйныйм»

72. Юлкүрсәткеч.
Республика буйлап сәяхәт

74. Туган төбәк.
Республиканың кайсы шәһәрендә кер юуга багышланган музей бар

90. Безнең киштәдә.
«Бу тарихта минем урыным кайда?»

100. Татар авыллары.
Пычак авылы атамасы кайдан алынган

Банк Казани

Тарифный план «Мобильный Бизнес» для активных предпринимателей

- открытие счёта – бесплатно
- ведение счёта – 3190 руб./мес.
- платёжные поручения – 16 руб.
- бесплатное смс-информирование и «Интернет-клиент»
- все платежи отправляются как срочные
- увеличенный операционный день до 20:00

Бесплатный звонок по России

8 (800) 77-518-77

Подробная информация на сайте: bankofkazan.ru
Лицензия №708 от 27.05.2016 г., ООО КБЭР «Банк Казани». Реклама

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

25.05

Дмитрий Медведев, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе, – КФУ студентлары белән очрашуда:

– Университетыгыз бик танылган, хәзер исә бик зур да. Эреләндерелгән университет булдыру карарын дөрес дип саныйм. Зур, нәкъ менә классик университет. Казан университеты элек тә зур, бөтен илгә билгеле иде, ә хәзер инде аны дөньякүләм дәрәҗәдәге уку йорты дип санарга була.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

13.05

Рональдиньо (Рона́лдо де Асси́с Море́йра), 2002 елда Бразилия җыелма командасы составында футбол буенча дөнья чемпионы, 2004 һәм 2005 елларда ФИФА версиясе буенча дөньяның иң яхшы футболчысы, – Казанда ФИФАның 2017 елгы Конфедерацияләр кубогы паркын ачу тантанасында:

– Казанга килүемә шатмын. Җылы каршы алуыгыз өчен рәхмәт. Сез бик кунакчыл. Казан матур шәһәр, ә монда әле хатын-кызлар да иң чибәрләр. Конфедерацияләр кубогында һәм дөнья чемпионатында чыгыш ясау – сүз белән әйтеп бетерә алмаслык хис-кичерешләр һәм бәхет ул, шуңа күрә мин һәркемне бу бәйрәмгә кушылырга чакырам.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

23.05

Джо Кэзер, Россиядә Германиянең Siemens концерны җитәкчесе, – Казанда очрашу вакытында:

– Киләчәк –альтернатив энергия чыганакларында. Россиянең киң мәйданнары яңадан торгызыла ала торган энергия чыганакларын үстерү потенциалына ия. Безнең өчен Татарстан – җил энергетикасы тармагындагы перспективалы төбәкләр исемлегендә.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстанның куәте **НИДӘ**

Россия белән Шартнамә **НИНДИ** хәлдә

Төбәккә **НИЧЕК** 150 млн хәләл сәяхәтчене китерергә

Футболны **НИ ӨЧЕН** килеп карарга кирәк

PRESSA.RU



ТАТАРСТАННЫҢ КУӘТЕ НИДӘ?

Фото: Сергей Фомин

Гаҗәпләнү – Татарстан җиренә аяк баскан һәркемне нәкъ менә шул хис биләп ала. Монда күп нәрсә шаккатыра. Әйтик, башкала – Казанның архитектурасы үзендә һич ярашмастайны – Мәгърибнең кырыс, төгәл үлчәмнәре белән Шәрыкнең һич көтелмәс купшылыгын берләштерә. Авыллары нык, бай, халкы эшсөяр. Манаралар, кәшәнәләр, костел шпильләре бер-берсе белән ярышмый, ә тулыландыра гына. Төрледән-төрле санкцияләргә карамастан яңа предприятиеләр төзелеп тора. Юллары да Россиянеке түгел кебек.

Һәм шунда ук ачыклыйсы килә башлый: ник болай бу? Башка төбәкләр һәм илләр хыяллана гына алган нәрсәләрнең күбесен ни өчен нәкъ менә Татарстан чынга ашыра? Бу сорауга җавап табарга тырышып, кунаклар бер-бер артлы фаразлар ядудыра. Кемдер республика бик уңай җирдә – Идел белән Чулман очрашкан төбәктә урнашкан дип искә алыр, борын-борыннан монда төрле кәрван юллары кисешкән, янәсе. Кемдер, уйлап та тормастан, бар «гаеп»не нефтькә аударыр, имеш, Татарстанга бу яктан Аллаһы Тәгалә сәгадәт биргән. Ә кемдер исә, хаклыкка төшенергә тырышып, республиканың бүгенге чәчәк атуын борынгы заманнар белән бәйләр. Монда, Европа белән Азия кавышкан җирләр чигендә, гаҗәеп зур чуен казанындагы кебек, үзләрендәге иң яхшы сыйфатларны, белемнәрне берләштереп, моңарчы күренмәгән синергетик нәтиҗәгә ирешү өчен, халыклар, милләтләр, мәдәниятләр очрашкан, бергә керешкән.

Автор:
Сафа Гәрәев

Чал тарихны галимнәргә калдырыйк. Татарстанның куәте, амбицияләре, кызыктыру сәләте – нәкъ менә безнең көннәрдә үзен аеруча ячтырак күрсәтә алган феномен ул.

ҺИЧНӘРСӘ ТУКТАТА АЛМАС ҮСЕШ

Кара алтын байлыгы – Татарстанның көндәшләрдән өстенлеге. Ләкин республиканың елына йөзәр миллион тонна нефть чыгарган вакытлары инде тарихта гына калды. Хәзер Татарстан ел саен җир астыннан 35 миллион тонна чамасы кара алтын чыгара. Бу инде кайчандыр фонтан булып ургылган сыек нефть түгел, хәзер аны җир астыннан өскә күтәрү шактый тырышлык һәм чыгымнар, яңа технологияләр таләп итә. Авыр чыгарыла торган үтә үзле нефть запаслары хәзер гомуми күләмнең 80 процентын диярлек тәшкил итә. Димәк, Татарстан нефтьчеләренең төп бурычы – авыр (үтә үзле) нефть ятмаларын, ә киләчәктә исә сланец нефте ятмаларын (Татарстанда алары да бар) үзләштерү.

Хәер, нефть чыгару күләмен арттыру, эшкәртелмәгән нефтьне сату – икътисад үсешен тизәйткән хәлиткеч булдылар һәм бу әле күптән түгел генә иде, шулай да үткәндә калды. Хәзер Татарстан икътисадның нефть торбасыннан котылып, тагын да нәтиҗәлерәк һәм көндәшлектә өстенрәк булу юлын бөтен илгә күрсәтә. Республикада билгеле бер тәртип белән стратегик максатны тормышка ашыралар, аның асылы исә чималның мөмкин кадәр шушы урында эшкәртелүен тәэмин итүдән гыйбарәт. Фикер сөреше аңлашыла булыр: эшкәртү ул – шушы территориядә кала торган өстәмә бәя, өстәмә салымнар һәм керемнәр, заманча технологияләр һәм яңа эш урыннары дигән сүз.

Билгеләнгән стратегиянең хаклыгы бүгенге катлаулы шартларда сынау узды. Көнбатышның кырыс санкцияләре дә, нефть бәясенең әледән-әле арзанаюы да Татарстанның икътисадый үсешен туктата алмый. Бу исә нигездә нефть химиясе һәм нефть эшкәртү хисабына тәэмин ителә. Татарстанның Премьер-министры Алексей Песошин сүзләренә караганда, бүген «илебездәге барлык синтетик каучукның 45% чамасы, этиленның 50%тан артыграгы, барлык пластикларның 42%ы Татарстанда җитештерелә, һәр өченче автошин да – безнеке».

Татарстандагы хәзерге нефть эшкәртү тармагының төп өстенлеге – 500 гектарга якын мәйдан биләгән ТАНЕКО нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексы, бу – бәхәссез. Белгечләр фикеренчә, әлеге комплекс советлар чорыннан соңгы утыз елда нульдән

«Аммоний» комплексы.

башлап төзелгән иң масштаблы инвестиция һәм сәнәгать объекты булды. Былтыр монда 8,7 млн тонна чимал эшкәртелгән, эшкәртү тирәнлеге уртача 84,6%ны тәшкил иткән, ачык нефть продуктлары чыгышы 77,8%ка җиткән.

ТАНЕКО – «Евро-5» классындагы дизель ягулыгы, югары сыйфатлы авиация ягулыгы, бензин, югары индекслы мотор майлары һәм тагын бик күп башка нәрсәләр ул. Комплексның икенче өлешен сафка бастыру белән нефть эшкәртү куәтләре 14 млн тоннага җитәчәк. Эшкәртү тирәнлеге 95 процентка кадәр артачак, ачык нефть продуктларының чыгышы 90 процент дәрәҗәсенә ирешәчәк. Шунысын да искә алу урынлы: әле моннан биш-ун ел элек кенә илебездәге нефть эшкәртү заводларының һичберсе мондый күрсәткечләр турында хәтта хыяллана да алмый иде.

Татарстан икътисадының диверсификациясе кызу темпларда бара: алты ел эчендә сәнәгать җитештерү күләмендә чимал сегментының өлеше 28,7 процентган 22,5 процентка кадәр кимегән. Эшкәртү секторының өлеше 62,8 проценттан 70,9 процентка кадәр үскән. Татарстанда әзер продукция экспорты күләме эшкәртелмәгән нефть экспорты күләмен инде берничә ел элек үк узып китте.

Ә шул ук вакытта Татарстанда шундый ук күләмле һәм нәтиҗәле яңа проектларны чынга ашыру белән шөгыльләнәләр. Аммиак, метанол һәм карбамид җитештерү буенча ил күләмендә иң зурлардан булган «Аммоний» комплексы бер ел элек сафка басты. «ТАИФ-НК» җәмгыяте авыр калдыкларны тирән эшкәртү комплексы төзелешен төгәлләп килә. Бу комплекста эшкәртү тирәнлеге 98,5%ка кадәр җитәргә тиеш. Ә «Түбән Кама Нефтехим» җәмгыятендә яңа этилен комплексын куллнышка тапшыру елына 1,2 млн тонна эшләп чыгарырга мөмкинлек бирәчәк.

Республика төп капиталга инвестицияләр буенча илдә өченче урында бара. Яңа, заманча җитештерүне җайга салмыйча, гамәлдәге җитештерү куәтләрен даими яңартып тормыйча, яңа технологияләр кертмичә, көндәшлеккә сәләтле булып калуның мөмкин түгеллеген монда бик ачык аңлыйлар.

СТРАТЕГИК МАКСАТЛАРДАГЫ ИКЪТИСАД

Россиянең һәр төбәге диярлек ике яки өч бренд аша бөтен илгә мәгълүм. Татарстан исә моннан чыгарма булып тора. «Татарстанда эшләнгән» мөһере сугылып, Россиядә генә түгел, аннан бик еракларда да дан казанган продукция ике, йә өч исемдә генә түгел, ә йөзләгән! Һәм бу продукция, кагыйдә буларак, мондагы фән һәм сәнәгатьнең чиксез мөмкинлекләрен раслый торган югары технологияләр кулланып эшләнгән.

Россия Президенты карамагындагы иң заманча лайнерларның берсе – Ту-214, илебезнең стратегик авиациясендә төп очкычлар саналган, тавыш тизлегеннән тизрәк очарга сәләтле булган Ту-160 һәм ТУ-22М самолетлары Казанда җитештерелә. Дөньяның йөздән артык илендә кулланыла торган МИ-8, Ми-17 һәм «Ансат» вертолетлары монда җыела. Зәңгәр ягулык кудыру өчен газ-турбина агрегатлары, илебездә йөк машиналары паркының төп өлешен тәшкил иткән һәм Азия, Африка, Латин Америкасының бик күп илләренә озатыла торган «КАМАЗ»лар – болары да Татарстаннан. Яшел Үзәндәге А.М.Горький ис. завод стапельләрендә төзелгән ракета кораблары һәм хәрби фрегатлар илебезнең Хәрби-диңгез флоты составына керә, шулай ук Вьетнамның диңгез чикләрен саклый.

Илебезнең машина төзү заводларының иң зурлары Татарстанда тупланган, шул исәптән автомобиль заводлары да. Әйтик, Алабугада «Форд»лар җыела. Өстәвенә, бу – чит ил машиналарын әзер детальләрдән примитив рәвештә туплап, җыеп куюу гына түгел. Россиядә чыгарыла торган «Форд»ларның детальләре илебезнең 70тән артык предприятиесеннән китерелә, машиналарга шушындагы двигательләр заводында җитештерелә торган моторлар куела.

Россиянең оборона-сәнәгать комплексы составына керә торган өч дистәдән артык предприятие, фәнни-тикшерену институтлары һәм конструкторлык бюролары – республиканың чын горурлыгы. Аларның хезмәт сыйфатын телевизион яңалыкларда шактый еш күрсәтелә торган видеоматериаллар аша бәяли алабыз. Сүриядәге террорчы бандаларның котын алып торган ракета һәм бомбаларның бик төгәл һөҗүмнәре Татарстанда эшләнгән хәрби кораблар һәм стратегик авиациянең бергәләп эш итү нәтиҗәсе ул. Сүриядәге кораллы бандитларга каршы Россия Хәрби-космик көчләренең югары нәтиҗәлелекне тәэмин итә торган пилотсыз очкычлар да Татарстанда уйлап чыгарылган һәм җитештерелгән.

ТАИФ-НК.

PRESSA.RU

Татарстанның машина төзелеше ул – үзенә күрә «идеаль» заманча икътисадның бер моделе. Экспортка йөз тоткан бер яки берничә җитештерү предприятиесе тирәсендә аны тәэмин итә һәм аңа хезмәт күрсәтә торган компанияләр челтәре формалашудан гыйбарәт. Мәсәлән, Чаллы шәһәрендә Россиянең иң зур сәнәгать паркларыннан берсе булган «Мастер» Кама индустриаль паркы эшли, ул үзенең «баш» предприятиесе – «КАМАЗ» белән тыгыз хезмәттәшлек итә. «Мастер» КИП резидентлары – 271 компания, шуларның яртысыннан күбе «КАМАЗ» өчен компонентлар җитештерә.

ДӨНЬЯ ЮГАРЫЛЫГЫНДАГЫ ИНФРАСТРУКТУРА

Халыкара сәяси вазгыять шартларына карамастан, Татарстанга эшмәкәрләр, шул исәптән чит илләрнеке дә, бик теләп килә. Сәбәбе аңлашыла да. Тотылган инвестицияләр кире кайтып, керем китерә башласын өчен, монда бизнес алып барырга барлык шартлар да тудырылган. Моның иң яхшы үрнәге – резидентлар өчен иң камил дип әйтерлек инфраструктура төзелгән «Алабуга» махсус икътисадый зонасы. Нәтиҗәдә республикага өч миллиард долларлык инвестицияләр керде (килешүләрдә каралганы белән – дүрт ярым миллиард).

«Алабуга» махсус икътисадый зонасындагы шартларны резидентлар үзләре ничек бәяли икән соң? «Татарстанда эшмәкәрлек өчен бик шәп мохит!» – дип раслый махсус икътисадый зонага 600 миллион доллардан артык инвестицияләр керткән «Хайат» холдингының идарә рәисе Яхъя Кигылы. ««Алабуга» МИЗ дөнья югарылыгындагы инфраструктура тәкъдим итә һәм ул чыннан да шулай», – дип саный «Форд-Соллерс» ширкәте президенты һәм генераль директоры Мари Овьенден. ««Рокволл Интернешнл» дөньяда җылылык изоляциясе җитештерә торган иң зур заводларның берсен монда төзеде һәм таможня ташламаларында 12,6 миллион доллар акчаны янга калдырды!» – дип ачыклык кертә Рокволл Раша Групп генераль директоры Марина Потокер.

Бүген Татарстан икътисадының гомуми структурасында кече һәм урта эшмәкәрлек предприятиеләре продукциясе 25,6%ны алып тора. Үз эшен ачарга теләүчеләр өчен җитештерү мәйданчыклары тәкъдим ителә, кирәкле документларны туплауда, инженерлык челтәрләренә тоташуда һ.б.ларда булышлык күрсәтелә. Җитештерү мәйданчыгы яки сәнәгать паркы резиденты булгач, эшмәкәр шунда ук эшен башлап җибәреп, продукт җитештерә һәм керем алуга ирешә. Татарстанда эшләп килгән «Мастер» КИП, «Химград» технопаркы, IT-парк һәм тагын муниципаль дәрәҗәдәге 40 сәнәгать мәйданчыгы әлеге принципның нәтиҗәлелеген бик ачык раслый.

1000нән артык компания Татарстандагы сәнәгать паркларының һәм мәйданчыкларының резиденты булып тора. Бу – реаль продукт эшләп чыгара торган реаль сектор. Сәнәгать мәйданчыкларында урын алган резидентларның күбесе полимерлар, авыл хуҗалыгы продукциясе, агач эшкәртү һәм резина һәм пластмасса әйберләр, автокомпонентлар җитештерү тармагында эш алып бара.

ИННОВАЦИЯЛӘР БИШЕГЕ

Кызыклы деталь: төбәктә җитештерелгән продуктларның якынча өч проценты –мәгълүмати-коммуникация технологияләре һәм системалары (уртача алганда, Россиядә бу сан күпкә кимрәк). Татарстанда беренче тапкыр кертелгән күп кенә мәгълүмати проектлар соңрак башка өлкәләрне дә «яулап алды». «Халык контроле» системасы белән әнә шулай булды. Республика документларның ведомствоара электрон әйләнеше системасын керткәндә дә, пионер вазыйфасын үз өстенә йөкләде.

Инновацияләргә, тормышыбызны яхшырта алырлык идеяләрне гамәлгә ашыруга йөз тоткан курс киләчәк елларны күзаллап төзеп куелган. Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр үсеш стратегиясендә «акыллы» икътисадны үстерүдә, яңа материаллар уйлап табу һәм аларны җитештерүне җайга салуда, республиканың дөньякүләм югарылыкта көндәшлеккә сәләтлелеген булдыруда инновацияләргә хәлиткеч роль билгеләнгән. Әлеге күләмле мәсьәләне чишүнең берничә юнәлештә алып барылуы шарт. Аңлашыла ки, яңа технологияләр үзеннән-үзе барлыкка килми – югары квалификацияле яңа кадрлар кирәк, «акыллы» икътисадны нәкъ менә шулар формалаштырырга тиеш. Казан (Идел буе) федераль университеты, А.Н.Туполев ис. Казан милли-тикшеренү техник университеты һәм Казан милли-тикшеренү технология университеты, Иннополис университеты бу кадрларны әзерләү эшенә керешә инде.

Татарстан Республикасы хәзерге көндә үк Россиядә наноиндустрия тармагының алдынгыларыннан санала. Нанотехнологияләр нигезендә җитештерелгән продукциянең еллык күләмен икътисадчылар 40 млрд сумга бәяли. Татарстан нанопродукциясенең яртысыннан артыгы республикадан тыш һәм чит илләрдә кулланыш таба.

Һәм өстәвенә, илебездәге иң уңышлы IT-паркларның берсе Татарстанда эшләп килә. Бу гына да түгел, республикада тулы бер яңа шәһәр – Иннополис калкып чыкты. Аңа нигез салучылар үз алларына искиткеч зур бурыч куйды – шәһәр Россиянең IT-башкаласына әйләнергә, анда иң яхшы инновация ысуллары эшләнеп, тормышка ашырылырга тиеш. Дөресрәге, алар инде эшләнә һәм тормышка да ашырыла. Иннополис – яңача фикер йөртүнең, уку-укытуга, хезмәткә, тормыш рәвешенә яңача карашларның чып-чын чагылышы.

Ә хәзер – иң мөһиме. Миллиардлаган инвестицияләр, гигант төзелешләр, зур күләмле проектлар һәм икътисадтагы структур үзгәртеп корулар, яңа технологияләр һәм эшләнмәләр – болар барысы да, әлбәттә, үзмаксат түгел, ә бер чара гына. Республиканың төп байлыгы нефть тә, галәмәт зур завод-фабрикалар да, авыл хуҗалыгы җирләре дә һәм хәтта алдынгы технологияләр дә түгел. Төп хәзинә – монда тупланган бәһасез кеше капиталы, нәкъ менә шул, гаҗәп колачлы планнарны тормышка ашырып, Татарстанның көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итә. Республикадагы һәр гамәл, һәр эш исә бер максатны – яшәешнең югары сыйфатлылыгына ирешүне күздә тотып башкарыла. ■

«Форд-Соллерс» җитештерүе.



Фото: Ната Смирнова

Казань ✈ Франкфурт-на-Майне

Прямой рейс 2 раза в неделю*

Направление	Номер рейса	Время вылета	Время прилета
Казань – Франкфурт-на-Майне	SU 704	9:50	13:05
Франкфурт-на-Майне – Казань	SU 705	14:20	19:15

THE WORLD'S 4-STAR AIRLINE
Авиакомпания «4 звезды» Скайтракс

6+

Установите приложение:
App Store
Google Play
Скачать

По России бесплатно:
8 (800) 444-5555
*555 МТС, Билайн, Мегафон

www.aeroflot.ru

**Летнее расписание полетов действует с 26.03.17 по 28.10.17. Возможны изменения в расписании полетов. Узнать подробности и купить билеты Вы можете на сайте авиакомпании www.aeroflot.ru, в офисах собственных продаж и у агентов. Реклама. Сертификат эксплуатанта №1 от 17.11.2011. ПАО «Аэрофлот», 119002, Москва, ул. Арбат, д. 10, ОГРН 1027700092661. Реклама.*

PRESSA.RU

ШАРТНАМӘ: АЧЫК СОРАУЛАР

Россия белән Татарстан арасында Шартнамә төзү, мөгаен, XX гасыр РФ тарихына иң зур вакыйгаларның берсе булып кереп калыр. Аның әһәмиятен тарих тагын бер кат раслар әле. Әйе, Татарстан Шартнамә кабул ителгәннән соң яңача яши башлады. Июнь азагында әлеге мөһим документның гамәлдәге вакыты чыга. «Яңа килешү булачакмы? Аны төзү кирәкме?» кебек сораулар көннән-көн ешрак яңгырый.

Автор:
Руфия Фазылова

КАЗАН БЕЛӘН МӘСКӘУ АРАСЫ...

ТР Конституциясендә шундый юллар бар: «Татарстан Республикасы – РФ Конституциясе, ТР Конституциясе һәм «РФ дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе нигезендә РФ белән берләшкән һәм Россия Федерациясе субъекты булган демократик хокукый дәүләт». Аңлашылганча, ТР Конституциясе нәкъ менә Шартнамәгә нигезләнгән.

Беренче Шартнамә 1994 елның 15 февралендә кабул ителгән иде. Безнең кебек яшьрәк буын анык кына хәтерләмидер дә. Бу документны эшләү, кабул итү чын мәгънәсендә тарихи вакыйгага, борылышка тиң була. Шул рәвеш-

ле Татарстан үзенең бәйсезлеген бөтен Россия алдында күрсәтә. 2007 елда икенче Шартнамә кабул ителә, чөнки беренчесе гамәлдән чыга. Дөрес, ул беренчесенә караганда шактый кыска. Димәк, Татарстан өчен мөһим мәсьәләләр дә азрак, дигән сүз. Шулай булса да, ул безгә республика буларак яшәргә, үз Президентыбызны булдырырга ярдәм итте.

Соңгы бер-ике айда Шартнамә турында сүзләр, бәхәсләр еш яңгырый. Дөресен әйтергә кирәк, кайбер Мәскәү сәясәтчеләре Татарстанның үз кануннары буенча яшәвенә каршы. Алар фикеренчә, без Россиянең башка субъектларыннан аерылмыйбыз, димәк, һәммәбез өчен дә бер үк төрле шартлар, кануннар булырга тиеш. Бу очракта «гафу» дип әйтәсе килә: Россиядә 10 донор төбәк бар (ун ел элек кенә бу сан 15 иде), шуларның берсе – Татарстан. Узган ел гына ул Федераль казнага 496 млрд сум акча күчергән. Чагыштыру өчен: 2016 елда аерым программаларга дип республикага 28,4 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Күргәнебезчә, Мәскәүгә киткән акчаның ун проценты да кире кайтмаган. Ә шул ук вакытта Россия составына 2014 елда кушылган Кырымга федераль казнадан 52,7 млрд сум акча күчкән. Ә дотациядә булган ут күршебез – Самара өлкәсенә 17,6 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Юк, бу тырнак астыннан кер эзләү түгел, бу Татарстанның башка төбәкләргә караганда мөстәкыйль, Мәскәүгә «обуза» түгеллеген күрсәтүче меңнән бер мисалы гына.

Яңа Шартнамә булачакмы? Ул безгә нәрсә бирер? Шушы сорауларны танылган сәясәтче-аналитиклар, кайчандыр Шартнамә төзүнең башында торган депутатлар, милләт өчен җан атып йөргән кешеләргә бирдек.

«СҮЗ МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК ТУРЫНДА БАРА»

Марат Галиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе урынбасары:

– Әлеге мәсьәләнең ике ягы бар: хокукый һәм сәяси. Хокукый яктан карасаң, килешү Татарстанга гына түгел, Россиягә дә нәкъ шул ук дәрәҗәдә кирәк. Ни өчен? Россия Конституциясен 1993 елда кабул итү драматик, хәтта кайберәүләр өчен фаҗигале дә күренеш булды. Октябрь аенда Ак йортка һөҗүм ясалды, бу башкарма хакимият белән законнар чыгаручы орган арасындагы конфликт белән бәйле иде. Ул чорда һәркемне бер сорау борчыды: алга таба нишләргә? Һәм менә шушы катлаулы чорда РФ Конституциясе кабул ителде. Аны Россиянең һәр субъекты хупларга тиеш иде. Татарстан ул вакытта тавыш бирмәде. Шуңа күрә безнең халыкның РФ Конституциясе өчен ризалыгы һавада эленеп калды. Ә менә 1994 елның февралендә кабул ителгән Шартнамәдән соң РФ Конституциясе Татарстан өчен дә эшли башлады. Менә шуның өчен дә Шартнамә ике якка да кирәк.

Сәяси яктан Шартнамәнең әһәмияте тагын да зуррак. Татарстан 1992 елда референдум үткәрде. Татарстан үзен Россия составында дип күрде, тик аерым килешү, ягъни Шартнамә нигезендә. Референдумны дөнья күләмендә дә, Россия масштабында да таныйлар. Мисал өчен, Кырым Россиягә кушылганда, Татарстан да бу сәяси сөйләшүгә кушылды, чөнки бездән дә рөхсәт сорадылар.

Икенчедән, безнең тәҗрибәбез бар, һәм без аны Мәскәүгә аермачык күрсәттек: Татарстан Россия составыннан беркая да китмәде. Шушы шартларда әйбәт кенә яшәп ята, ул канәгать.

Яшерен-батырын түгел, Мәскәүнең кайбер сәясәтчеләренә безнең болай яшәвебез ошамый, алар Россиянең һәр субъектын тигез итәргә тели. Тик бер нәрсәне танырга һәм аның белән килешергә кирәк: Шартнамә төзелгәннән соң, Татарстанда, шул исәптән Россиядә дә, сәяси тотрыклылык урнашты. Аңа кадәр бу өлкәдә шактый проблемалар бар иде, монысын да әйбәт беләбез.

Татарстан һәрвакыт күбрәк хокукларга дәгъва кылды. Россиядә 85 субъект бар. Алар үсеш, күләм ягыннан барысы да төрле, тигез түгел. Татарстан СССР заманында ук үзен уңайлы хис итмәде, сәяси статусын үстерү турында сүзләр күп булды: союздаш республикалар дәрәҗәсендә тануларын теләде. РФ составында башка субъектларга бирелгән кебек хокуклар да Татарстанга аз тоелды. Әйткәнемчә, субъектлар төрле. Әгәр син донор икәнсең – сиңа мөнәсәбәт бер төрле, реципиент икәнсең – икенче төрле. Татарстан 1930 нчы еллардан бирле донор санала. Татарстанның икътисадый ихтыяҗларыннан кала, гуманитар ихтыяҗлары да бар. Татарлар Татарстан Республикасында гына яшәми, Россия, чит илләр буенча да сибелгән. Алар белән яхшы мөнәсәбәттә тору өчен аерым шартлар кирәк, ягъни – дәүләт элементлары. Шуңа күрә Татарстан өлкә, төбәк түгел, ә республика. Бу исә – федерация

PRESSA.RU

Россиядә 10 донор төбәк бар (ун ел элек кенә бу сан 15 иде), шуларның берсе – Татарстан. Узган ел гына ул Федераль казнага 496 млрд сум акча күчергән. Чагыштыру өчен: 2016 елда аерым программаларга дип республикага 28,4 млрд сум акча бүлеп бирелгән.

эчендәге дәүләт формасы. Без беркайчан да акча, армиягә дәгъва кылмадык. Без шулай ук гомуми дәүләт кануннары бар икәнен дә аңлыйбыз, мисал өчен салым. Иң зур салым түләүче субъектларның берсе без. Бер ук вакытта әлеге акчаның аерым бер өлешен кире кайтаруны да таләп итәргә хокукыбыз бар, чөнки аерым республика булгач, чыгымнар бик күп. Шуңа күрә федераль бюджеттан акча кайткач, кайберәүләр: «Ни өчен һаман Татарстанга?» – диләр. Ә бит без үзебез түләгән акчаның бер өлешен генә кайтарабыз. Һәм ул акчалар рациональ файдаланыла: яңа сәнәгать объектлары, заманча оешмалар барлыкка килде. Кайберләре хәтта Россиядә дә юк. Шул рәвешле Мәскәүгә үзебезнең булдыклы, күп нәрсәләргә сәләтле икәнебезне күрсәттек. Ә иң мөһиме – теләсә нинди икътисад сәяси тотрыклылык булганда гына үсә ала.

Шартнамә булмаса, нәрсә үзгәрә? Баштарак үзгәреш әллә ни сизелмәячәк. Ә аннан безнең өчен шактый катлаулы чор башланырга мөмкин. Мөстәкыйльлекне югалту турында сүз бара...

Юридик яктан карасаң, икенче мәсьәлә килеп баса: Шартнамәдән тыш, РФ Конституциясе Татарстанда эшләргә тиешме? Без бит РФ Конституциясен кабул иткәндә тавыш бирмәдек. Без аны Шартнамә нигезендә генә кабул итә алабыз...

Аерым сәясәтчеләр Россия унитар дәүләт булырга тиеш, диләр. Әйе, Россия гел унитар булган, дөрес. Тик, әйдәгез, нәтиҗәләргә карыйк. Россия гел каршылыклар белән очраша. Җир шарында Россия кебек зур ил бүтән юк. Бу очракта федерализмнан әйбәтрәк нәрсә юк кебек. Уй-максатлар туры килсә генә, эшләр уңышлы бара. Күреп торабыз: Мәскәү белән Казанның бер-берсенә ихтирамы артты, үзара аңлашу барлыкка килде. Республиканың да дәрәҗәсе артты. Боларны кул белән тотып карап та, акчага сатып алып та булмый. Ә алар бик мөһим күрсәткечләр. Шартнамә Татарстанга, иң беренче чиратта, шушы кыйммәтләрне бирде. Гади генә мисал: төп йорттан аерылып чыккан егет, тиз арада мөстәкыйльгә әйләнеп, матур тормыш кора. Чөнки аның үз-үзенә ышанычы арта, әтисеннән өч сум акча сорауны оныта. Субъект та шулай, мөстәкыйльлек бирсәң, ул зур уңышларга ирешә.

Шартнамәнең киләчәге турында сүз барганда, әлегә төгәл генә бер ни әйтеп булмый. Татарстанның аерым сәясәтчеләре бу эшкә алынды. Тик әлегә Мәскәүгә башлап сүз әйтүче юк. Ә безгә әйтергә кирәк, чөнки Шартнамәнең әһәмияте Татарстан өчен мөһимрәк.



«ТӨП МАКСАТ – САКЛАП КАЛУ»

Индус Таһиров, тарих фәннәре докторы, профессор, сәясәтче, Татарстан Фәннәр академиясе академигы:

– Әлеге Шартнамәне булдыру өчен безгә нык көрәшергә туры килде. 1994 елда ике яклы делегация төзелде. Россия ягы Татарстанга нинди дә булса өстенлекләр бирүгә каршы чыкты. Без исә, уртак проект кабул итеп, мөнәсәбәтләрне ике яклы Шартнамә белән җайлый алдык.

Ул чагында, безгә ияреп, тагын 40 тан артык субъект Россия белән шундый ук Шартнамә төзеде. Ләкин аларның күбесе әлеге килешүләрдән тиз арада баш тартты. Кемнәргәдер «өстәге» көчләр шулай эшләргә кушты, икенчеләре исә үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны башкара алмабыз, дип курыкты. Һәм аларны гаепләп тә булмый. Әлеге Шартнамә субъектларны шактый мөһим вәкаләтләр белән тәэмин итте. Аларны тиешенчә үти белергә дә кирәк бит. Нәтиҗәдә, Татарстан Шартнамәле бердәнбер республика булып калды. Әгәр дә без беренче булып килешү төзегәнбез, әле алай гына да түгел, артыбыздан башка төбәкләрне дә иярткәнбез икән, димәк, Татарстан зур Россияне федератив рельсларга бастырган, дигән сүз.

2007 елның июнендә Россия Президенты В.В. Путин тарафыннан икенче Шартнамә имзаланды. Әлеге документ әзер булгач, аны Россиянең ике палатасы да җентекләп тикшерде. Шартнамә Дәүләт Думасында үтте, ә Федерация Советында үткәргән вакытта Сергей Миронов теше-тырнагы белән каршы чакты. Кызганыч, аңа башка депутатлар да кушылды. Ләкин без бу мәсьәләне өр-яңадан күтәрдек. Биредә М.Ш. Шәймиевнең йогынтысы аеруча зур булды. Ул Владимир Путин белән элемтәгә кереп, мәсьәләгә ачыклык кертте. Документны Федерация Советы аша яңадан үткәреп, өр-яңа Шартнамә барлыкка килде. Ике Шартнамәне чагыштырсак, күренә: әлбәттә, без күп кенә мәсьәләләр буенча артка чигенергә мәҗбүр булдык. Безнең махсус статуста булуыбыз күпләргә ошамады, билгеле. Соңгы вакытта бу сүзләр тагын да кискенрәк яңгырый башлады. Мәсәлән, күптән түгел генә Владимир Жириновский: «Ике якның мөнәсәбәтләрен билгели

торган пунктлар Конституциядә бар инде», – дип белдерде. Чынлыкта: «Россия Конституциясендә субъектлар Үзәк белән федератив шартнамә нигезендә яки башка килешү аша яшәргә тиеш», – диелгән. Без федератив килешүдән баш тарттык, кул куймадык. Нәкъ менә шуңа күрә 1994 елның 15 февраль Шартнамәсе барлыкка килде дә инде.

Бүген безнең төп максат – Шартнамәне саклап калу. Беренчедән, ул Россияне федератив дәүләт итү өчен кирәк. Әгәр дә хәзер шушы Шартнамәбезне юк итәләр икән, Россия формаль рәвештә федерация булып кала алмаячак, дигән сүз. Ник дигәндә, федерациянең нигезе – нәкъ менә шартнамәлелек. Икенчедән, Татарстан башка төбәкләр өчен һәрвакыт үрнәк ролен үти, социаль-икътисадый яктан үсә, камилләшә. Бик зур кризис чорларында да республика үзенең ныклыгын югалтмый. Киресенчә, үзенең бердәмлеген, яшәү көчен күрсәтә. Биредә нәкъ менә әлеге Шартнамә зур роль уйный да.

Татарстан һәм Россия арасындагы икенче Шартнамәгә 2007 елда РФ Президенты Владимир Путинның сәяси хуплавы нәтиҗәсендә кул куелды.

«ВАКЫТ БЕЛӘН ЧИКЛӘНМӘГӘН ИДЕ...»

Фәрит Зәкиев, Бөтентатар иҗтимагый үзәге рәисе:

– Шартнамәне озайту буламы, дигән сүзләр дөрес түгел, бу Конституциягә каршы килә. 1994 елда кабул ителгән беренче Шартнамә 1992 елның 21 мартында үткәрелгән референдумга нигезләнде. Беренче Шартнамәдә чын федератив дәүләт принциплары гамәлгә кергән иде. Мисал өчен, хәзер Татарстанның бөтен табышының 80–85 проценты Мәскәүгә китеп бара, ә 1994 елда Татарстан үз табышының яртысын үзендә калдырырга теләде. Әмма ләкин 2000 елда, унитар дәүләткә кайту гамәлләре башлангач, Шартнамәнең асылы үзгәрде. Югыйсә ул вакыт белән чикләнмәгән, ягъни документ ничек расланган, шулай эшләргә тиеш иде.

РФ Президенты исеменә 30 май көнне хат юлладык. Анда без Мәскәү белән Казан арасында Шартнамә төзүнең мөһимлеген ассызыкладык. Шулай ук кайбер мөһим таләпләрне аерып күрсәттек: милли белем бирү системасы булдыру, бер каналлы салым җыюны тормышка ашыру, Милли банк булдыру, Президент статусын саклап калу һ.б. Президент Аппаратыннан: «Хатыгыз караладак», – дигән җавап хаты килде. Күңелдә ышаныч уянды.

«ФЕДЕРАЛИЗМНЫҢ ФУНДАМЕНТЫ»

Максим Шевченко, Россия Президенты каршындагы Ватандашлык җәмгыятен үстерү һәм кеше хокуклары шурасы әгъзасы:

– Татарстан белән Мәскәү арасындагы Шартнамә, федерализмның фундаменты булып тора. Документны сакларга кирәк, чөнки шуның нигезендә республика һәм Россия зур уңышларга иреште. Бу зур низаглы мәсьәләләрдән качарга ярдәм итте, икътисадны көчәйтте. Ул Татарстанның гына түгел, Россиянең дә үсешенә булыша. Шуңа да, мин бу Шартнамә барлык нечкәлекләренә кадәр сакланып, озайтылырга тиеш, дип саныйм. Шул исәптән президент институты да сакланырга тиеш. Алтын йомырка китерүче тавыкка тияргә ярамый.

...Яңа Шартнамә төзеләчәкме? Дөресен әйтергә кирәк, бу сорауга анык кына җавап әлегә юк. Югыйсә Шартнамәнең вакыты чыкты дисәк тә була. РФ Дәүләт Думасы депутаты Олег Морозовка шушы сорауны юллаган идек. Кызганыч, җавапны көтеп җиткереп булмады. Шулай да бу хакта аның фикерен белдек. Июнь аенда, депутат Казанга килгән иде. Журналистларның: «Яңа Шартнамә кабул ителәчәкме?» – дигән соравына Олег Викторович түбәндәгечә җавап бирде:

– Югары даирәдә бу хакта сөйләшүләр барамы-юкмы, төгәл генә әйтә алмыйм. Минем фикергә килгәндә, Шартнамәнең 10 ел элек булган кебек әһәмиятен күрмим. Ул вакытта субъектлар арасында аерым кануннар юк иде. Бүген исә барысы да рәсмиләштерелгән. Россиянең хәзерге халәтендә Шартнамәнең әллә ни зур ролен күрмим. Тик аның булуында да проблема юк дип уйлыйм. ■

PRESSA.RU

Фото: tatarstan.ru

ХӘЛӘЛ ҺӘМ АНЫҢ СТАНДАРТЛАРЫ

Россия һәм Татарстан буенча сәяхәт итүче хәләл туристка нәрсә җитми? Мөселман илләреннән кунаклар күбрәк килсен өчен нишләргә? Бу сораулар майда Россия һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы (ИХО) илләренең KAZANSUMMIT – 2017 IX Халыкара икътисадый саммиты кысаларында үткән «Хәләл туризм: статус-кво һәм киләчәккә караш» тематик сессиясендә катнашучылар һәм спикерлар арасында кызу бәхәс куптарды.



Автор:
Ксения Сёмина

МӨСЕЛМАННАР ДӨНЬЯ КҮРЕРГӘ ӘЗЕРЛӘНӘ

Конференциядә катнашучылар әйткән бөтен тезисларны берләштерсәң, якынча мондый картина күз алдына килә: мөселман илләре туристлары Россиягә һәм Татарстанга сәяхәт белән кызыксына. Әмма бу агым, булган потенциалны һәм, беренче чиратта, халыкара агентлыкларның мөселман туристлык базары үсеше фаразларын исәпкә алганда, хәлдән килгәннән әкренрәк үсә.

Мәсәлән, MasterCard компаниясе үзенең еллык хисабында* теркәгән: 2015 елдан бирле хәләл туризм базары бик тиз үсә. Һәм кыю фараз бирә: мөселман туристлары саны 2015 елда 117 миллион булса, 2020 елга 168 миллионга җитәчәк. Хәләл туристлар дөнья туристлык агымының 11 процентын тәшкил итә, ягъни бу туристлык базары гомуми күләменнән якынча 200 миллиард доллар, дигән сүз.

Конференциядә 2016 елда Россиядә булып киткән мөселман туристларының саны турында мәгълүмат ишетелмәде. Әмма Татарстанда, мәсәлән, республика туристлык комитеты мәгълүматлары буенча былтыр Төркиядән генә дә 13,5 мең кунак ял иткән. Моннан тыш, визасыз мөнәсәбәтләр үсеше фонында Иран туристлар чыганагына әйләнеп бара. Былтыр Россия Федерациясендә бу илдән килгән кунаклар саны 62 процентка арткан.

Шул ук вакытта, MasterCard бастырып чыгарган еллык Global Muslim Travel Index (Мөселманнар сәяхәте халыкара индексы) рейтингыннан күренгәнчә, 2016 ел нәтиҗәләре буенча Россия мөселман туристлары аеруча үз итә

* Global Muslim Travel Index (Мөселманнар сәяхәте халыкара индексы)

> **“ – Кызганыч, бүген хәләл хезмәт күрсәтүләрнең статусы турында мәгълүмат җитәрлек түгел. Ә кайбер төбәкләрдә – бөтенләй юк.**

торган илләр арасында 49 нчы урынга куелган (45,1 балл), Кытайны бер позициягә артта калдырган (50 нче урын, 44,5 балл).

ИҢ МӨҺИМЕ – ДУСЛЫК

Туристлык өлкәсендәге дәүләт учреждениеләре вәкилләре әлеге контексттагы иң мөһим бурычларның берсе дип Россиянең һәм, аерым алганда, Татарстанның хәләл туристларны кабул итәргә әзер юнәлешләр сыйфатында дөньяда танылучанлыгын арттыруны саный.

– Кызганыч, бүген хәләл хезмәт күрсәтүләрнең статусы турында мәгълүмат җитәрлек түгел. Ә кайбер төбәкләрдә – бөтенләй юк. Билгеле, бу без актив шөгыльләнергә тиешле мөһим бурыч, – дип белдерде үзенең саммиттагы чыгышында Туристлык буенча федераль агентлык җитәкчесенең урынбасары Николай Королев. Аннары ул «Ростуризм» каршындагы координация советының Россия төбәкләрен халыкара базарда танытачак типлаштырылган төбәк маркетинг стратегиясен эшләвен хәбәр итте. Совет шулай ук «Рус кунакчыллыгы» проектын үстерү өстендә дә эшли, аңа «Halal Friendly» («Дустанә хәләл») дә интеграцияләнәчәк.

Аерым алганда, «Дустанә хәләл стандарты» ирекле сертификатлаштыру программасы Россия һәм шул исәптән Татарстан тәкъдимнәрен мөселман илләренең туристлык базарларында таныту максатларында эшләнгән.

ИКМӘК TӘ, РУХ ТА

Хәләл турист күзаллавында идеаль отель нинди соң? Һәм ватаныбызның кунакханә операторлары әлеге теләкләрне ни дәрәҗәдә үтәргә сәләтле?

Мәсәлән, Amadeus халыкара агентлыгы яшәү урыннарына хәләл таләпләрнең шартлы рәвештә өч категориягә бүленүен күрсәтә: мәҗбүри (хәләл туклану һәм гыйбадәт урыннары), кирәкле (тәһарәт алу мөмкинлеге булган уңайлы бүлмәләр һәм ураза тотучылар өчен сервислар), һәм туристлар рәхәт бонус буларак кабул итә торган (хәрам «активлыклары» булмау, вакытны сыйфатлы үткәрү өчен мөмкинлекләр һәм шәригать рөхсәт иткән башка хезмәтләр булу).

MasterCard хисабыннан күренгәнчә, иң югары бәяне Россиянең сәяхәт иминлеген тәэмин итү белән бәйле сервислары, иң түбән бәяне – урнаштыру объектлары тәкъдим иткән мөмкинлекләр алган. Amadeus әлеге категориягә челтәрле кунакханә/апартаментларда урнаштыру мөмкинлеген, «мәдәни комфорт» булуын (намаз бүлмәләре, туклану өчен шартларны) һәм хатын-кызлар өчен уңайлылыкны (үзләре теләгәнчә ял итә алу мөмкинлеген) кертә. «Урнаштыру» өчен Россиягә 100 баллдан 20 балл бирелүе хәлнең никадәр аяныч булуын күрсәтеп тора.

«Halal Friendly» («Дустанә хәләл») сертификатлаштыру критерийлары әлеге таләпләрнең мәҗбүри җыелмасына тулысынча тәңгәл килә. Аны алу өчен, кунакханәдәге номерларда алкогольле эчемлекләр (мини-барлар) булмаска, намаз укырлык иркен урын һәм намазлык булырга, Кыйбланың кайсы якта булуы күрсәтелергә, сурәт, сыннар, тереклек ияләре төшерелгән символлар булмаска тиеш. Номердагы санузел госел коенырлык һәм тәһарәт алырлык булырга (гигиеник душ, биде, алар булмаганда – комган) тиеш.

КЫТАЙ ИСЛАМЫ

Бер караганда, бернинди гайре табигый нәрсәләр юк кебек, әмма Россиядә хәләл сертификаты алган кунакханә операторлары берничә дистәләп кенә. Татарстанда «Дустанә хәләл стандарты» программасы буенча гамәлдәге сертификатлар бары тик Korston Hotel & Mall Kazan һәм Relita-Kazan Hotel кунакханәләрендә генә бар.

– Сертификат алу кунакханәдән бераз чыгымнар таләп итә. Намазлыклар сатып алырга, кунакханә номеры санузелларына

PRESSA.RU

тәһарәт алу өчен биде яки комган куярга, мини-барлардан алкогольне алырга, намаз уку бүлмәсен булдырырга, сертификатның үзе өчен түләргә («Дустанә хәләл стандарты» кысаларында – 45–60 мең сум тирәсе – ред.иск.) һәм аны ел саен кабат раслатырга кирәк. Әлбәттә, болар зур сумма һәм катлаулы шартлар түгел, әмма һәрхәлдә отельер үзенең моны ни өчен эшләгәнен һәм киләчәктә нинди файда күрәсен аңларга тиеш, – ди «Релита-Казан» отеле идарәчесе,

Казан һәм ТР кунакханәләр ассоциациясе президенты Гөлнара Сафина. – Чыннан да, безнең кунакханәдә номерлар буш тормый, һәм монда кунакханә комплексының яхшы үсештәге инфраструктурасы да, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты да, факторлар бергәлеге дә зур роль уйный: кунакханә 4 йолдыз категориясенә классификацияне уңышлы үтте, Бизнес-туризм ассоциациясе тарафыннан бизнес-һәм конференц-отель буларак аттестацияләнде. Без Казанда һәм Татарстанда беренче буларак Кытай туристлары өчен «Чайна френдли» һәм мөселман туристлары өчен «Дустанә хәләл» программалары буенча сертификатлаштыру үттек. Әлеге факторлар бөтенесе бергә кунакханәнең Казанда һәм Россиядә танылу драйверларының берсе булды. Әмма без, гәрчә туристлык базарының бу юнәлешенең зур перспективаларын күрсәк тә, хәзергә мөселман илләре туристларының артык ихтыяҗын һәм кызыксынуын тоймыйбыз. Кайвакыт исә хәләл стандарты буенча тудырылган шартлар көтмәгәндә кирәкле булып чыга. Әйтик, без күптән түгел Кытайдан туристларның зур төркемен каршыладык. Аларның күпчелеге ислам динендәге Өремчедән булып чыкты.

СЕРТИФИКАТЛАШТЫРУ ПАРАДОКСЛАРЫ

Гөлнара Сафина әйтүенчә, аның күп кенә коллегалары өчен сертификат алу яки аның вакытын озайту мәсьәләсе ачык булып кала.

– Без «Дустанә хәләл» таләпләрен үтәдек һәм мөселман туристлары өчен уңайлы шартлар тудырдык. Хәләл номерларын без аерым катта урнаштырдык. Бүлмәләрдән мини-барларны һәм кеше яки хайван сурәтләнгән картиналарны алдык. Андый туристлар килгәндә, без аларны хәләл ризык белән тәэмин итәбез. Безнең хәләл ризыклар өчен аерым суыткычыбыз, хәләл меню ризыкларын әзерләү өчен аерым савыт-саба, җайланмаларыбыз бар. Казанда тагын берничә кунакханә хәләл программасы буенча сертификатлаштыру үткән иде, әмма алар, хәзергә ихтыяҗ булмаганга, аны озайту зарурлыгын күрми, – ди Гөлнара Сафина.

– «Чайна френдли» проектын үстерүгә 15 елга якын вакыт китте. Безнең проектка әле икенче

ел гына, – ди, Россия Рестораторлар һәм отельерлар федерациясе вице-президенты, «Дустанә хәләл стандарты» программасы җитәкчесе Илдар Мусин. – Әле соңгы берничә елда гына Россиядә хәләл продуктлар барлыгы турында сөйли башладылар. Ә алардан башка рестораннар да, кунакханәдә туклану да була алмый.

Ихтимал, хәләл сертификатлаштыруы программасына ихтыяҗ юклыгы аны гамәлгә кертүче органнарның күпсанлы һәм таркау булуыннандыр. Әй-

тик, Россия кунакханәләрендә хәләл стандартларын гамәлгә кертү проектын «Дустанә хәләл» белән берләштерү проектына бирде. Беррәттән былтыр Россия Мөфтиләр советының «Хәләл» Халыкара стандартлаштыру һәм сертификатлаштыру үзәге дә башлап җибәргән.

– Россиядә хәләл кунакханәләр броньлау интернет системаларының берсендә безнең сертификатны алудан баш тарттылар һәм аларның үзләренең хәләл сертификатлаштыруын үтүне таләп иттеләр. Шунлыктан, миңа калса, бердәм хәләл стандарты системасын булдыру зарур, – ди Гөлнара Сафина.

– «Рус кунакчыллыгы» – федераль программа. Аның программалары буенча сертификатлаштыруга җавап бирүче экспертлар Россия законнарының бу тармактагы таләпләренә җавап бирә, бу исә башка органнарда һәрвакытта да күзәтелми. Әлбәттә, турист мондый нечкәлекләрне белмәскә дә мөмкин, ә менә кунакханә хуҗасына, уңайсыз хәлдә калмас өчен, барысына да төшенү мөһим, – ди Илдар Мусин. – Моннан тыш, «Ростуризм» да, Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты да «Рус кунакчыллыгы» проектын төрле халыкара чараларда һәм форумнарда танытуны үзләренең мөһим бурычларыннан берсе итеп күрә.

«Росстандарт» техник көйләү һәм метрология федераль агентлыгы җитәкчесе Антон Шалаев сессияләрнең берсендә хәләл сертификатларының төрлелеге проблемасын күтәргән иде. Россиядәге хәләл продукция һәм хезмәтләр өлкәсендәге 12 төрле ирекле сертификатлаштыру системасы эшендә төрлечә укылышларны булдырмас өчен, ул ике конструктив вариант тәкъдим итә.

Беренчесе – Россия хокук кырында «Росстандарт» куллануырга рөхсәт иткән гамәлдәге халыкара яки чит ил стандартларын берләштереп, үрнәк итеп алу. Икенче вариант – Россиядә үз милли Дәүләт стандартын (ГОСТ) булдыру.

Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Стандартлар һәм метрология институты генераль секретаре Ихсан Овют та шулайрак уйлый:

– Мин, милли стандартлаштыру органнары раслаган хәләл стандартлары гына ориентир булырга тиеш, дип саныйм, – дип белдерде ул саммит чараларының берсендә.

Рамил Мифтахов, Татарстан Республикасы Туристлык агентлыклары ассоциациясе президенты:

– Татарстан ИХО илләре белән актив хезмәттәшлек итә. Сезон саен без Әнкара, Истанбул, Бохарадан 12 ләп төркемне кабул итәбез. Шунлыктан мин хәләл туризм юнәлешен үстерүне бик перспективалы саныйм. Әмма биредә, минемчә, нинди дер бер генә нәрсәдә тукталу кирәкми. Мәсәлән, кунакханәләр санын арттыру турында сөйләргә кирәк. Менә без 0,1% «сәяхәтче мөселманны», 100 меңгә якын кешене җәлеп иттек ди. Кая урнаштырырбыз без аларны? Моннан тыш, кайбер уңайлы, шул исәптән челтәрле отельләрдә, хәләл туклану мәсьәләсе хәл ителмәгән. Әйе, бездә үзебезнең төркемнәрне тукландырганда проблемалар килеп чыкмый, әмма бу бит ставка ясалган агым түгел. Ниһаять, инфраструктураның гомуми дәрәҗәсен күтәрү турында да сөйләргә кирәк, чөнки хәләл, беренче чиратта, тәкъдим ителә торган продуктның сыйфатын күздә тота. Мәсәлән, безнең кайбер тәкъдимнәребез – шул ук «Свияжские холмы» ял йорты – Дубайдагы халыкара күргәзмәдә мөселман туроператорларының игътибарын җәлеп итте. Алар, безгә килеп, күзәтеп-карап китте, һәм бу яхшы нәтиҗә бирер, дип уйлыйм. Шул ук вакытта безнең бик гади кебек тоелган әйберләребез җитешми. Мәсәлән, хәзер республикада гарәпчәдән тәрҗемәчеләр кытлыгы сизелә. Мин инде фарсы теле турында әйтеп тә тормыйм, ә бит без Ираннан туристлар агыла башлавына да өметләнәбез...

PRESSA.RU

ИЮНЬ ▸ ТАТАРСТАН ▸ РЕКЛАМА ▸ 222-09-76 ▸▸

«ТАТМЕЛИОРАЦИЯ»:
НЫКЛЫ ТРАДИЦИЯЛӘР, ТУКТАУСЫЗ ҮСЕШ

«Казан сугару техникасы заводы» ҖЧҖ генераль директоры Рамил Идрисов республика мелиораторларының уңыш нигезләре турында сөйли.

– Республика «Татмелиорация» системасына 95 яшь тула. Республика мелиораторлары үз традицияләренә сакчыл карый, әмма бу системаның туктаусыз камилләшүенә дә комачауламый. Динамик үсештәге «Татмелиорация» 40 предприятие һәм оешманы берләштерә, безнең завод та – шулар исәбендә.

1999 елның августыннан «Татмелиорация» Траст компаниясе» ААҖгә Әнвәр Залаков җитәкчелек итә. «Татмелиорация»нең бүген бердәм, зур һәм нәтиҗәле команда булуы – аның хезмәтенә объектив бәя булып тора. Компания белгечләренең компетенциясендә – агросәнәгать секторына салынган ныклы нигез, авыл җитештерүенең рентабельлелеге һәм тотрыклылыгы, гидротехника корылмаларының ышанычлы һәм куркынычсыз эше, республиканың киләчәге өчен җирләрнең уңдырышлылыгын саклау һәм яңартып тору.

Татарстан – Россиянең мелиорация буенча киң күләмле программалар тормышка ашырыла, объектлар төзелә, сугару техникасы җитештерүче яңа предприятиеләр ачыла торган сирәк төбәкләрнең берсе.

Әйтик, 2015 елда республика территориясендә сугару техникасын җитештерүне үзебездә булдыру турында карар кабул ителде. Бер елдан да азрак вакыт эчендә яңа җитештерү бинасы төзелде, остаханә һәм җитәкчелек биналары, торак блок белән матди товарлар склады яңартып корылды. Бер үк вакытта конструкторлык документларын эшләү һәм гамәлгә кертү, детальләрнең вектор модельләрен әзерләү эшләре башкарылды, станоклар, җиһазлар һәм машиналар өчен комплектлаучы детальләр сатып алынды. Һәм инде 2016 елда Казан сугару техникасы заводы әйләнә-әйләнә «яңгыр сиптерүче» 14 «Казанка» машинасын кырларга чыгарды.

Кулланучылар яңалыкны шунда ук югары бәяләде, чөнки төрле культураларның уңдырышлылыгы су сипкәндә бермә-бер арта. Моннан тыш, «Казанка» чит ил аналогларыннан сизелерлек арзан да. Якындагы өч ел өчен безнең планда – елына 300 «Казанка» корылмасы җитештерү буенча проект егәрлегенә чыгу. Җитештерүгә барабан тибындагы сугару җайланмаларын кертү һәм заводта төрле типтагы сугару корылмалары өчен насос станцияләре җыюны оештыру кебек ниятләр дә бар.

Республика һәм федераль максатчан программалар кысаларында Татарстан мелиорация комплексын үзгәртеп кору һәм яңарту эше мелиорация тармагының киләчәктәге үсешенә йогынты ясый. Һәм, димәк, агросәнәгать комплексының киләчәктәге үсешенә, авыл хуҗалыгы җитештерүенең рентабельлелегенә һәм тотрыклылыгына да.

«Татмелиорация» республика системасын 95 еллыгы белән котлап, мин барлык мелиораторларга аларның четерекле, авыр, әмма игелекле эшләрендә түземлелек, сәламәтлек һәм гаиләләренә иминлек телим!

Реклама

ГКЗ
ГЛАЗОВСКИЙ
комбикормовый
завод

ПОДБИРАЙТЕ КОМБИКОРМА ПРАВИЛЬНО!

Входит в группу компаний
КОМОС ГРУПП

ДЛЯ ЛИЧНЫХ ПОДСОБНЫХ ХОЗЯЙСТВ.

Комбикорма ЭКОНОМ – «Доброе подворье» разработаны специально для животных, которые содержатся в условиях домашних хозяйств с традиционной технологией выращивания. Необходимое количество питательных веществ, витаминов и минералов обеспечат здоровье и продуктивность ваших животных.

• Фасовка 5 и 25 кг. •

ДЛЯ ПРОМЫШЛЕННЫХ ЖИВОТНОВОДЧЕСКИХ КОМПЛЕКСОВ И ПТИЦЕФАБРИК.

Рецептуры комбикормов ПРОФИ разработаны с учетом рекомендаций от создателей пород и кроссов сельскохозяйственных животных и птицы, оптимальны для применения в условиях промышленных комплексов с интенсивной технологией выращивания.

• Фасовка 25 и 40 кг. •

Реклама

АДРЕСА ТОРГОВЫХ ТОЧЕК

УДМУРТИЯ

«Глазовский комбикормовый завод»
г.Глазов,
ул. Красногорский тракт, 15
Отдел продаж:
тел.:(34141)3-85- 33
Фирменный магазин:
тел.:(34141)3-81- 20

«Можгинский элеватор»
г.Можга,
ул.Железнодорожная, 93
Фирменный магазин:
тел.: (912)019-54- 60

УДМУРТИЯ

«Крестьянский рынок»
Завьяловский район,
уд.Пирогово, ул.Торговая, 1
тел.: (3412)62-33- 89

БАШКИРИЯ

«Янаульский элеватор»
г. Янаул,
ул. Социалистическая, 19А
Фирменный магазин:
тел.: (34760)5-95-93

ТАТАРСТАН

«Крестьянский двор»
г. Набережные Челны,
п. Сидоровка,
ул. Магистральная, 47 Б
тел.: (927)416-95-07

«ИП Садреев»
г. Чистополь,
ул. Привалова, 86
тел.: (917)905-95-85

«ИП Минабутдинова»
г. Казань,
Горьковское шоссе, 113 В
тел.: (919)633-83-32

ПЕРМСКИЙ КРАЙ

«Агро-Торг»
г. Пермь,
ул. Буксирная, 4
тел.: (922)24-34-224

КИРОВСКАЯ ОБЛАСТЬ

«Оникс»
тел.: (912)874-82-00
тел.: (912)852-31-93

«ЩЁЛКОВО АГРОХИМ» АЖ

Үсемлекләрне һәм агрохимикатларны, бөртеклеләрнең, бөртекле-кузаклыларның һәм шикәр чөгендеренең орлыкларын саклау чараларын иң эре җитештерүчеләрнең берсе, тиз арада илебезнең географик чикләреннән «атлап чыккан», якын һәм чит ил аграрийлары белән актив хезмәттәшлек итүче җәмгыять.

Салис Каракотов, «Щёлково Агрохим» АЖ генераль директоры.

1998 елда ике предприятие – ВНИИХСЗР-ның Щёлково филиалы һәм «Агрохимның Щёлково предприятиесе» ААҖ базасында нигезләнгән. Предприятие, препаратларның токсикологиясе буенча барлык зарури тикшеренүләрне үткәрү һәм аларның биологик активлыкларын өйрәнү максатында, Россиянең ВИЗР, ВНИИФ, Эрисман ис. ФНЦГ, ВНИИД, ВНИИСС, К.А. Тимирязев ис. РГАУ МСХА һәм башка шундый фәнни-тикшеренү институтлары белән хезмәттәшлек итә.

Бүгенге көндә РФ һәм БДБ төбәкләрендә 40тан артык вәкиллеге эшли.

Компания озак вакытлардан бирле Орёл өлкәсендәге иң эре авыл хуҗалыгы предприятиесе – «Дубовицкое» ҖЧҖ белән эшли. Җитди инвестицияләр, алдынгы технологияләр, җир эшкәртүнең фәнни нигезләнгән системасы... Берничә ел эчендә «Дубовицкое» үз төбәгендә генә түгел, илнең төрле почмакларындагы башка хуҗалыклар өчен дә үрнәк алырдай мәйданга әверелде.

2011 елда Воронеж өлкәсендә «Бетагран Рамонь» шикәр чөгендере орлыкларын дражелаштыру заводы эшли башлады. Предприятиенең җитештерү егәрлеге елына 400 мең чәчү берәмлеген тәшкил итә.

Дача хуҗалары өчен махсус «Октябрина Апрелевна» дигән сәүдә маркасы чыгарыла башлады, ул югары сыйфатлы препаратларны уңайлы, вак фасовкаларда тәкъдим итә.

2014 елдан «Щёлково Агрохим» зур көчен авыл хуҗалыгы юнәлешен үстерүгә багышлый. Нәтиҗәдә – «Бетагран Липецк» ҖЧҖндә терлекчелекнең югары нәтиҗәле үсеше өчен мөгезле эре терлекнең элиталы токымнары эмбрионнарын җитештерү буенча Россиядә беренче селекция-генетика үзәге ачылды.

2016 елдан «Щёлково Агрохим» авыл хуҗалыгы техникасы чыгару буенча ике Италия заводының (Proiet* һәм Mascar**) рәсми дилеры булып тора. Уңышлы эшчәнлек өчен Воронеж өлкәсендә махсус запас частьлар склады һәм сервис хезмәте оештырылган.

2017 елның беренче яртыеллыгында компания тагын ике проект ачылуын белдерде. Алар – интенсив бакчаларны боз явудан һәм кошлардан саклау буенча Россиядә беренче «БЕТАНЕТ» сәүдә маркасы җитештерү линейкасын эшләтеп җибәрү, һәм шулай ук «Русагро» компанияләр группасы белән берлектә оештырылган СоюзСемСвёкла яңа селекция үзәген ачу. Үзәкнең максаты – яңа сыйфатлы, югары продуктлы, авыруларга (церкоспороз, тамыр череге һ.б.) бирешмәүчән һәм төп биоморфологик билгеләре буенча бер тигезлеккә ия шикәр чөгендере гибридларын булдыру.

ЩЕЛКОВО АГРОХИМ
российский аргумент защиты

«Щёлково Агрохим»ның Урал-Идел буе вәкиллеге

Казан ш.,
Красносельская ур., 51а йорты
Телефон: (843) 562-34-85
E-mail: kazan@betaren.ru
www.betaren.ru

[1] Проджет, [2] Маскар.

Реклама

ПЕРЕДОВЫЕ ТЕХНОЛОГИИ В ОРОШЕНИИ И УТИЛИЗАЦИИ ЖИВОТНОВОДЧЕСКИХ СТОКОВ

- ОРОСИТЕЛЬНЫЕ УСТАНОВКИ
- НАСОСЫ ДИЗЕЛЬНЫЕ И ЭЛЕКТРИЧЕСКИЕ
- ТРУБОПРОВОДЫ БЫСТРОГО СОЕДИНЕНИЯ
- СЕПАРАТОРЫ, МИКСЕРЫ, ЦИСТЕРНЫ
- УСТАНОВКИ BRU** ДЛЯ ПРОИЗВОДСТВА ПОДСТИЛКИ
- КОМПОНЕНТЫ ДЛЯ БИОГАЗОВЫХ УСТАНОВОК

Волгоград, ул. Тимирязева, 9, тел.: +7 (8442) 41-62-83, +7 (8442) 26-04-30
www.riagro.ru, e-mail: vasilyuk@riagro.ru

Реклама * Бауэр «Для зелёного мира» ** БРУ

PRESSA.RU

ЯКТЫРТЫЛУНЫҢ БӘЙЛӘМИЧӘ АСРАГАН СЫЕРЛАРНЫҢ ПРОДУКТЛЫЛЫГЫНА ЙОГЫНТЫСЫ



Рифат Садыйков, «ДеЛаваль» компаниясенең әйдәп баручы консультанты

Тикшеренүләр Рязань өлкәсенең «Вакино Агро» ЖЧҖнең роботлаштырылган саву комплексындагы голштин токымлы сыерларда үткәрелде.

Яктыртылу дәрәҗәсенең терлекләрнең туклануына һәм продуктлылыгына йогынтысы өйрәнелде.

Язгы-җәйге һәм көзге-кышкы чорларга күчү вакытында, аеруча кышын – көн кыскарганда сыер организмында продуктлылыкның кимүенә китерүче үзгәрешләр башлана. Бу чорда тәүлекнең караңгы вакытында гына барлыкка килүче меланин гормоны бүленеп чыгу акрыная.

IGF[2]-1 аутоген факторына кышын юл ябыла, ә җәен ул туплана һәм, көннәрнең озын булуы нәтиҗәсендә, арта, сөт ясалуга нәкъ менә ул шактый зур йогынты ясый.

Безнең алга яктыртылу дәрәҗәсенең терлекләрнең туклануына һәм продуктлылыгына йогынтысын өйрәнү максаты куелды.

ТИКШЕРЕНҮЛӘР МАТЕРИАЛЫ ҺӘМ МЕТОДИКАСЫ

Экспериментал тикшеренүләр 2014–2015 елларда башкарылды, әлеге мәсьәләне өйрәнү Рязань өлкәсенең «Вакино Агро» ЖЧҖнең роботлаштырылган саву комплексында «ДеЛаваль» компаниясенең савымчы роботларында үткәрелде.

Төрле абзарлардагы сыерларның ике төркеме өйрәнелде, аларны ашату һәм асрау шартлары бертөрле иде. 885 баш терлекне саву роботлаштырылган 16 җайланмада башкарылды.

Продуктлылык һәм физиологик халәт буенча мәгълүмат көтү белән идарә итүче ДельПро программасыннан алынды. 1 нче номерлы абзарга «ДеЛаваль» компаниясенең E-FL[3] 250 яктырткычлары урнаштырылды, исәпләү яктыртылышы – 180 люкс, көн озынлыгы 180 сәгатьне тәшкил итте, караңгылык – 6 сәгать һәм яктыртылу 70 люкс иде. 2 нче номерлы абзарда көн яктылыгы лампалары файдаланылды, исәпләү яктыртылышы – 100 люкс, көн озынлыгы 14 сәгатьне тәшкил итте, караңгылык 10 сәгать булды. 1 нче номерлы корпуста яктыртылу бертөрле булды – ашату зонасында да, ял зонасында да 180 люкс иде. 2 нче номерлы абзарда яктыртылу ашату зонасында – 95 люкс, ә ял зонасында 75 тирәсе люксны тәшкил итте.

ТИКШЕРЕНҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Туклану һәм продуктлылык сыерларны ашатуның яхшы сыйфатлы булуын, терлекләрнең сәламәтлеген һәм уңай шартларда яшәү дәрәҗәсен характерлаучы мөһим параметрлар булып тора. Сыерларның сөт бирүчәнлегенә анализ ясау ДельПро көтү белән идарә итү программасындагы уртача тәүлеклек савым буенча үткәрелде, туклану терлек азыгы өстәлендәге азык калдыкларын көндәлек үлчәү юлы белән һәм азык станцияләре мәгълүматлары буенча бәяләнде.

Тикшеренү нәтиҗәләре, тәҗрибә төркеме белән чагыштырганда, продуктлылыкның – 10,7%ка, ашап бетерү буенча туклану өстәлендәге коры азык маддәсенең 4,2%ка артуын күрсәтә.

Яктыртылу 180 люкс һәм көн озынлыгы 16 сәгать булганда, бер үк шартларда асралучы сыерлардан, көн озынлыгы һәм яктыртылу азрак булган төркемдәгеләр белән чагыштырганда, сөт 2 литрга

BSC[1] идарә итү блогы фермада күп җиһазлар – яктырту системасыннан башлап, терлекләрне җылләтү системалары һәм сыеру вентиляциясе системасына кадәр – белән идарә итәргә мөмкинлек бирә. Микроклимат белән тагын да нәтиҗәлерәк идарә итү өчен һава торышы станциясен кушарга мөмкин.

1 нче номерлы сыер абзарын яктырту өчен E-FL250 яктырткычы һәм читтән торып идарә итү һәм күзәтү мөмкинлеге бирә торган BSC микроклимат һәм яктырту белән идарә итү блогы кулланылды.

1 нче таблица.
Яктыртылу һәм көн озынлыгы төрле дәрәҗәдә булганда туклану һәм продуктлылыкка чагыштырмача анализ.

Исеме	Эксперимент төркем	Күзәтүче төркем	Тайпылышлар	
			нат.	%
Сыерларның баш саны	451	434	17	3,8
Коры азык, кг	19,2	18,4	0,8	4,2
Савым көннәре	161	152	9	5,6
Экспер.ка кадәр савым	26,3	26,7	-0,4	-1,5
Экспер. вакыт. савым	29,9	26,7	3,2	10,7

[1] БиЭсСи, [2] АйДжиЭф, [3] И-ЭфЭл, [4] АйПи

Реклама

Инде бүген үк микроклимат белән читтән торып идарә итәргә һәм агымдагы вазгыятьне контрольдә тотарга мөмкин.

күбрәк савып алынган. Лактация өчен бу сыерлар 500 литр өстәмә сөт биргән.

Бер литр сөтнең минималь сатып алу бәясе 20 сум дип алсак, лактация өчен 500 литр сөт (бу бер баш сыердан 1000 сум яки 1 нче номерлы абзардагы барлык сыерлардан 451 мең сум керә дигән сүз) яктыртылу 180 люкс булу һәм көннең озынайтылу бәрабәренә алынган.

Шулай итеп, сыер абзарында «ДеЛаваль»нең 180 люкс яктыртылуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирүче E-FL 250 профессиональ яктырткычларын файдалану икътисадый яктан нигезләнгән һәм продуктылыкны арттырырга сәләтле.

Җиһазларны сайлап алу өчен ДеЛавальнең якындагы дилерына яисә үзәк офиска мөрәҗәгать итегез.

«ДеЛаваль» E-FL250 һәм E-FL400 яктырткычлары терлекчелек биналарында файдалану өчен махсус эшләнгән һәм IP[4]-65 саклану классына ия. Яктырткычлар сыер абзарларында иң югары – 180–200 люкс яктыртылуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Лампаның мөмкинлеге – 20 мең сәгать.

«ТатЛаваль» ҖЧҖ
420061,ТР, Казан шәһәре
Новаторлар ур., 2В, 4нче кат
Тел.: (843) 272-72-38,
факс: (843) 272-72-53
www.tatlaval.ru
E-mail: tatlaval@yandex.ru

Реклама

DeLaval[1]

ОптиБлу™+ Фортекс

Бережный уход и надежная защита

We live milk
Мы живём молоком

Превосходные моющие и дезинфицирующие свойства ОптиБлу™ делают его отличным средством для ухода за выменем перед доением.

Надежная защита от возбудителей мастита после доения благодаря отличным бактерицидным свойствам Фортекс.

Технология Ionoplex[2] эффективно уничтожает бактерии на поверхности кожи соска делая Фортекс отличным средством для ухода за выменем после доения.

Иод является основным активным ингредиентом. Его содержание: 2500 ppm — доступного и 8 ppm — активного. Содержание ухаживающих веществ: 27%.

Преимущества ОптиБлу™

- Эффективное быстрое действие против патогенных бактерий, вызывающих мастит
- Отличные очищающие и дезинфицирующие свойства
- Экономичный
- Густая, хорошо заметная на сосках пена позволяет контролировать обработку сосков.

Преимущества Фортекс:

- Удобен в использовании – готов к применению
- Экономичный расход: низкая стекаемость с сосков после обработки
- Хорошо виден на сосках – для контроля обработки.

8 800 333 50 05 . www.delaval.ru

[1] ДеЛаваль, [2] Лоноплекс, [3] ОптиБлу, [4] Фортекс

Реклама

PRESSA.RU

ВЛАДИМИР ЛЕОНОВ: – ФУТБОЛНЫ КИЛЕП КАРАРГА КИРӘК!

Журналыбызга биргән интервьюсында Татарстан яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов Казанның Конфедерацияләр кубогын кабул итәргә ничек әзерләнүе турында сөйләде.

Автор:
Олеся Бондаревская

– Футболга бәйле һәр спорт вакыйгасы, иң беренче чиратта, күпләр өчен җанатарларның бихисап булуы белән күзаллана. Билгеле булганча, Россиягә Конфедерацияләр кубогы матчларына килүче кунаклар өчен визасыз режим гамәлдә булачак. Ә менә матчларда куркынычсызлык ничек тәэмин ителәчәк?

– Куркынычсызлык чараларын – инде күрелгәннәрен һәм матч вакытында күреләчәкләрен – моңарчы булмаганча җитди дип атарга була. Шуннан башларга кирәк: стадионга киләчәк һәркемнең үзе белән ике документы булырга тиеш – матчка билеты һәм Fan ID. Соңгысы, асылда, визаның аналогы санала, аны РФ чиген узган чит ил җанатарлары күрсәтергә тиеш. Аннан соң Fan ID һәр матчка кергәндә сканлаштырылачак. Шулай итеп, без кемнең кайсы урында утырганын беләчәкбез. Тәңгәлләштерүнең әлеге системасы Россиядә беренче мәртәбә кулланылачак.

– Җанатарлар стадион территориясенә шәхси машиналарында керә алачакларммы?

– Юк. FIFA таләпләре буенча мондый масштабтагы чаралар вакытында спорт объектлары транспорттан бөтенләй азат ителгән километрлы зона белән әйләндереп алынган булырга тиеш. Без Казанда әлеге зонаны 500–600 метр итү турында килешүгә ирешә алдык. Шуңа күрә барлык җанатараларны җәмәгать транспортыннан файдаланырга өндибез – Fan ID булган очракта транспортта йөрү бушлай булачак.

– FIFA Конфедерацияләр кубогына билетларга бәя ничек формалашачак?

– Конфедерацияләр кубогын үткәрүнең башка шактый гына таләпләре кебек үк билет бәяләре дә FIFA тарафыннан билгеләнә. Россия резидентлары өчен FIFA Конфедерацияләр кубогы матчлары билетларына махсус дүртенче категория куелган. Бәяләр 960 сумнан башлана. Дөрес, Казанда узачак төркем этаплары матчларына мондый категориядәге билетлар инде юк, бу тагын бер мәртәбә әлеге вакыйгага карата кызыксынуның шактый югары булуын күрсәтә. Әлбәттә, стадионга килүгә альтернатива да булачак – онлайн-трансляцияләрне барда яисә өйдә карарга да мөмкинлек тудырабыз. Ләкин стадионда карау – бу инде бөтенләй башка эмоцияләр! Шуңа күрә мин якыннарымны һәм коллегаларымны, мөмкинлек чыкканда, матчларга барырга чакырам. Мондый дәрәҗәдәге йолдызлар икенче мәртәбә безгә бары тик дүрт елдан соң гына килә алачак.

– Билетларга шундый бәяләр булганда, сезне «Казан Арена» трибуналары ярымбуш булу перспективасы куркытмыймы?

– Кызганыч, сатылган билетлар буенча саннарны яңгырата алмыйм – бу FIFAның коммерциячел мәгълүматы. Ләкин мин трибуналарның тулы булуына ышанам. Билетлар сатыла башлаганнан бирле, яхшы динамика күзәтелә. Иң популяры, әлбәттә, 24 июнь көнне узачак Россия һәм Мексика арасындагы матч булачак. Дөнья чемпионы Германия җыелма командасы белән Америка Кубогы җиңүчесе Чили командасы арасындагы матч та зур кызыксыну уята. Ә инде билетларның ярымфиналга сатылышы анда кайсы командалар эләгүенә бәйле.

– Кунаклар кайсы регионнардан киләчәк?

– Сатылган билетларга караганда, безгә Казаннан 500–600 км радиуста урнашкан шәһәрләрдән – Самарадан, Ульяновскидан, Уфадан, Йошкар-Оладан җанатарлар килер, дип көтелә. Татарстаннан җанатарларның күп булуы да шатландыра.

– Фан-клубларның вәкилләре кызыксыну белдерделәрме?

– 20 кешелек скайбокслар сатыла. Бу дуслар һәм туганнар компанияләре булыр, дип уйлыйм. Җанатарлар «армиясе» ябырылыр дип көтәргә кирәк түгелдер. Моннан тыш, FIFAның үзенең дә скайбоксларда, һәм шулай ук кунакханәләрдә урыннарны сату буенча килешүләре бар.

– Конфедерацияләр кубогы матчлары – Казанны һәм республиканы танытту өчен менә дигән мөмкинлек. Чит ил кунаклары өчен мәдәни программа каралганмы?

– Без чит ил туристларын да, үзебезнекеләрне дә каршы алырга әзерләнәбез. Шәһәрдә барган интенсив әзерлекне үзегез дә күрәсездер. Барлык җәйге мәдәни актив чаралар матчлар графигын исәпкә алып үткәреләчәк. Җәмәгать транспорты хәрәкәтенең ешлыгы, Казан һәм аэропорт арасында элек-

Ната Смирнова фотолары.

PRESSA.RU



> **– Спорт объектларының моның кадәр күплеге белән бер генә Россия шәһәре дә мактана алмый, хәтта Мәскәү дә.**

тропоездлар рейсларының саны арттырыла. Матчлар үтә торган чорны бәйрәмчә – күңелле, матур һәм бар кеше өчен куркынычсыз итү өчен мөмкин булганның барысы да эшләнә.

– «Казан Арена»ның торышына нинди бәя куясыз?

– Стадион 100%ка әзер дияргә була. Скептикларның газонга карата фикерләренә карамастан, аның торышы тренерлар тарафыннан да, FIFA чараларына аккредитация үткәрә торган компанияләр тарафыннан да идеаль дәрәҗәдә дип бәяләнә. Сүз уңаеннан, Конфедерацияләр кубогын кабул итүче стадионнар арасында «Казан Арена» иң әзерлеклесе булып чыкты, регламент кысаларында шелтәләр минималь булды.

– Конфедерацияләр кубогы матчларын үткәрү Казан өчен – үзенә күрә оештыру һәм ресурс потенциалын демонстрацияләү дип әйтеп буламы?

– Без мондый демонстрацияләүгә мохтаҗ, димәс идем. Казанның спорт башкаласы дигән даны инде таралган. Килешәсездер, һәр шәһәр үз кырында Португалия, Германия, Чили, Мексика командалары кебек дәрәҗәле кунакларны лаеклы рәвештә кабул итә алмыйдыр. Бу сезонның титуллы футбол турниры булган Конфедерацияләр кубогын бездә каршы алу факты үзе үк күп нәрсә турында сөйли.

– Күптән түгел генә Россия Президенты Владимир Путин, Казан 2028 елгы Җәйге Олимпиада үткәрүгә дәгъва кыла алырлык шәһәрләр исемлегенә керергә лаеклы, дип белдерде. Сез ничек уйлыйсыз, инфраструктура ягыннан шәһәр әзер, дип уйлыйсызмы?

– Һичшиксез. Масштаблы спорт вакыйгаларында катнашу, һәм шулай ук спорт объектлары төзү буенча президент программалары нәтиҗәсендә без яссылыклы корылмалар, бассейннар, ачык урам мәйданчыклары саны буенча – лидерлар. Универсиада үткәрелү нәтиҗәсендә алар барысы да заманча технологияләр буенча төзелгән һәм халыкара спорт федерацияләре таләпләренә, шул исәптән объектларны урнаштыру буенча куелганнарына да җавап бирә. Спорт объектларының моның кадәр күплеге белән бер генә Россия шәһәре дә мактана алмый, хәтта Мәскәү дә. 2019 елга «Казан Экспо» комплексы салыначак, ул безнең мөмкинлекләрне тагын да киңәйтәчәк. Бездә Олимпиада исемлегенә кергән бер генә объект юк әлегә – велотрек, аны кайбер таләпләр аркасында, реконструкцияләү юлы белән төзергә ярамый. Яңабаштан төзергә кирәк.

– Масштаблы спорт чаралары арасында әлеге инфраструктура ничек кулланылачак?

– Ул, һичшиксез, безгә кирәк һәм барлык мәйданнар, анда хезмәт күрсәтүләр даими файдаланылсын өчен без актив эшлибез. Нәтиҗә аермачык – республика халкының 40%ка якыны спорт белән шөгыльләнә. Студентлар арасында бу сан тагын да югарырак – 77%. Безнең яхшы резервларыбыз, әйбәт юниор командаларыбыз бар, спортның индивидуаль төрләрендә дә, командалы уеннарда да.

– Матчлары 2018 елда Казанда узачак футбол буенча дөнья чемпионатына яңа объектлар төзеләчәкме?

– Бераз гына серне ача төшәм: «Казан» Гаилә үзәге янындагы мәйданда вакытлыча парк – җанатарлар фестивале узачак фан-зона ачылачак. Бирегә нииндидер сәбәпләр аркасында матчларга эләкмәгәннәр да килә алачак. Хәзер без территорияне проектлау белән шөгыльләнәбез – аның мәйданы якынча өч мең квадрат метрны тәшкил итә. ■

ТАТАРСТАНДА
КУНАК БУЛСАҢ –

«ТАТАРСТАННЫ»
УКЫ!

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛДЫНДАГЫ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН

Гөлнара Галкина-Сәмитова – Олимпия уеннары тарихында стипль-чезда (каршылыклар аша 3000 метрга йөгерү) беренче чемпион. Ул үзенең беренче дөнья рекордын 2003 елда, җиңел атлетика буенча Россия чемпионатында, икенчесен – тагын бер елдан Грециядәге халыкара ярышларда, ә өченчесен инде Пекиндагы Олимпиадада куйды. Хәзерге вакытта дөньяның экс-рекордсменкасы санала, әмма Олимпия уеннарында Гөлнара рекордын әле беркем дә уза алмады. 1999 елдан «Динамо» җәмгыяте өчен чыгыш ясый, полиция майоры званиесенә ия.

БАРЛЫК **КАРШЫЛЫКЛАРНЫ** КИЧЕП...

Ул карап торышка бик нәфис күренә. Әмма Яр Чаллы кызының холкы – корычтай. Җиңел атлетиканың иң катлаулы дисциплинасы – стипль-чезда өч дөнья рекорды куйган спортчы ул. 2008 елда үзенең спорт бүләкләренә өстәп, Гөлнара Галкина-Сәмитова республиканың иң югары бүләгенә – «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденына лаек булды.

ҖИҢҮ БӘҺАСЕ

Ул көнне мин гомерем буена онытмам. 2003 елда Туладагы Россия чемпионатында, миңа тиешле финишка чыгарга ярдәм итү өчен темп бирергә дип, яныма бер пейсмейкер кызны билгеләделәр. Ихтимал, ул тизлекне дөрес исәпләмәгәндер, гомуми әйләнәбезне без графиктан тизрәк йөгереп үттек. Нәтиҗәдә, кыз чыгып калды, ә миңа – йөгерәсе дә йөгерәсе – әле каршылыклар белән! Инде беренче мең метрдан соң ук шундый авыр була башлады, һәм бердәнбер теләк – дистанциядән төшү теләге генә калды. Әмма моны кайсы урында эшләргә? Менә мин Россия җыелма командасының баш тренеры Валерий Куличенко янынннан узам – юк, бик уңайлы урын түгел бу. Түзәм, ары узып китәм. Икенче сызыкта инде минем тренерым – Миңнулла Низаметдинович Чинкин басып тора – монда да чыгарга ярамый. Кырның икенче ягына чыгып җитәм – анда безнең өчен җан атучы солдатлар. Алар алдында да уңайсыз, махсус килгәннәр бит. Шулай итеп, әйләнә арты әйләнәне кичеп, үземнең өч мең метрымны уздым һәм финишка беренче булып килеп җиттем. Ул чакта бу дисциплина буенча дөнья рекорды Белоруссия спортчысы Алеся Туровада иде. Мин, дистанцияне 9.08 минутта узып, рекордны 9 секундка яхшырттым.

Стипль-чезда икенче дөнья рекордымны мин 2008 елда Пекиндагы Олимпиадада куйдым. Ул сигез ел буе сакланды һәм 2016 елда гына яңа рекордсмен табылды – Бәхрәйннан Рут Джебет җитезрәк булып чыкты. Мин аның өчен үртәлмим, чөнки сүз секундның күпмедер өлеше турында түгел, тулы алты секунд турында бара бит. Бу спортчы кызны күптән күзәтәм һәм, дөресен генә әйткәндә, ул моны иртәрәк тә эшләр дип уйлаган идем. Яхшы әзерләнгән, сәләтле. Афәрин!

МАРАФОНГА... МАКРАМЕДАН

Ун яшемә кадәр мин, гомумән, спорт белән шөгыльләнмәдем – башка кызлар кебек үк, макраме үрә, чигү чигә идем... Барысын да көннәрдән бер көнне узган физкультура дәресе үзгәртеп җибәрде. Ул дәрескә минем булачак тренерым Виктор Аржевитин килгән иде. Кырык биш минут буе ул безне игътибар белән күзәтте һәм, мөгаен, миндә әти-әниләремнән күчкән табигый сәләтне сизгәндер. (Әнинең туган авылы Татар Карамалысында йөгерештә малайларны да узуы турында сөйләгәне бар иде, ә әти армия кроссларында иң яхшы нәтиҗәләр күрсәтә торган булган.) Виктор Николаевич миңа махсус спорт классы ачылачак мәктәпкә күчәргә тәкъдим итте. Тиз арада иң яхшыларның берсенә әверелдем дип әйтә алмыйм – лидерлар башка иде, алар тизрәк йөгерә дә, биегрәк сикерә дә. Үзебезнең танылган Равил Кашапов кебек марафончыларга карап (1988 елда Сеул Олимпиадасында катнашучы – ред. иск.), миңа да торган саен озынрак дистанцияләр ошый баруын аңладым. Мин беркайчан да Олимпия уеннарында яну идеяләре белән янмадым, әмма ул чакта инде аларда катнашып карау теләге туган иде.

Ольга Туманская
әзерләде

КАЯ ЙӨГЕРЕРГӘ?

Стипль-чез, ягъни каршылыклар аша өч мең метрга йөгерү – җиңел сынаулардан түгел. Тизлек белән барьерга эләгеп калсаң... сөякләреңне сындырырга да мөмкинсең. Күп каршылыклар арасында – су тутырылган чокыр да бар. Миннән еш кына финишка кадәр йөгерергә туры киләчәк юеш кроссовкаларым турында сорыйлар. Монысына карата минем үз стратегиям бар: икенче аягым коры калсын өчен, чокырга бер аяк белән генә эләгергә тырышам. Бу беркадәр өстенлек бирә. Моннан тыш, минем махсус шиповкаларым да бар – челтәрләп ясалган, аларда су тоткарланмый.

Чаллыдагы тренерым белән стипль-чезны беренче тапкыр 2000 елда ук сынап карадык. Минем буем моңа мөмкинлек бирә дигән фикергә килдек. Әмма бу дисциплинага килергә мин шактый вакыт җөрьәт итмәдем. Нәкъ менә Тулада дебютым булды, шуннан соң Россия җыелма командасына эләктем. Ә бер елдан соң инде Афинага үземнең беренче Олимпиадама киттем.

Яшермим, ул еннарда финалга эләгүемә бик гаҗәпләндем. Эш шунда, 5000 метрлы дистанциягә мин буп-буш ашказаны белән чыктым. Безнең йөгерешнең вакытын соң куйдылар, ә мин борчылып, иртәдән бирле ашамаган идем. Финишка ничек барып җиткәнемне дә белмим: ян-ягымның авыртуы иртәгесе көн буена сузылды.

Финалда тагын бер көтелмәгән хәл килеп чыкты: халык белән тулы трибуналарны күргәч, югалып калдым һәм кайсы якка йөгерергә икәнен дә чамаламый башладым. Бәхеткә, безнең спортчылар Лена Задорожная белән Лиля Шобухова янәшәмдә булып чыкты. Рәхмәт аларга, юнәлешне күрсәттеләр.

БАРЫСЫНА ДА ПАРИЖ ГАЕПЛЕ

Әгәр без ирем белән паркка йөгерергә чыксак, иртәме-соңмы, мин аны калдырып китәм. Өйдә очрашабыз. Антон (Антон Галкин-Сәмитов, җиңел атлетика буенча Россия призёры – ред.иск.) – кыска дистанция спринтер, әмма озын дистанцияләрдә ул мине куып җитә алмый. Хәер, бу көндәшлек өчен сәбәп түгел – без бер-беребезнең уңышларына һәрвакыт шатлана идек.

Танышуыбызның тарихы шулай ук спорт белән бәйле. Россия җыелма командасында бергә шөгыльләндек, ләкин бер-беребезгә әллә ни игътибар итми идек. Соңрак Антон минем нинди дистанциягә йөгерүемне дә белмәгәнлеген әйтте! Барысын да Париждагы 2003 елгы дөнья чемпионаты үзгәртте. Ярышларның соңгы көнендә банкет булды, һәм менә шунда әлеге очкын кабынып китте... Шуннан бирле аерылышмадык инде. Минем беренче Олимпиадамнан соң бергәләп Яр Чаллыга кайттык. Мин ул чакта Афинада ярыйсы гына әйбәт нәтиҗә күрсәттем – алтынчы булып килдем – туган ягымда мине каршы алдылар. Мөгаен, җитәкчелек Антон мине үз ягына Санкт-Петербургка алып китәр дип шикләнгәндер, шуңа да ул чакта шәһәр хакимияте җитәкчесе булган Илдар Халиков безгә туй үткәрергә ярдәмен тәкъдим итте. Без баш тартмадык, әмма, дөресен әйткәндә, ул чакта безнең планда ЗАГС юк иде әле.

Бүген без ул карарыбызга сөенәбез. Анда мөмкинлекләрнең кулдан ычкынуына юл куелмады. Мин беркайчан да китәргә теләмәдем– кем әйтмешли, «тамыр җибәргән» идем, иремә дә ошый биредә. Санкт-Петербургта югалып калырга да мөмкин, ә Чаллыда безне бәялиләр һәм ярдәм итәләр.

Гаиләдә спорт карьерасын кем дәвам итәргә тиеш дигән сорау тугач, бу мөмкинлекне Антон миңа бирде. Кемдер гаилә учагын сакларга тиеш бит, өстәвенә, 2010 елда безнең кызыбыз туды. Ирем тренер булып эшли. Аның шәкертләре арасында бик тә сәләтле балалар бар, бүген алар – аның азарты.

ИКЕ ФЛАГ АСТЫНДА

Минем спортны ташларга теләгән чакларым бар иде. Ул мизгелләрнең берсе Пекиндагы «алтын» Олимпиадам алдыннан булды. 2008 елның ул гыйнвар аен бик яхшы хәтерлим. Күнегүләр бик авыр бирелә, көн саен моны дәвам итәргәме-юкмы икән дип шикләнә идем. Шунда без Миңнулла Чинкин белән миңа яңа тренер белән шөгыльләнеп карарга кирәк дигән нәтиҗәгә килдек. Шулай итеп, Россия җыелма командасы тренеры Геннадий Суворов минем яңа остазым булды. Түземлелектә аннан оста зат юктыр! Аңа килергә бик үк теләмиләр дә – ул кадәр йөкне һәркем күтәрә алмый. Төркемдә без ике кыз идек – мин һәм Аня Альминова (Россия һәм Европа чемпионы – ред.иск.). Безнең өчен искәрмәләр юк – башкалар кебек үк шөгыльләнәбез. Кургаш тутырган капчыклар күтәреп йөгермибез йөгерүен, әмма барыбер зур түземлек кирәк – бөтен көчебез белән малайларга «ябышабыз», артта калмаска тырышабыз. Яңа кешеләр, методикалар... Кызыксыну барлыкка килде, озакламый беренче нәтиҗәләр дә. Тагын ярты ел шөгыльләнүләр, һәм мин Пекиндагы Олимпиадада «алтын» яулый алдым. Дөрес, чак кына коры калмадым мин аннан....

Исемдә, почёт әйләнәсен ниндидер күтәренкелек, эйфория белән уздым, янәшәмдә – шундый ук халәттә – Катя Волкова (Пекин Олимпиадасында бронза призер – ред.иск.). Беренче өч йөз метр план буенча барды – минем кулда Россия флагы җилферди. Инде финишка якынайганда Татарстан группасын күреп алдым. Барысы да шундый бәхетле! Миңа кемдер тагын бер постау – Татарстан флагын – сузды. Менә без Катя белән йөгерәбез, ә ул безнең арабызда җилферди. Әмма стадионнан чыгуга, безне көтелмәгән хәл каршылый – җиңү скандалга әверелергә мөмкин иде. Уен кагыйдәләре буенча ике флаг астында йөгерергә ярамый – моның өчен дисквалификация ясарга да мөмкиннәр икән. Бәхеткә, без җиңелчә курку белән котылдык.

БУЛАЧАК АЛМАШ

Июнь ахырында «Динамо» стартларында кросс йөгерәчәкмен. Дистанцияләре – чикләнгән урында бер һәм өч километр. Бу бик зур ярышлар. Катнашучылар – очсыз-кырыйсыз, хәтта Россия чемпионатында да ул кадәр җыелмас. Бер ярышта уналтышар кеше. Көндәшләрме? Илнең бөтен җыелма командасы килә инде!

Мин «Динамо» өчен 17 яшемнән бирле йөгерәм. Россия җыелма командасы составында бүген чыкмыйм диярлек: сборларга барып булмый – кызым озакламый укырга керә. Быел ил чемпионатында йөгерергә телим, әмма үз дисциплинамда түгел, «шома» биш километрны. Стипль-чез, ни дисәң дә, даими шөгыльләнүләрне таләп итә. Ә мин торган саен иремнең уңышларына күбрәк игътибар итәм. Бөтен тормышымны спортка багышладым, артымда зур тәҗрибә – бәлки миңа да тренер карьерасы турында уйларга вакыт җиткәндер? ▪

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

PRESSA.RU



ЯҢАЛЫКЛАР ФАБРИКАСЫ **РЕКОРДЫ**

Апрель аенда «Татар-информ» МА миллионынчы чиген алды – хаклы булуында шик уятмаслык интернет-исәпләгечләр сайтка керүчеләрнең саны нәкъ шулкадәр булуын ачыклады. Агентлыкның үсеше һәм соңгы елларда ирешкән уңышлары турында безнең журналга «Татар-информ» МАның генераль директоры Шамил Садыйков сөйли.

– «Татар-информ»ның вазыйфасы нидән гыйбарәт?

– Бер ел элек Республика матбугат һәм массакүләм мәгълүмат агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов һәм «Татмедиа» АҖ генераль директоры Андрей Кузьмин тарафыннан безнең алдыбызга Россиядә Татарстанга һәм татарларга багышланган төп мәгълүмат ресурсы булу бурычы куелган иде. Шушы максат тулысынча эшебезнең эчтәлеген билгели. «Татар-информ» республикада бара торган бөтен вакыйгалар турында оператив мәгълүмат бирә. Үзәк темалар исемлегендә ТР Президентының, дәүләт хакимияте органнарының эшчәнлеген, социаль-икътисадый үсешне яктырту. Бу мәгълүматка ихтыяҗ гаять зур. Игътибарыбызның тагын бер мөһим объекты – татар халкының тормышын төрле формаларында һәм чагылышларда яктырту. Татарлар күп гасырлар дәвамында бөтен дөньяга таралып яши, аларга Татарстанда ниләр булып торуын белү кызык. Алар яңалыкларны үз туган телләрендә белергә һәм укырга, үзләренең тарихи Ватаннарына кагылышлы

Реклама 16+

Бер елда «Татар-информ» МА сайтына керү дүрт тапкырга артты. 2016 елның апрелендә аңа 245 733 уникаль катнашучы кергән иде, ә 2017 елның апрелендә бу сан инде 1 143 031 гә җитте.

булуларын тоярга тели. Безнең аудиториянең 60–70%ы – Россиянең башка төбәкләрендәге укучылар.

– Мондый амбициоз бурыч гамәлдә ничек хәл ителә?

– Бер ел элек «Татар-информ»да йөкләнешләр үзгәртеп корылды, шуның нәтиҗәсендә асылда яңа команда оешты. Коллектив 70–80%ка яңарды. Күренекле Россия һәм дөнья мәгълүмат агентлыкларының тәҗрибәсен өйрәнеп, без үзебездә тармакның танылган лидерлары үрнәгендә яңа технологияләр керттек. Темалар буенча махсуслашуны, мәгълүматны җыю, сайлау һәм эшкәртүнең яңа системасын булдырдык. Социаль челтәрләрдә эшләү системасын төзедек. Бездә соцчелтәрләр өчен видеоконтент әзерләү буенча махсус бүлек эшли башлады. Көчле матбугат үзәген оештырдык. Бүген «Татар-информ» МА көненә берничә матбугат конференциясе үткәрә. Асылда, мәгълүмат дулкыны нәкъ менә бездән тарала, ягъни журналистлар өчен продуктны без булдырабыз.

Татар телендә нульдән башлап диярлек яңа сайт – tatar-inform.tatar сайтын булдырдык, ул узган елның августыннан башлап эшли инде. Сайтның бурычы – татарларга, дөньяның кайсы почмагында яшәүләренә карамастан, яңалыкларны үз телләрендә уку мөмкинлеге бирү.

Узган ел intertat.ru, sntat.ru кебек электрон матбугат чараларын һәм «Атна вакыйгалары» һәм «События недели» дигән ике басма газетаны үз канатыбыз астына алдык. Шулай итеп, «Татар-информ» бүген зур булмаган интеграцияләнгән мәгълүмат холдингы булып тора. Анда 100дән артык хезмәткәр эшли, аларның 50гә якыны – журналистлар. Бу – республикадагы иң зур редакция, үзенчәлекле яңалыклар фабрикасы.

Холдингка берләшү нәтиҗәсендә агентлыкның мәгълүматны республиканың һәр торак пунктына диярлек ирештерү мөмкинлекләре артты.

«Атна вакыйгалары» һәм «События недели» барлык район газеталарына урнаштырыла. Аларның гомуми тиражы (ике телдә) – 200 мең данәне тәшкил итә. tatar-inform.ru, tatar-inform.tatar, intertat.ru һәм sntat.ru сайтлары муниципаль берәмлекләрнең барлык сайтларына интеграцияләнгән.

Агентлыкның форматын алыштыру, аны заманча эш стандартларына күчерү нәтиҗәсендә сайтларга керүчеләр саны сизелерлек артты. Әгәр «Татар-информ»га моннан бер ел элек аена 250 мең кеше кергән булса, бу елның апрелендә уникаль катнашучылар саны миллионны узып китте! Сайтка керү дүрт тапкырга артты.

Позитив үзгәрешләр саннар арту ягыннан гына түгел, ә бәлки сыйфат ягыннан да күзәтелә. Бу да бик әһәмиятле. Электрон матбугат чараларының сыйфат күрсәткече – цитаталар китерүнең тематик индексы (ЦТИ). Бу елның беренче кварталында «Медиалогия» компаниясе «Татар-информ» МАны Татарстан Республикасы матбугат чаралары арасыннан цитаталары иң еш кулланыла торган чара дип таныды. Ел дәвамында ЦТИ буенча без ике тапкырга үстек.

Безгә уңышлы булу өчен, әлбәттә, Татарстанның илдә иң актив регион булуы ярдәм итә. Кайчагында республикада көненә берничә чара үтә, еш кына – бөтенроссия күләмендә дә. Әлбәттә, бу вакыйгаларны яктыртып, без дә мәгълүмат дулкынында югары күтәреләбез. Болар бар да безнең хәрәкәтләребезне тизәйтә.

- Цитаталар китерүнең тематик индексы (ЦТИ) буенча «Татар-информ» МА Татарстанда – **беренче**, Идел буе төбәгендә **өченче** урында тора.
- Бер ел эчендә «Татар-информ» МАның татар версиясе уникаль катнашучылар санын уртача **7,5 тапкырга** арттырды.

Tatar-inform.tatar сайты бөтен позицияләр буенча интернетның татар телле сегментында беренче урында тора. Монда керүчеләр санының үсеш динамикасы рус телендәгесенә караганда тагын да югарырак – җиде тапкырга ук. Дөресен генә әйткәндә, без мондый ук гаҗәеп нәтиҗәне көтмәгән дә идек.

– Социаль челтәрләрдә шундый ук уңышлар бармы?

– Трафикның көчле үсешен чагылдыручы социаль челтәрләрдәге эш – агентлыкның өстенлекле бурычларыннан берсе. Соңгы елда безнең социаль челтәрләрдәге сәхифәләргә керү 13 тапкырга артты. Соцчелтәрләр өчен визуаль контентлар булдыру буенча махсус бүлек булдырылганын әйткән идем инде. Бу бик мөһим юнәлеш. Яшьләр бүген газета укымый, телевизор карамый, радио тыңламый. Алар интернетта, социаль челтәрләрдә яши. Шуңа күрә бу аудитория өчен традицион матбугат чараларыннан аерылып торган, «башка телдә» яңгыраган махсус контент булдырырга кирәк. Символлар, кыска җөмләләр, кыска видеолар теле белән. Шушы юнәлештә үсәчәкбез.

PRESSA.RU

«БЕТАР» ҖКФ ҖЧҖ 1996 ЕЛДАН БАШЛАП ЭНЕРГИЯ РЕСУРСЛАРЫ (СУ, ГАЗ, ҖЫЛЫЛЫК, ЭЛЕКТР ЭНЕРГИЯСЕ) ИСӘПЛӘҮ ПРИБОРЛАРЫ ҖИТЕШТЕРҮ ҺӘМ САТУ БУЕНЧА ӘЙДӘП БАРУЧЫЛАРНЫҢ БЕРСЕ БУЛЫП ТОРА.

Эшчәнлек юнәлешләре:

1. Энергия ресурсларын исәпләү приборлары җитештерү
- тулы циклы җитештерү
- машина төзелеше тармагын дөнья күләмендә төп җитештерүчеләрне җиһазлар белән тәэмин итү

2. Пластмассаларны басым астында кою
- машина төзелеше тармагында дөньякүләм әйдәп баручыларның 40 тан артык өр-яңа термопластавтоматы
- җибәрүнең күләме 8 см³ дан 1155 см³ га кадәр

3. Кою формаларын проектлаштыру, хәзерләү һәм ремонтлау
- пресс-формаларның төрләре: кайнар каналлы һәм салкын каналлы кою системалары
- ресурс: 500 000 һәм аннан күбрәк тоташтыру

4. Югары төгәллекле роботлаштырылган махсус системалар һәм автоматлаштырылган җитештерү линияләре проектлаштыру һәм эшләп чыгару.

Казанышлар:

- фирманың Россиянең 69 төбәгендә, шулай ук якын чит илләр – Белоруссия, Казахстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Монголиядәге вәкиллекләре;
- сыйфат өлкәсендә ике тапкыр Россия Федерациясе Хөкүмәте премияләре конкурсы лауреаты;
- фирма менеджменты системасы алты стандарт (ISO* 9001, ISO/TS** 16949, ISO 14001, OHSAS*** 18001, ISO 50001, һәм шулай ук ГОСТ Р**** 56404) таләпләренә туры китереп сертификацияләнгән.

БЕТАР BETAR®

Контактлар:
www.betar.ru,
e-mail: info@betar.ru

Реклама

* ИСО, ** ТС, *** ОХСАС, **** П

ЦИФРЛЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ҮЗӘГЕ: ИДЕЯДӘН – ӘЗЕР ПРОДУКТКА КАДӘР

Заманча инжиниринг үзәге Казанда 2014 елның ахырында Татарстан Хөкүмәте һәм РФ Икътисадый үсеш министрлыгы ярдәме белән оештырылды. Югары технологияле җитештерү өлкәсендәге бизнес үзенчәлекләре турында журналыбызга «Цифрлы технологияләр үзәге» (ЦТҮ) АҖнең генераль директоры Эльбрус Мәһдиев сөйли.

– Эльбрус әфәнде, мондый компания булдыру теләге ничек туды һәм аның башкалардан көндәшлекле өстенлеге нидә?

– Мондый идеяне базар үзе күрсәтте: киң даирә кулланучылар өчен коелма эшләнмәләрне югары технологияләр кулланып җитештерү мөмкинлекләре бөтенләй юк иде. Бернечә тармакны берләштергән өлкәдә комплекслы мәсьәләләр барлыкка килү сәнәгатьтән мөмкин кадәр кыскарак эш циклы, арзан бәяләр һәм продукциянең югары сыйфатын таләп итә. Һәркем куллана алырдай мондый җитештерү объекты Россиядә башка юк икәнен дә әйтә алам. Һәм бу, һичшиксез, үзәкнең бик зур өстенлеге булып тора.

– ЦТҮ эшчәнлеген ике өлешкә бүлеп карарга мөмкин: эретеп кою һәм хезмәт күрсәтү. Шуларны тормышка ашыру өчен үзәк иң заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән. Әнә шулар һәм компаниянең җитештерү өлкәсендәге технологияләре турында сөйләгез әле.

– Әйе, без үз тармагыбызда хәзер кече һәм урта эшкуарлык предприятиеләре сатып алырлык иң алдынгы җиһазлар белән эш итәбез. Бүген компаниябез цифрлы технологияләр нигезендә бик төгәл эретеп кою, өч үлчәмдәге басма, сканлаштыру һәм аннары продукцияне сыйфат ягыннан сертификацияләү юнәлешендәге тәҗрибә-эксперименталь җитештерү белән шөгыльләнә. ExONE[1] немец компаниясенең сәнәгый **SMAX**[2] **3-D принтеры** эретеп кою өчен нигез әзерләп тормау мөмкинлеге бирә, ә аны эшләү технологик яктан бик катлаулы. Машина бер тапкыр кулланыла торган теләсә нинди катлаулылыктагы калып геометриясен ком һәм фуран сумаладан катлам-катлам салып ясый. Әлеге калыпка металл (алюминий, корыч, чуен, магний) агызыла һәм деталь әзер дә. Төрле ассортименттагы номенклатуралы һәм берьюлы әзерләнә торган аз сандагы детальләр өчен мондый технология шактый әһәмиятле өстенлекләргә ия: эшләп чыгаруның югары тизлеге (2–12 атна урынына – 1–2 көн), сыйфат һәм көндәшлеккә сәләтле бәя.

Илебез өчен тиңдәшсез комплектациядә сатып алынган **GE v|tome|x**[3] **c450 компьютер томографы** төрле кимчелекләрнең рентген анализын, тикшерелә торган объектларның өч үлчәмдәге сурәтен ясарга һәм эретеп коелган эшләнмәләрнең ватмыйча гына башкарыла торган сыйфат контролен уздырырга мөмкинлек бирә. Мисал өчен, былтыр безнең Үзәккә, Енисейда һәлакәткә юлыккан Ми-8Т вертолетының винт төенен тикшертү өчен, Дәүләтара авиация комитеты мөрәҗәгать итте. 10 көн эчендә үз җиһазларыбызда агрегатның эчке өлешләрен анализлап, барлык эчке элементлар күрсәтелгән катлаулы 3D-модель төзеп бирдек.

Лазерлы **ATOS III TRIPLE SCAN XL**[4] **3D-сканеры** һич чикләнмәгән диярлек зурлыктагы теләсә нинди эшләнмәне 2 микронга кадәр төгәллек белән цифрлы форматка күчерергә мөмкинлек бирә.

Исәп-хисап эше махсус санау кластерында 4 терафлопс куәтле суперкомпьютер ярдәмендә башкарыла, бу исә процессларның (мәсәлән, эретеп кою өчен катнашманы салу һәм аның кристаллашуы) математик модельләштерү этабы өчен вакытны сизелерлек киметергә мөмкинлек тудыра.

Бүген без һәркем белән хезмәттәшлеккә әзер, моны «Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе» ГАҖ, «М.П. Симонов ис. ТКБ» Фәнни-җитештерү берләшмәсе АҖ, «ВИАМ» ФДУП, «Агат» ГМЗ ААҖ, «ИТЛАН» ҖЧҖ кебек эре ширкәтләр белән уртак проектларны уңышлы тормышка ашыру тәҗрибәсе раслый.

Якындагы планнарда – Бөек Петр ис. Санкт-Петербург политехника университеты белән зур күләмле «Киләчәк фабрикасы» проектында катнашу. Анда без «Акыллы фабрика» ролендә чыгыш ясыйбыз. Шулай ук «Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе» ГАҖ белән Идел буе төбәгендәге биш заводны үзгәртеп кору мәсьәләсендә эшне дәвам итәргә исәплибез.

ЦТҮ хезмәтләре:

- Эретеп кою
- 3D басма
- Инжиниринг
- 3D сканлаштыру
- 3D модельләштерү
- Компьютер томографиясе
- Компьютерда модельләштерү
- Лаборатор тикшеренүләр
- Реверсив инжиниринг

«Цифрлы технологияләр үзәге» АҖ
Тел.: (843) 204-75-05, 570-82-07,
e-mail: info@kcdt.ru www.kcdt.ru

Реклама

[1] ЭксОНЕ, [2] СМАКС, [3] ГЭ в|томе|х, [4] АТОС 3 Трипл Скан Экс Эл.

PRESSA.RU

Реклама 16+
www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Хәзәр каганлыгы
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
WWW.PROTATRSTAN.RU

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Балалар йортлары **НИГӘ** ябыла

Казанны **НИЧЕК** җәяү йөреп чыгарга

Татарстанда **НИНДИ** милли ашлардан авыз итәргә була

Иң тәмле корт **НӘРСӘДӘН** ясала

PRESSA.RU

ЧИТ БАЛАЛАР БУЛАМЫ?

Соңгы өч елда республикада дүрт балалар йорты ябылган. Тагын икесен ябу турында сүз бара. Бу илдә барган сәясәт белән бәйле: «Бала гаиләдә яшәргә тиеш!» Бөтен балаларны да гаиләләргә урнаштырып бетерү мөмкинме, ә иң мөһиме – кирәкме? Медальнең ике ягын да «әйләндереп», шушы теманы өйрәнергә булдык.

Автор:
Руфия Фазылова

БУЛАЧАК АТА-АНАЛАР ӨЧЕН... МӘКТӘП

2012 елдан башлап, тәрбиягә бала алырга теләгән ата-аналар махсус курслар узарга тиеш. Аның өчен Казанда аерым мәктәп эшли. Рәсми исеме: «Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру үзәге». Бирегә республиканың төрле районнарыннан киләләр. Биш ел эчендә 1500ләп кеше укыган мәктәптә.

– Бала алырга теләгән кешеләр, иң беренче чиратта, үзләре яшәгән районның опека һәм попечительлек бүлегенә мөрәҗәгать итәргә тиеш, – дип сөйләде үзәк директоры урынбасары Татьяна Трушкова. – Закон буенча, 18 яше тулган, шул ук вакытта яшәү, эш урыны булган гражданнарга опекун булырга рөхсәт ителә. Мисал өчен, бүген бездә курсларда егерме яшьлек егет укып йөри. Танышларының 14 яшьлек улын опекунлыкка алырга җыена ул. Яшүсмер малайның әтисе юк, әнисе тәртипсез тормыш рәвеше алып бара икән. «Үсмер урам тәрбиясендә үсә, моның начар тәмамлануы бар», – ди егет, танышы өчен борчылып. Үзәктә өч юнәлештә эш алып барыла: социаль-юридик, медицина, психология. Беренчесендә документлар белән эшләү тәртипләрен өйрәтәбез, булачак ата-аналарга хокукларын аңлатабыз. Икенче бүлектә авыру балаларның сәламәтлеге, җенси тәрбия турында сөйлибез. Бу өлкә дә бик мөһим. Күп вакыт балалар йортында тәрбияләнгән бала чикләрне аңламый. Чөнки анда аларга: «Чалбарыңны төшер, укол ясыйм», «Авызыңны ач, дару каптырам», – дип боерып торалар. Баладан рөхсәт сорап, аңлатып тору юк, ул аны шулай булырга тиеш дип кабул итә. Кызганыч, балалар йортында тәрбияләнгән балаларда үзләрен җенси яктан яклау инстинкты бик булмый. Ата-ананың бурычы – балага аңлату: җенси әгъзаларыңа, эчке киемнәреңә берәү дә кагылмасын. Гомумән, өлкәннәр җитлегеп килгән баланың бүлмәсенә ишек шакымыйча керергә тиеш тә түгел. Бу – аның мәйданы, бала шуны тоеп үссен.

Өченче бүлек, сәгать саны буенча иң озыны, бирелә тәрбиягә алган балалар белән нинди проблемалар туарга мөмкин булуын аңлатабыз. Күп очракта бала алырга теләгән өлкәннәр үзләрендә идеаль образ тудыра, булачак ул-кызлары менә шундый булырга тиеш, дип исәпли. Тик беркайчан да хыялдагыча гына барып чыкмый: баланың үз холкы, капризлары, омтылышлары... Ата-ана боларны аңларга, моңа алдан әзер булырга тиеш. Психологик тренинглардан соң кайбер ата-аналар, тәрбиягә бала алу уеннан кире кайта.

Без исә шатланабыз гына, димәк, алар әзер булмаган. Әле яхшы, шуны аңлаганнар, югыйсә баланы алгач, кире китерерләр иде.

«Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру үзәге» 2014 елның азагына кадәр балалар йорты булып саналган. Малай-кызларны гаиләләргә урнаштырып бетергәннән соң, башкаланың Киров районындагы ике катлы әлеге бина буш калган. Бүгенге көндә, үзәкнең беренче катында булачак ата-аналар дәресләр укыса, икенче катында, әти-әнисез егет-кызлар яши.

– Кызганычка каршы, балалар йортында малай-кызлар унсигез яшькәчә генә яши ала, – дип сөйләде Татьяна Трушкова. – Аннан алар үз көннәрен үзләре күрергә тиеш. Әйе, яшәү урыны булмаганнарга дәүләт тарафыннан торак бирелә. Ләкин кайбер очракларда фатир артыннан йөрү еллар буена сузыла. Яки икенче очрак: балалар йортында үскән егет-кызның рәсми рәвештә тору урыны бар, тик анда аның сәрхүш туганнары, икенче кешеләр яши. Балага анда яшәргә мөмкинчелек юк. Бу очракта ул нишләргә тиеш?! Фатир арендалап яшәргә аның акчасы җитми, берәр җирдә укыса яки эшләсә дә, торак өчен түли алмаска мөмкин. Менә шундый хәлгә тарыган егет-кызлар безнең үзәккә килеп яши. Алар биредә ашау-эчү ягын үзләре карый, әзерли, сатып ала. Иганәчеләр чәй, шикәр комы, башкасын алып килә. Бүгенгесе көндә үзәктә алты кеше яши. Закон буенча егет-кызлар монда бер ел гына булырга тиеш. Әлбәттә, барыр урыны булмаса без аларны куып чыгармыйбыз. Тормышлары җайланганчы яшиләр.

ТӘРБИЯГӘ УН БАЛА?!

Яшерен-батырын түгел, булачак ата-аналарның күбесе сау-сәламәт бала алырга тели. Бу аңлашыла да кебек, сүз куертып торырга кирәкми дип уйлыйм. Тәрбиягә сәламәт бала алган очракта да күпме көч кирәк, ә авыруга исә... Шулай булса да андый балаларны тәрбиягә алган кешеләр дә бар. Мисал өчен «Ярдәм» хәйрия фондын оештыручыларның берсе, бүгенге көндә аның җитәкчесе булган ханым – Мәликә Гыйльметдинова ун бала анасы. Малай-кызларның барысының да сәламәтлекләрендә кимчелекләре бар: аутист, Даун синдромы, церебраль паралич...

– Тәрбиягә алыр алдыннан бер баламны да барып карамадым, – дип сөйләде Мәликә ханым. – Аллаһы Тәгалә кемне җибәрә, шулар булсын дидем. Ә ният күптән бар иде. Үземнең балалар үсеп беткәч күңелдә булган бу уйны тормышка ашырасым килде.

Мәликә апа балаларны ялгызы гына үстерми, ярдәмчеләре бар. Ул үзе дә «без» дип сөйләшә, чөнки бу изге эшкә «Ярдәм» фонды белән берлектә алынганнар. Балалар өчен Теләче районы Иске Җөри авылында махсус зур йорт сатып алганнар. Монда барлык мөмкинлекләр дә бар: мунча, бакча, ашханә, аерым йокы бүлмәләре. Үзенә күрә бер кечкенә балалар йортын хәтерләтә ул. Балалар Мәликә Гыйльметдиновага «әни» диеп эндәшә. Бер гаиләдән булган ике, өчәр бала да бар.

– Ни өчен авыру бала алырга булдыгыз? – Мәликә апага бу сорауны бик күпләр бирә икән. Ун бала анасының җавабы гади:

– Сау-сәламәт балаларны тәрбиягә алыр өчен чират көтәргә кирәк. Минем исә кемне дә булса шул минутта ук бәхетле итәсем килде. Өстәвенә, Теләче районында йортыбыз әзер булды, озакка сузмаска дип уйлаштык.

Мәликә Гыйльметдинова, үз тәҗрибәсенә таянып, тәрбиягә бала алган гаиләләргә психологик-педагогик киңәшләрдән торган китап та чыгарган. Педагогик, дини белемгә ия булган әлеге ханымның нәрсәләр аша узганын ишеткәч, чәчләр үрә тора:

– Башта өч баланы Менделеевск районыннан алып кайттык. Әниләрен алар алдында пычак белән кадап үтергәннәр. Бу сабыйларның нәрсә кичергәнен

PRESSA.RU

аңлау өчен психолог булырга кирәкми. Яннарыннан да китә алмыйм, калдырып китмә, дип кычкырып елыйлар. Төннәрен йокламыйлар, баштарак саклап чыга идек. Ә Яшел Үзән балалар йортыннан алган өч бертуганны әниләре капчыкка салып чүплеккә ташлаган булган. Сабыйларның исән калуы могҗизага тиң. Аларны этләр авызыннан тартып алганнар. Менә шушы балаларны кеше итү өчен никадәр җан җылысы, сабырлык, көч кирәк икәнлеген үзегез аңлагыз. Ләкин мин бу адымга еллар буе әзерләндем, барысын уйлап, аңлап эшләдем.

Мәликә апа, балалар гаиләдә үсәргә тиеш дип саный. Фикерен болай дип дәлилләде:

– Балаларыбыз күзгә күренеп үзгәрде. Кайберләре, безгә кайтканда, зур яшьтә булуга карамастан, йомышларын да йомышлый белми иделәр. Сөйләшү, тулы җөмләләр төзү турында әйтмим дә. Аларны дәвалау өчен кая гына алып бармадык. Бүген, Аллага шөкер, ике баладан инвалидлык төркемен алдылар, ул-кызларыбыз күзгә күренеп үзгәрә.

Мәликә апаның тәрбиягә алган улы белән кызы быел һөнәр училищесын тәмамлый, үзләре гаилә корырга җыеналар икән. «Менә аларга дәүләттән фатир алуны юллап йөрим», – диде. Изге күңелле бу ханым яңа уйлар, ният белән яши: балалар йортыннан тагын берничә авыру сабый алып, аларны кеше итеп олы тормышка аяк бастыру.

«АЛАР ЯКЛАНМАГАН»

Балалар йортында үскән бер танышым бар: әти-әнисе вафат булганнан соң, дүрт бертуган калганнар. Аларның үзара җылы мөнәсәбәтен, бер-берсен кайгыртып яшәүләрен күреп, таң калабыз. Интернат-мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, югары белем алып, тормышта үз урынын тапкан хөрмәтле ханым ул.

– Әле ярый берәрсе тәрбиягә алмаган, – ди танышым. – Чит кешегә ата-ана итеп мәңге карый алмас идем. Күпләр балалар йортында яшәүне начар, куркыныч итеп күзаллый. Юк, анда барыбыз да тигез булдык. Тәрбияче апалардан кыерсыту күрмәдек. Алар безне һәр эшкә өйрәттеләр. Тәрбиягә алсалар, нинди гаиләгә эләгер идек, әле туганнардан да аерсалар… Шуңа күрә мин балалар йортларын бөтенләй ябып бетерү тенденциясенә каршы.

Лаеш балалар йорты җитәкчесе Рузалия Вәлиуллина да әлеге фикерне куәтләде:

– Ни өчендер халык, балалар йортын караңгы итеп күрә. Беренчедән, шуны әйтим, урта хәлле гаиләләрдә дә балалар мондагы кебек яхшы тукланмый. Икенчедән, балалар тормышка яраклашырга өйрәнә, авырулар сауларга булыша. Кайчакта өлкәннәр арасында андый яхшы мөнәсәбәт булмый. Ә бертуганнарның бер-берсе өчен кайгыртуларын күреп, күзгә яшьләр килә. Күп еллар бу өлкәдә эшләгәч тоемлавым бар: кайберәүләр, балаларны тәрбиягә эш итеп карап, акчасы өчен генә ала. Малай-кызлар мондый ният, максатны тиз аңлый, яхшы психолог алар. Әле бездә үскән бер балам килгән иде: «Рузалия апа, мин башка түзә алмадым. Үги әнигә: «Сез мине яратмыйсыз, кырын карашларыгыздан тойдым», – дип әйттем». Дөресен генә әйткәндә, ул гаиләдә хәлләр шулайрак тәмамланачагын чамалый идем. Бер ханым, дүрт ел элек үсмер малайны тәрбиягә алды. Үз улы да аның яшендә иде. Бергә укырлар, бергә үсәрләр дип, башта куандым. Тик кызыксына торгач, ана кеше балаларны аерганын аңладым. Хәтта үги бала белән икенче тонда сөйләшә. Моны мин генә түгел, укытучылар да күргән. Закон буенча, тәрбиягә алган баланы ата-ана какмаса, сукмаса, ашатса, киендерсә, шул җиткән. Ә аның эчке дөньясы, күңел халәте турында уйлап торыш юк. Шуңа күрә гаиләгә киткән һәр бала да бәхетле була диген сүз түгел әле.

Рузалия апа Вәлиуллина Лаеш балалар йортында утыз ел эшли. Аларда тәрбияләнеп, бүгенге көндә менә дигән итеп яшәп яткан бик күп егет-кызларны мисалга китерде. Миндә исә бу ханымга карата соклану, хөрмәт уянды: чын мәгънәсендә гомерен ятимнәргә багышлаган. Ул балаларның аннан соңгы тормышлары белән дә кызыксынып яши. Мәктәпне тәмамлагач, аларны Россиянең төрле шәһәрләренә укырга урнаштырырга үзе бара. Һәм студент булган үсмерләр җәйге каникулларда балалар йортына кайтып яши.

Ятимнәр дөньясын төптән аңлаган, белгән ханым тагын бер фикере белән уртаклашты:

– Балаларны гаиләдән алуга каршы мин. Кайвакыт, эшләми дип, эчкече, тәртипсез тормыш рәвеше алып бармаган ата-аналардан да балаларны алалар. Еш кына күп балалы була ул гаиләләр. Бөтен әйбер кыйммәт, ата-ана җиткерә дә алмаска мөмкин. Ә опека идарәләренең эше җайлы: баланы алырга! Ә бәлки ул гаиләгә ярдәм итүне уйларга кирәктер. Чит баланы үстергән кешегә дәүләт 8 мең сумнан артык акча бирә, ә күп балалы гаиләгә пособие мең сум да юк...

Республика балалар йортларында бүген балалар саны аз калган, һәркайсында, күп дигәндә, 30–40 бала тәрбияләнә. Татарстанлылар балаларны тәрбиягә чират торып ала. Андый гаиләләрнең иң күбе Яшел Үзән районында яши икән.

– Тәрбиягә алынган балалар белән бәйле фаҗигаләрнең республикада булганы юк, барысы да тәртиптә, – дип тынычландырды мине ятимнәр тормышы өчен җаваплы җитәкчеләр. Берүк шулай гына була күрсен.

Бу теманы ныклап өйрәнгәч, тагын шуңа инандым: балалар йортында яшәп тә бер диген кеше булып җитлегеп була. Киресенчә, наз күрми гаиләдә тәрбияләнеп тә ябык, дөньяга ачулы кеше булып үсү мөмкинлеге бар. Әйе, баланың кайда яшәве мөһим түгел. Иң мөһиме – юлында аны яратучы, аңлаучы, дөрес юл күрсәтүче кешесе булсын. Шул очракта ул тормышта үз урынын табып, менә диген итеп яшәр.

Бүген Татарстанда әти-әни назыннан мәхрүм калган 11 мең 717 бала бар, аларның 11 мең 150се гаиләләргә тапшырылган. Тәрбиягә алынган баланың алдагы тормышын җирле опека һәм попечительлек бүлекләре тикшерә, дөресрәге, бу эшне бары алар контрольдә тота.

Тәрбиягә бала түбәндәге очракларда бирелми:
– психика белән бәйле авырулары булган затларга;
– закон бозган өчен җавапка тартылучыларга;
– каты авырулары (онкология чире, гариплек) булган кешеләргә.

Зөлфия Мөсабирова, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге җитәкчесе:

– 2017 ел башына республикада 0 дән 17 яшькәчә 795 мең 959 малай-кызлар исәпләнде. Ни кызганыч, балаларның 1,4 проценты ата-ана назыннан мәхрүм ителгән. Соңгы елларда бездә тәрбиягә бала алган гаиләләр институты зур үсеш алды. Шуңа да ата-анасыз калган малай-кызларның 95 проценты гаиләләрдә тәрбияләнә. Иң беренче чиратта, үксезләрне туганнарына бирергә тырышабыз: дәү әни, дәү әтиләр, абый-апалар. Туганнарында тәрбияләнүче балалар барлык ятимнәрнең 70 процентын тәшкил итә.

Республикада ата-ана назыннан мәхрүм ителгән балалар өчен 13 дәүләт учреждениесе бар. Аларда 485 малай-кыз тәрбияләнә. Максат – мөмкин кадәр күбрәк баланы гаиләләргә тапшыру. Бала гаиләдә үссә, яхшырак. Моны тәҗрибә күрсәтте. Ә опека, попечительлек бүлекләренең эше – тәрбиягә бала алган гаиләләрне «энә күзеннән үткәрү». Гадәттә, бу эш җирле опека, попечительлек бүлекләренә тапшырыла, чөнки авылда, районда нәрсә булганын алардан яхшы күрүче юк. Шулай ук балалар бакчасы, мәктәпләр, фельдшер да тәрбиягә алган балаларга күз-колак була.

Гүзәл Удачина, Татарстан Республикасында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:

– Россия Көнбатыш үрнәгенә таянып эшли: анда балалар йортлары юк. Без дә акрынлап шуңа таба барабыз. Чынлап та, гаиләдә үскән бала тормышка күбрәк яраклашкан була, монысы бәхәссез.

Тәрбиягә алган балаларның хокукларын яклау дигәндә, безнең җәмгыять кирәгеннән артык уяу. Мисал өчен, мәктәпкә килгән бер баланың чалбары пычрак ди. Әгәр ул үз ата-анасы белән яши икән, пычрак чалбарга берәүнең дә исе китмәячәк, ә тәрбиягә алынган баланыкына, әлбәттә, игътибар итәләр... Укытучылар, ата-аналар, хәтта опека бүлекләренә кадәр барып әйтергә мөмкиннәр. Әлбәттә, бер яктан караганда, бу уңай күренеш, җәмгыять үксезләргә битараф түгел. Ләкин икенче яктан, тәрбиягә бала алырга теләгән ата-аналарны мондый контроль куркыта да.

Без тагын шуны аңлыйбыз: гаиләдә яши алмый торган балалар була, һәм алар бар. Беркемне дә үз ата-анасы итеп кабул итә алмый ул балалар. Менә шундыйлар өчен балалар йортлары, приютлар булырга тиеш. Шуңа күрә ятимнәр йортларын бөтенләй ябу турында сүз бармый.

PRESSA.RU

мәдәни маршрут:

КАЗАН

Конфедерацияләр кубогының тыгыз, кызыклы спорт программасын кабатланмас, үзенчәлекле мәдәни программа белән дә үреп алып барырга киңәш итәбез. «Кая барырга?» дигән мәңгелек сорауга үзебез йөреп чыккан сәяхәт маршруты белән җавап кайтарырга булдык. Тик алдан ук кисәтеп куябыз: бу – Казанда күрергә мөмкин булган урыннарның бик аз өлеше генә.

ИСКЕ КАЗАННЫҢ ЙӨРӘГЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры каршындагы «биюче» фонтаннарга сокланып, Кабан күленнән искән тымызык җилдән иркәләнеп бераз йөреп алгач, янәшәдәге генә Иске Татар бистәсенә юл тотарга киңәш итәбез. Бер дә арттыру түгел: бу – башкалабызның тарихи йөрәге типкән урын. Бүген исә ул йөрәк – җырлый! Мондагы берничә урам милли мәдәниятебез һәм архитектурабызның соклангыч үрнәге булып тора, һәрбер йорт истәлекле даталар һәм күренекле шәхесләр белән бәйле хәтерне саклый. Дистәләгән тарихи объектны манзара кыла алачаксыз бирелә. Алар арасында татар сәүдәгәрләренең, шулай ук интеллигенция һәм сәнәгатьче затларның йортлары да, мәчет-мәдрәсәләр дә, татар укытучылар мәктәбе һәм атаклы Шәрык клубы да бар. Кайчандыр монда хәзерге классикларыбыз дип исәпләнгән шагыйрьләр үз шигырьләрен укыганнар, татар театры баш калкыткан. Җыйнак, күркәм урамнардан йөреп хозурлангач, бистәдәге ресторанга керергә дә онытмагыз. Татар мәдәниятенең «тәме» нинди икәнен шулчакта гына чын-чынлап тоячаксыз (тулырак мәгълүмат – безнең кулинар маршрутта).

Адрес:
Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Нәриманов, Сафьян, Солтанов урамнары

Ничек барып җитәргә:
«Тукай мәйданы» тукталышына кадәр метро белән барырга, аннары Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрына кадәр – җәяүләп

КАЗАНДАГЫ БЕРЕНЧЕ ГЛАДИОЛУСЛАР

Узган гасыр башында интеллигенция ничек яшәгән? Бу хакта белергә теләсәгез, шәһәребездәге бер йортка чакырабыз – анда XX йөз башы рухы хөкем сөрә бүген дә. 1916 елдан бу йортта Казаныбызның күренекле химиклары – академик Арбузовлар яшәгән. Йортның тышкы кыяфәте генә түгел, ә эчке торышы да алар яшәгән чордагыча сакланган. Монда күрергә мөмкин барлык предметлар да кайчандыр Арбузовларныкы булган: җиһазлар да, савыт-саба да, шәхси әйберләр дә, хәтта гаилә документлары да – һәммәсе сакланган. Бухгалтер кенәгәләре, гимназист көндәлекләре дисеңме…

Җәйге веранда баскычлары буйлап мемориаль бакчага төшеп була. Монда сез аспиринны ачкан җирле галимебез үз куллары белән утырткан агачлар белән куакларны гына түгел, ә ул ясаган түтәлләрне, чәчәклекләрне дә күрә аласыз. Сүз уңаеннан, Арбузов Казанда гладиолуслар үстерә башлаган тәүге кеше була.

Адрес:
Катанов тыкрыгы, 8 йорт

Ничек барып җитәргә:
«Тукай мәйданы» тукталышына кадәр метрода барырга, аннары Бутлеров урамы буйлап Маяковский чатына кадәр күтәрелергә, 150 метрдан соң, уңга борылырга кирәк



КОШ БИЕКЛЕГЕННӘН КАРАСАК...

Күз явын алырдай Казаныбызның кош очкан биеклектән ничек күренүен күгәрченнәр генә түгел, без үзебез дә күзәтә алабыз. Шәһәрдәге иң биек корылмаларның берсенә – Богоявление соборының чиркәү манарасына менсәк, Казанның тарихи урыннарын 70 метр югарылыктан манзара кылырга мөмкин. Билгеле, тар һәм бик үк уңайлы булмаган баскычтан озаклап менәргә кирәк булачак, әмма һич тә үкенмәссез: башкаланың күзне иркәли торган гаҗәеп панорамасын бары тик шул карау мәйданчыгыннан гына күзәтеп була. Богоявление соборы Татарстанның энҗесе исәпләнә. Архитектура үрнәге буларак, ул XVIII гасыр рус бароккосына карый, һәм бу стильнең иң матур төзелмәләре рәтенә керә. Ул бик күп тарихи вакыйгаларны хәтерендә саклый. Мәсәлән, нәкъ менә шушында бәләкәй Федя Шаляпинны чукындыралар. Үсә төшкәч, яшь даһи беренче чыгышларын мондагы чиркәү хорында ясый.

Адрес:
Бауман урамы, 78 к1 йорт

Ничек барып җитәргә:
«Тукай мәйданы» тукталышына кадәр – метрода, аннары Бауман урамы буйлап җәяү барырга кирәк

КАЗАНЫБЫЗНЫҢ ГОРУРЛЫГЫ

Сюрреализм һәм экспрессионизм, борынгы чорлар һәм бүгенге заман, пейзажлар һәм портретлар, әкият сюжетлары һәм яуларны чагылдырган киң колачлы сурәтләр – барлыгы 400дән артык киндер! Әнә шундый мирас калдырган безгә илебезнең иң киңкырлы талантка ия рәссамнарының берсе – Константин Васильев. Кайчандыр Казаннан ерак булмаган бистәләрнең берсендә яши ул. Бистәнең исеме, әйтерсең, махсус аның исеменә тәңгәл итеп сайланган – Васильево. Казан сәнгать училищесын тәмамлаганнан соң, Васильев Казанның бер рәсем мәктәбендә гап-гади укытучы булып эшли. Казанда аның картиналар галереясы күптәннән булдырылса да, музее әле берничә ел элек кенә ачылды. Музейның биш иркен залында рәссамның иҗат мирасына караган төп эшләре тәкъдим ителгән – барлыгы 160 киндер. Әмма музей булгач, ул, билгеле, иҗат белән генә чикләнми. Биредә сез рәссамның шәхси әйберләре урнашкан почмакны да карый аласыз, шулай ук аның китапханәсе белән архивы да саклана музейда.

Адрес:
Бауман урамы, 29 йорт

Ничек барып җитәргә:
«Тукай мәйданы» тукталышына кадәр – метрода, аннары Бауман урамы белән Астрономическая урамы чатына кадәр җәяү барырга кирәк

«Северный орёл». Константин Васильев.

PRESSA.RU

КАЗАН КРЕМЛЕ –

Килми һәм күрми калмагыз! Әгәр сез Казан Кремлендә булмагансыз икән, димәк, Татарстанда да булмагансыз, аның тормыш ритмын сизмәгәнсез, тарихына кагылмагансыз, киләчәккә омтылышларын тоймагансыз дигән сүз. Биредә, Кремль калкулыгында, бүгенге көндә безнең тарихыбызның, күпмилләтле республикабызның мәдәнияте һәм рухиятенең үзәк ноктасы булган урында, аның йөзләрчә еллар элек салынган башлангычы саклана.

ГАСЫРЛАР ТИРӘНЛЕГЕННӘН

Безнең борынгы бабаларыбыз яшәгән җирләр әллә никадәр ачылмаган серләрне саклый әле. Рәхимсез вакыт хан сарайларын да, китапханә һәм мәдрәсәләрне дә, хан төрбәләрен дә кызганмаган. Әмма соңгы дистә еллардагы фән казанышлары тарихыбызның онытылган сәхифәләрен ачты. Казан Кремлендә XX–XXI гасыр чикләрендә үткәрелгән археологик тикшеренүләр безнең шәһәрнең яшен билгеләүне дәлилләү өчен нигез булып кына калмады, моңарчы күп гасырлык мәдәният катламнары астында яшеренеп яткан борынгы объектларны да ачарга мөмкинлек бирде. Соңгы ханбикә Сөембикә исемен йөрткән манара астында археологик тикшеренүләр вакытында ханнар мавзолее табылды. Һәм монда, әйтерсең лә, халык хәтерендә сакланган риваять җанлана: Сөембикә ханбикәнең, Мәскәүгә, «мактаулы әсирлек»кә озатылыр алдыннан ире Сафа-Гәрәй хан кабере янында елавы күз алдына килеп баса.
Хакимнәр һәм дәүләт төзелеше үзгәреп торуга кармастан, киң җәелгән төбәк белән хакимлек итү үзәгенең гасырлардан гасырларга шушы урында – Кремль калкулыгының төньяк чигендә урнашуы очраклы түгел. Хәзерге вакытта анда Татарстанның дәүләтчелек тарихы музее эшли.

Сез монда беләчәксез:

- Татарлар кемнәр алар.
- Идел буе Болгарстаны шәһәрләре: Биләр, Болгар, Сувар... тарихын. Алар урта гасырның эре шәһәрләре. Әлеге ерак тарихка кагылырга археологлар тапкан артефактлар: савыт-саба, пыяла, бизәнү әйберләре һәм хәтта... кура җиләк орлыклары да булышыр.
- Бөек Болгария һәм Идел буе Болгарстаны нәрсәсе белән аерыла һәм аларның нинди уртак яклары бар.
- Чынлыкта Казан ханнары нинди булган – галимнәр хакимнәрнең йөзләрен модельләштерә, ә скульпторлар аларны металлдан коя алганнар.
- Ни өчен Екатерина II нең зәркәнчеләре озак вакытлар Алтын Урда чоры «алкасының» сыңарын эшли алмаган?

Документаль хроника:

- Казан Кремленең 3D проекциясе Казан ханлыгы чорында аның нинди булганлыгын күрсәтә. Тарихи күренеш галимнәр тарафыннан чын мәгънәсендә бөртекләп җыелган.
- Сәхиб-Гәрәйнең Тархан ярлыгы, яки «хакимлек итүченең паспорты» – Казан ханлыгы чорыннан сакланып калган бердәнбер документ.
- Күлтәгин ташы (стеласы) – заманча технологияләр базарындагы яңалыкларның берсе – уникаль 3D-пойнтер ярдәмендә ясалган интерактив модель.

МЕГАПОЛИСНЫҢ ЙӨРӘГЕ

Идел һәм Казансу арасында, шәһәрнең иң үзәгендә, мегаполисның йөрәге тибә.
Монда һәрвакыт тормыш кайный! Музейлар тормышы гына түгел, фестивальләр тормышы да. Ел саен җылы май кичләренең берсендә Казан Кремле музейлары төнге тормышны сөючеләр өчен үзләренең ишекләрен ача, һәм бөтен шәһәр «Музейда төн» Халыкара акциясе карамагында кала. 1 июньдә, Халыкара балаларны яклау көнендә, борынгы ныгытма әкият патшалык иткән Балачак иленә әверелә... һәм Кремль көн буена балаларның күңелле көлү тавышлары белән тулып тора.
Кремльдәге җәйге вакыйгалар калейдоскобын традицион рәвештә «Казан фанфаралары» Халыкара хәрби тынлы оркестрлар фестивале тәгәлли. 2017 елның 25–26 августларында иң яхшы коллективлар, парад белән Кремль брусчаткаларыннан узып, плац-концертта үз программаларын тәкъдим итәчәк.
Әмма көтелмәгән очрашулар да була. Әйтик, Казан Кремле буйлап йөргәндә, сезнең Владимир Юдашкинны да, Софи Лоренны да, Орнелла Муттины да, Пласидо Домингоны да очратуыгыз һәм Борис Гребенщиков башкаруында җырлар ишетүегез ихтимал. Көтәбез сезне!

МӘДӘНИЯТ НЫКЛЫГЫ



ПРАВОСЛАВИЕ ЭНҖЕСЕ

Бу – Казан Кремле территориясендә генә түгел, шәһәрнең үзендә үк сакланып калган иң борынгы һәйкәлләрнең берсе.

Благовещение соборын төзү урынын 1552 елда Иван Грозный үзе сайлаган.

Өч көн эчендә чатыр рәвешендәге чиркәүне бер кадаксыз төзеп куйганнар, ә тагын бер елдан – ак таштан храм салынган.

Озак вакытлар буена ул безнең якларның төп соборы булып исәпләнгән, әмма аның язмышында да фаҗигале борылыш бар: совет власте елларында ул бушап калган, фрескаларның зур өлеше юкка чыккан.

Хәер, шулай да сез аларның берсен күрәчәксез: алтарь янындагы «Ветхозаветная троица» XVI гасырдан бирле сакланган.

Благовещение соборы тарихы музеена керү өчен 5 сәбәп:

- Екатерина патшаның, Казанга килгәч, ни өчен «Мин лаек түгел» дип, тиарасын салуын белергә.
- Күренекле изге Гурийның дүрт йөз еллык таягын күрергә.
- Могҗизалы Казан Мәрьям Ана иконасының табылу тарихы һәм аның юкка чыгуы белән бәйле әлегәчә ябылмаган җинаять эше белән иркенләп танышырга.
- Ниһаять, Казан Мәрьям Ана иконасының беренчел чагылышын күрергә.
- Иван Грозныйның даирәсендәгеләргә ни сәбәпле сарай этикетын бозып, үзенә арка белән басарга рөхсәт итүен белергә.

АНДА КОРЪӘН ЯҢГЫРЫЙ

Әгәр сез тимер юл буйлап сәяхәт итәргә яратасыз икән, Россия шәһәрләренең күпчелегеннән аермалы буларак, Казан сезне шәһәргә кергәндә үк ачылып китүче гаҗәеп гүзәл күренеше белән шатландырыр. Кич белән аеруча әкияти тамаша көтә: чыршы уенчыгы кебек ялтырап, шәһәрнең кичке манзарасында Казан Кремле күренә, аның үзәгендә Кол Шәриф мәчете күтәрелә. Кол Шәриф мәчете ул – татар халкының Казан ханлыгы чорындагы күп манаралы легендар мәчетне торгызу турындагы хыялының тормышка ашуы билгесе. Кол Шәриф мәчетенең ишекләре һәркемгә ачык. Көн саен биредә мөселманнарны намазга чакырып азан яңгырый; секунд саен әлеге шарык әкиятен хәтерләрендә сакларга теләгән туристларның фотоаппаратлары чертләгәне ишетелә; Ислам мәдәнияте музеендагы мастер-класста катнашкан баланың шатлыклы тавышы – болар барысы да Кол Шәриф мәчетендә.

Ислам мәдәнияте музеенда сез нинди сорауларыгызга җавап таба аласыз:

- Ислам ничек барлыкка килгән һәм ни өчен ул Идел буенда шулай тиз таралган?
- Алтын Урда ни өчен мөселман дәүләте эченә кереп урнашкан һәм бу Россиядә исламның киләчәк тарихына нинди йогынты ясаган?
- Исламда сурәтләр ясауны тыю нәрсә белән бәйле?
- Ибраһим диннәре – ислам, христианлык һәм иудаизмның берлеге һәм аерымлыгы нидә?
- XIX гасырга кадәр татарлар үзләрен кем дип атаган?

Кызыклы экспонат:

- «Битләре ачыла торган интерактив Корьән» сезне Корьәннең басма һәм кулъязма төрләре, гарәп каллиграфиясе сәнгате белән таныштырыр. Шулай ук Изге Корьәннең яңгырашын гарәп телендә ишетергә генә түгел, ә бәлки русчага, татарчага һәм инглизчәгә тәрҗемәсен белергә дә ярдәм итәр.

Реклама

Башы:
«Кремль» метро станциясе.

Ахыры:
В. И. Ленин музей йорты. Сәяхәт якынча ике сәгатькә сузылачак.

КАЗАН: ТАРИХКА СӘЯХӘТ

Экскурсовод җитәкчелегендә «Сулга карагыз, уңга карагыз» дип, манзара кыларга яратканнарны, «Татарстан» журналын култык астына кыстырып, Казан шәһәренең алты кызыклы урынын, ике музеен һәм бер бакчасын карарга чакырабыз.

Автор:
Гадел Хәеров

IНЧЕ ОБЪЕКТ.
ПЁТР I ХӨРМӘТЕНӘ ХРАМ

Метродан чыккач, брусчатка түшәлгән тау буенча күтәреләбез, герой-шагыйрь Җәлил һәйкәле яныннан узабыз һәм Кремль урамына чыгабыз. Артта Казан Кремле кала (сүз уңаеннан, аны аерым карарга була, бу очракта җентекле схема ясалган элмә такта ярдәмгә килер).

Гөмбәзендә сәгать урнаштырылган матур йортка таба атлыйбыз, ул сул якта пәйда булачак. Александр Пассажы – бүгенге сәүдә үзәкләренең элеккеге версиясе, хәзерге вакытта ул – реставрациядә.

Юллар кисешкән чатка килеп җиткәч (Пассаж каршы якта кала), татар шагыйре Муса Җәлил исемен йөрткән кечкенә генә урамга борылабыз һәм бераз гына түбәнгә төшәбез. Чуен койма артында, ишегалдында, гаҗәеп матур Петропавловск соборын күрерсез, ул Казан сәүдәгәре Иван Афанасьевич Михляев акчаларына Пётр I нең Казанга килүе хөрмәтенә салынган.

Россия православие храмнары өчен бик үк гадәти булмаган архитектураны күрәбез биредә: җылы, шатлыклы төсмерләр, бизәкләрендә чәчәк, виноград тәлгәшләре чагылыш тапкан, витражлы тәрәзәләр. Аны Флоренция осталары төзегән. Ул заманнарда Россия буйлап, эш эзләп, кызыл оек һәм очлы башлы туфлиләр кигән мәзәк кыяфәтле итальян «бригадалары» шактый күп йөргән. Әмма флорентиялеләрнең эше, кызганыч, рәтле булып чыкмый: төзелеп бетмәгән собор тиздән җимерелеп төшә. Сәүдәгәр чит ил кешеләрен куып җибәрә һәм чабата кигән үзебезнең балта осталарын һәм ташчыларны: русларны, татарларны, украиннарны, чуваш һәм мариларны яллый. Әлеге гүзәллекне алар тудыра да инде!

Иң элек храмның тышкы ягын тикшерик, соңыннан, террасага күтәрелеп, анда урнашкан карау мәйданына күз салыйк. Биредән шәһәрнең бай һәм төрле архитек-

Фото: Солтан Исхаков



турасына һәм Идел киңлекләренә манзара ачыла. Инде храм эчен дә карап чыгыйк.

Совет чорында чиркәү биналарында Росреставрация остаханәләре урнашканга күрә, язулар һәм бизәкләр, хәтта идәннәрнең чуен плитәләре дә соборның үзенеке сакланып калган. Храмның икенче өлешендә – гадәти булмаган һәм үлчәмнәре буенча тар зал белән ярашмый торган иконостас урнашкан, аны бер карауда гына колачлап бетерү мөмкин түгел.

Пётр Казанга бары тик бер хәрби максат белән генә килә. Ул җирле завод һәм фабрикаларны карап чыга. Адмиралтействоны ача, аның верфьләрендә тиздән озынлыгы 35 метр, палубасында 16 артиллерия тубы булган «Казан» корветы төзеләчәк. Корабль Фарсы иленә походта, Дербент һәм Баку крепостьларын алуда катнашачак. Сукно мануфактурасы хуҗасы Иван Михляев патша флоты өчен җилкәннәр тегүгә «тендер» отачак. Әйтергә кирәк, Петропавловск соборының мәһабәтлегенә һәм гүзәллегенә карап, әлеге хәрби заказ китергән табышның күләме турында фикер йөртергә буладыр!

Соборның эчке ишегалдында сәүдәгәр Михляевның үз йорты сакланып калуы – могҗизага тиң күренеш. Казанга килгән көнне патшага 50 яшь тулган була. Император үзенең юбилеен нәкъ менә биредә бәйрәм итә. Аны тантаналы итеп каршы алалар: 19 төрле ризыктан торган төшке аш, «эчү чиксез күләмдә». Сәүдәгәрчелек Россия флотының үсешенә юмарт акчалар бүләк итә. Кунакчыллыктан җылынып киткән Пётр өстәл артында йорт хуҗасы хөрмәтенә тост әйтә, һәм хәтта сакалыннан тартып китереп, үбеп тә ала. Юма телгә эреп киткән сәүдәгәр, җавап итеп, православие храмы төзү өчен патшаның үзеннән урын сорый.

Ә хәзер Кремль урамына кире кайтыйк һәм алга – университетка таба атлыйк. Вакытыгыз булса, XIX гасыр азагындагы өяз шәһәре атмосферасын саклап калган матур гына ишегалдына (керү юлындагы чуен коймага беркетелгән «КИУ» вензеле «Казан Император университеты» дигәнне аңлата) керергә мөмкин, шулай ук төп бинада урнашкан музейны карап чыгарга була. Биредә артефактлар куелган, мәсәлән, ишек янында торучы һәм студентларның таныклыгын тикшерүче швейцарның киеме һәм таягы; бөек математик һәм университетның беренче ректоры Николай Лобачевскийның язу өстәле һәм идән сәгате. Сәгать телләре инде икенче йөз ел туктамый йөри, борып торасы да юк, дип сөйлиләр, серен исә беркем белә алмый. Ләкин безне хәзер университет каршында торган бина кызыксындыра.

2НЧЕ ОБЪЕКТ. КӘЛӘШКӘ БҮЛӘК

Бина торак йортка караганда шкатулкага күбрәк охшаган. Архитекторы – руслашкан немец Карл Мюфке бер фасад астында ул бер-берсенә якын урнашкан өч йортны берләштерә. Йорт сәүдәгәр Алексей Капитонович Ушковның кәләше – профессор кызы Зинаида Высоцкаяга зиннәтле туй бүләге була. Яшьләр әле никахлашмаган, әмма йортның фасадында инде «ЗУ», ягъни «Зинаида Ушкова» вензеле балкып тора. Кызның хәлен күз алдына китерегез: кияү йортның ишекләрен ачып җибәрә, эчкә узарга тәкъдим итә, ә анда… һәр зал үзенчәлекле өслүбтә бизәлгән: шинуазри, ампир, готика, рококо, барокко. Витражлар ПарижДан китертелгән, баскычлар – тамарисктан, паркет – сакурадан, тәрәзә һәм ишекләрнең тоткычлары – бронзадан, алары Кытайда коелган, балкон рәшәткәләрен Санкт-Петербург тимерчеләре ясаган. Эркер манарасы хәтерләтә. Әлбәттә, кыз гаҗәпләнүдән телсез кала һәм шунда ук ризалыгын бирә.

Әмма матур башланган әкият бик кыска гомерле булып чыга. Гашыйклар, әлеге сарайда бары тик ике ел гына яшәп кала, аннан аерылышалар. Алексей Капитоновичның башын – театр, ә тәгәлрәге – балет, тагын да тәгәлрәге, сылу балерина әйләндерә. Ул аның пуантыларына кадәр үбәргә әзер була! Альтернатива булган Зинаиданың башмаклары, якут ташлар белән бизәлгән сәхтиян күннән булса да, сәүдәгәрне инде кызыксындырмый. Ул яшь һәм бай. Мәскәүдә, Пречистенкада, Казандагы йортының тәгәл күчермәсен салдыра һәм яңа яры белән шунда урнаша. Сүз уңаеннан, революциядән соң, ул йортта Сергей Есенин белән Айседора Дункан яши.

Бүген Зинаида Ушкова йортында Идел буендагы иң бай китаплар тупланмасына ия Татарстан Милли китапханәсе урнашкан. Биредә экскурсия алырга һәм 15 минут эчендә «туй бүләген» тулысынча карап чыгарга мөмкин.

Ә хәзер «сковородка» (сходкага ашыгучы яшь Ульянов һәйкәле әйләнәсендәге мәйданны шулай дип атыйлар) аша үтеп, Лобачевский исемендәге китапханә янын-

Зинаида Ушкова йортындагы витражлар.

PRESSA.RU

нан узып, кубизм стилендә ясалган баскыч буйлап Ленин бакчасына төшәбез.

Биредә борынгы фонтан (ул Бельгия су үткәрү компаниясе тарафыннан алга таба контракт алуга өметләнеп бүләк ителгән) янындагы эскәмиягә утырып, эсселектән качарга мөмкин. Элек бакчаның бу урынында Николай мәйданы була. Май чабу бәйрәменә, Пасха һәм Святкига мәйдан уртасында таганнар һәм карусельләр урнаштырыла, шунда ук Яшка Мамонов балаганының җете чатырлары балкып утыра. Биш тиенгә петрушка, шамакайлар, фокусчылар һәм пәһлеваннар катнашындагы «репертуар»ны карарга мөмкин була. Бирегә яшь Федя Шаляпин да кергәләп йөри.

«Матур кызның толымына асып гер күтәрүен һәм шамакайларның ахмаклануын исем китеп карап тордым», – дип искә ала торган була Шаляпин. «Хөрмәтле публика» арасында, онга батып, тыз-быз килеп йөрүче Алексей Пешковны (Максим Горькийны) күрергә дә мөмкин була. Татар кафтаны һәм түбәтәен киеп алган Алексей каешына бер тиенлек һәм биш тиенлек кайнар күмәчләр һәм төрле тәм-том тутырылган тартмасын эләктергән. Товарын сатып бетергәннән соң, яңалары артыннан булочнаяга йөгерә. Без дә шунда ашыгыйк...

«Ленин бакчасы» тукталышында төшәбез, химик Александр Бутлеров («ул утырып тора») һәйкәлен артта калдырабыз һәм, Галактионов урамы буйлап, тауга күтәреләбез.

3 НЧЕ ОБЪЕКТ. ПЕШКОВ ЭШЛИ ТОРГАН ИКМӘК ПЕШЕРҮ ЙОРТЫ

Алексей Пешков Деренков икмәк пешерү йортында пешерүче ярдәмчесе булып эшли. Ул бер төн эчендә 6 капчык он изәргә тиеш була. Тынчу һәм он тузанына баткан икмәк пешерү подвалы әле дә сакланып калган. Йоклап китмәс өчен, монда эшләүчеләр кычкырып җырлый торган булалар. Хәзер монда язучының музее ачылган, иптәше Фёдор Шаляпинга багышланган экспозиция дә урын алган биредә. Аларның хорга җырчылар җыючы Казан опера антрепренеры Орлов-Сокольский янына җырлап карарга килүләре факты билгеле. Алёша Пешковны алалар, ә менә Федя Шаляпинны – юк, ышанасызмы-юкмы, тавышы булмау сәбәпле!

1884 елда Түбән Новгородтан бердәнбер максат – Казан университетына укырга керергә дип килгән Пешков Старогоршечная урамында (хәзер Ульяновлар ур., 60 йорт) танышлары Евреиновлар йортына урнаша. Йорт сакланып калган, ул Ленин музееннан (маршрутыбызның ахыры) сул якта урнашкан. Гаилә бик фәкыйрь яши. Алексей, артык кашык булырга теләмичә, кунып чыкканнан соң, шәһәр буйлап йөрергә яраткан. Аннан соң ул ночлежкага күчә. Сәүдәгәр Лупп Спиридонович Марусов тауда берничә таш йорт төзи, анда һәр почмак: «уты булганы» (ягъни тәрәзәлесе) да, булмаганы да арендага бирелә. Халык арасында ул «Марусовкая» дип йөртелә.

Боларның барысын да соңрак Горький истәлекләрендә искә ала: «Бу ач студентлар, фахишәләр һәм кешелекләрен җуя барган күләгәләр белән тулган зур ярымҗимерек йорт иде». «Минем университетларым» повестен язу идеясе нәкъ менә «Марусовка»да туа да. Кунып чыгу урынындагылар язучының «На дне» пьесасында чагылыш табалар.

Казанда җавапсыз мәхәббәт хисләре кичергән Алексей үз-үзенә кул салырга да омтылып карый. Базарда өч сумга бердәнбер ядрәле револьвер сатып ала. Казансуның кешесирәк йөри торган ярына барып, йөрәгенә төбәп ата, әмма ядрә үпкәсенә генә эләгә. Аны очраклы рәвештә үтеп баручы каравылчы Мостафа коткара һәм земство хастаханәсенә илтә.

4НЧЕ ОБЪЕКТ. ЛЕОНТИЙ КЕКИННЫҢ ТАБЫШ ЙОРТЫ

Горький музей-йортыннан чыкканда, берничә минутка псевдоготик өслүбтә салынган «Урта гасырлар замогы» янында туктап алыйк. Ул 1905 елда архитектор Генрих Руш тарафыннан миллионер сәүдәгәр Леонтий Кекин заказы буенча төзелә. Бу Казан архитекторының соңгы эше була.

Кекин Чистайда бөлгенлеккә төшкән кәгазь фабрикасын сатып ала (хуҗасы барон Врангель үзе була!) һәм бер ел эчендә аның чәчәк атуына ирешә. Керемнән кергән акчалар Казанда «замок» төзелешенә салына.

Кекин йорты түбәсенә кадәр наймга бирелә. Подваллар һәм беренче катлар лавкалар һәм лабазлар өчен каралган була. Икенче катта статский чиновниклар һәм пенсионер генераллар арендалый торган рәтләрәк фатирлар урнашса, мансардада ваграк чиндагылар һәм прапорщиклар яшәгән.

Алга таба Горький урамы (Кекин йорты артта кала) буйлап өскә күтәреләбез һәм светофорга якынаябыз. Чатта София Вагнерның (хәзер анда 3нче гимназия урнашкан) сәнгать мәктәбе бинасы сакланып калган, анда үз вакытында модернист рәссам Давид Бурлюк укып чыккан.

Каршыбызда – соры сталинка, анда шагыйрь Муса Җәлил музей-фатиры эшли (Горький ур., 17, 28 нче фа-



тир). Сугыш вакытында әлеге йортта Демьян Бедный тәхәллүсе белән билгеле шагыйрь Ефим Придворов яшәгән. Иртәнге аштан соң ул Лядской бакчасында һава сулап йөрергә яраткан, без дә шунда юл тотыйк. Эскәмиягә утырып, биредә ул үзенең «Как родная меня мать провожала» дигән атаклы шигырен язган, соңрак ул халык җырына әйләнгән.

5НЧЕ ОБЪЕКТ.
ГЕНЕРАЛ БАКЧАСЫ

Революциягә кадәрге «Большая Лядская» урамы хәзеге вакытта Горький урамы дип атала, һәм атама бары тик «Лядской бакча» исемендә генә сакланып калган, ул исә үз чиратында үзенең беренче бакчачысы – генерал-майор Александр Петрович Лецкой исемен бозып әйтүдән килеп чыккан. Сүз уңаеннан, әлеге тыйнак кына йортта 1798 елда император Павел I туктала.

Нәкъ менә Лецкой Пугачёв бунты вакытында Казан Кремле коменданты була. Пугачёв ул вакытта, билгеле булганча, шәһәрне ала, шулай да Кремльгә аның теше үтми, гәрчә туплар туры төзәп кирмәннең капкаларына һәм диварларына атса да.

Генерал, гөлҗимеш, алмагач һәм наратлар утыртып, шәһәр читендәге җирләрне матурлый. Биредә аллеяләр һәм эскәмияләр пәйда була, фонтан ата башлый. Бүген сез моның төгәл күчермәсен күрә аласыз.

Казанда якташыбыз шагыйрь Гавриил Державин һәйкәле дә торгызылган. Тик элек ул башка урында торган. Анысын пролетарийлар, авыр чүкечләр белән ваткалап, кисәкләрен трампарк тимерчелегенә озатканнар да тормоз кысалары итеп эретеп койганнар. Борынгы Рим киеме – тогага уралган шагыйрь уйчан карашын еракка төбәгән. Кулында – балавыз тактага язу өчен кулланыла торган таякчык.



6НЧЫ ОБЪЕКТ. БУЛАЧАК ЮЛБАШЧЫ ЯШӘГӘН ЙОРТ

Беренче Тауда урнашкан Орловлар йортында 1888 елның көзеннән күп балалы Ульяновлар яши башлый. Бу вакытка булачак юлбашчы Владимир Ильичның, бабасы Александр Бланкның Казан губернасы Кокушкино авылындагы имениесендә китап укып, Үшнә елгасы ярында кармак салып, тыныч кына үткәргән сөргенлек чоры тәмамлана.

Орловлар йортының элегрәк үз бакчасы булмый, ул фасадлары белән урамга чыккан сәүдәгәр йортлары арасында качып утыра. Нәкъ Владимир Ульянов яшәгән һәм эшләгән бүлмә тәрәзәләре караган чокырда солдатлар һәм матрослар өчен арзанлы фәхешханәләр урнашкан була. Исерекләр авазы, сүгенү сүзләре һәм төне буена сузылган күңел ачулар Казан университетының элеккеге студентына Маркс һәм Энгельсның тыелган хезмәтләрен укырга комачаулый.

Тәрәзә пәрдәләре артында гади халыкның пычрак һәм оялырга мәҗбүр итә торган тормышы гөрли, ә язу өстәле артында Россиянең өстен аска китерергә, гаделлек һәм тигезлек тантана итә торган җәмгыять төзергә хыялланучы яшь Ульянов утыра.

Совет чорында бирегә туристлар төркеменең эзе суынып тормаган, ә хәзер исә кеше бик сирәк керә. Аның каравы, кытайлар Казанга бары тик бер максат – дөнья пролетариаты юлбашчысын хәтерләгән стеналарга кагылу өчен генә булса да киләләр. Әлеге йорт үзендә яшәгән атаклы кешесе белән генә түгел, бәлки, иң беренче чиратта, сакланып калган интерьеры белән дә кызыклы. Коридорлар буйлап йөреп, бүлмәләргә кереп, бик җиңел генә йөз ел элек булган заманнарга кайтырга, үзеңне гөрләп утырган самоварлы өстәл артында хис итәргә, самоварда, көзгедәге сыман чагылган, зур һәм бәхетле гаиләне күз алдына китерергә буладыр.

1. Лядской бакчасы. Державин һәйкәлендәге барельеф.

2. Лядской бакчасы. Державин һәйкәле.

PRESSA.RU

Автор:
Ксения Сёмина

ТАТАР АШЛАРЫ БУЙЛАП СӘЯХӘТ



Корт, аш, шурпа, кыстыбый, чәкчәк – без бу һәм башка серле кулинария терминнарын Татарстан кунаклары өчен аңлатып бирдек, шул ук вакытта аларның барысыннан да кайда авыз итеп булуын ачыкладык. Казан буенча гастротур аларның хәтерендә озак саклансын, дип тырыштык. Яхшы мәгънәсендә, әлбәттә.

Татарстанда кунакка йөргә, сыйлануга әзер булыгыз һәм, һичшиксез, менә бу ризыклардан авыз итегез:

Өчпочмак
Сүзен сүзгә «три угла» дип тәрҗемә ителә. Шунлыктан, «треугольник» дип сорасагыз, чын өчпочмак белән сыйланмый калмассыз. Өчпочмакны чүпрәле яки төче камырдан пешерәләр. Эчлеге – ит, бәрәңге һәм суган. Табынга шулпа яки катык белән бирелә.

Гөбәдия
Рус милли кухнясы түрендә каравай булса, татар милли табыны түрендә – гөбәдия, ул зур тантаналарда төп сыйларның берсе. Гөбәдия – корт, дөге, йомырка, йөзем катламнарыннан торган түгәрәк бәлеш. Баллы сый чәй табынына куела. Итле гөбәдия дә була.

Зур бәлеш
Татарларның иң яраткан ризыгы! Төче камырдан эченә туралган ит (сыер, үрдәк, йә каз ите), бәрәңге, суган һәм тәмләткечләр салып пешерелгән зур бәлешнең сере шунда – аның эчлеге камыр эчендә авызда эрерлек булып пешә.

Казылык
Ат итеннән әзерләнгән казылык – бик калорияле, искиткеч тәмле ризык, ул табыннан күз ачып йомганчы юкка чыга. Чын казылык 4–5 ай саклана, озаграк торган саен, тәмләнә генә бара.

Без сөйләгән бу ризыклар – татар милли ашларының бик аз өлеше генә. Тагын менә болары белән дә һич сыйланмый калырга ярамый:

Беренче ашлар:
токмачлы аш, татарча солянка, чумар, борчаклы аш, шурпа, умач.

Икенче ашлар:
тутырган тавык, кыздырма, куллама, балык тәбәсе, катлама, каклаган каз, татарча азу.

Камыр ризыклары һәм десертлар:
коймак, пәрәмәч, өлеш, кабак бәлеше, вак бәлеш, бөккән, дучмак, күмәч, кабартма, талкыш кәләвә, кош теле, бавырсак, татлы, бармак, как.

Эчемлекләр:
буза, әйрән, кымыз, катык, татарча чәй.

БАШТА – ПИЛМӘН, АННАРЫ – КИЯҮГӘ

Сезгә, мөгаен, насыйп ярлары мәхәббәтенә лаек булуларын дәлилләү өчен кырыс сынаулар аша үткән патша кызлары турындагы әкиятләр таныштыр. Шуны да белеп торыгыз: бу әкиятләрдә дөреслек тә байтак. Татар авылларында гореф-гадәтләрне хөрмәт иткән һәр кәләш пилмән сынавын үтәргә тиеш булган.

– Әлбәттә, безнең рецепт өйдә әзерләгән кебек гади генә түгел. Иртән-иртүк без, ит һәм бераз пешереп алынган сөякләрне салып, шулпа куябыз. Ул ярты көн пешә, аннары яшелчәләр һәм тәмләткеч үләннәр өстәп, төнәтәбез, – дип сөйли «Татар ашлары йорты» рестораны шеф-повары Антон Камашев. – Заказ кергән саен, бераз шулпаны бүлеп алып, иртән ясалган пилмәнне салабыз һәм 5 минут пешерәбез. Һәм менә «кияү пилмәне» әзер.

Әлеге пилмәннәр шикәр шакмагы кадәр генә. Борынгыдан килгән гадәт буенча, никах мәҗлесләренең берсендә килен кунакларны «кияү пилмәне» белән сыйлаган. Пилмән никадәр вак булса, хуҗабикә шулкадәр уңганрак саналган. Һәм ирен дә шулкадәр күбрәк ярата, янәсе...

Сүз уңаеннан, «Татар ашлары йортының» бүгенге менюсы танылган татар шеф-повары Юныс Әхмәтҗанов китабына нигезләнгән. 1968 елда ачылган ресторанга нәкъ менә аны хуҗа итеп куйганнар. Татар ашлары традицияләрен саклап калырга омтылып, Әхмәтҗанов авыллар буйлап йөргән, төрле милли рецептлар язып алып кайткан. Бу китап хәзер сирәк очрый, аның русчага тәрҗемәсе юк.

Фото: Ната Смирнова.

«КИЯҮ ПИЛМӘНЕ» – 250 Г/ 400 СУМ

РЕСТОРАННЫҢ УРТАЧА ЧЕГЫ: 1500 СУМ

МИҢА ГОРЕФ-ГАДӘТНЕ КЫСТЫРЫП БИРЕГЕЗЧЕ

Чын бөеклек вакытлар үтү белән кимеми. Әлеге фикергә килгән фәлсәфәче татар аш-суларын күздә тотмаса да, алар да бу формулага бик шәп керен урнаша. Традицион рецептлардан иң яхшыларын сайлап алып, Казанда татар фастфуды барлыкка килгән. Һәм әле берәү генә дә түгел.

– Кешеләр үзләре белән алып китәрлек һәм өйләренә заказ белән китертерлек әзер ризыкларга ияләште. Без бу трендта булырга һәм шул ук вакытта милли кулинарияне дә үстерергә теләдек. Гап-гади кыстыбый моның өчен менә дигән булып чыкты, – дип сөйли «Кыстыбый» татар милли фастфуды брендына нигез салучы, аның генераль директоры Азат Нәҗметдинов.

Традицион үзле-майлы камыр җәеменә биредә рецепттагы бәрәңге боламыгын яки тары боткасын гына кыстырып бирмиләр, эчлекләрдән тулы бер композицияләр үк ясыйлар. Мәсәлән, Тукай әкиятендәге «Су анасы» – кыяр, дөге, сөләйман балыгы, креветкалы кыстыбый… Балалар өчен җыелма «Куян кучтәнәче» дип атала. «Кыстыбыйдагы» бөтен продукциянең хәләл-сертификаты бар, сыйфатлары яхшы булу аларның барысының да Татарстанда җитештерелүеннән дер. «Тәм-томга» исә – демократик бәягә сырганак компоты һәм искиткеч тәмле десерт.

КЫСТЫБЫЙ – 115 СУМНАН 250 СУМГА КАДӘР

УРТАЧА ЧЕК: 500 СУМ



МИЧТӘ ПЕШЕРЕЛГӘН АТ ИТЕ – 100 Г/250 СУМ

РЕСТОРАННЫҢ УРТАЧА ЧЕГЫ: 3000 СУМ

АТ ИТЕНЕҢ ҮЗ ТӘМЕН САКЛЫЙЛАР

Аларның өч миче бар. «Помпей», стейклар өчен хоспер һәм рус миче. Анысында, шеф-повар Константин Николаевич әйтүенчә, ашлар пешерәләр.

– Тәүлеклек ашлар, – дип, шулкадәр тәмләп әйтә ул бу сүзне, минем күз алдымнан ярты сәгать буе зур ит кисәгә һәм төрле яшелчәләр йөзеп йөргән, буы бөркелеп торган кайнар шулпа китми.

Әмма без «Пир» ресторанына щи ашарга да, үгез койрыкларыннан әзерләнгән аш белән сыйланырга да түгел, бәлки биредә генә шундый тәмле итеп әзерләнә торган ат итеннән авыз итәргә дип килдек.

Константин Николаевичның кулдашы Станислав безгә «Помпей» миченең капкачын ачып күрсәтә. Аның авызында – зур кисәк ат ите салынган савыт. Станислав мичне яба да, безне пешекчеләр алхимиясенең нечкәлекләре белән таныштыра: бу минутларда ит эчендә оксидлашу процессы бара, шуның нәтиҗәсендә ул тагын да хуш исләнәчәк икән.

– Мичтә пешерүе гади – ашамлыкларны аның эченә тыгасың да куясың. Без бернинди молекулярия дә уйлап чыгармыйбыз, бу безнең өчен ят. Ризыкның үз тәмен саклыйбыз. Без – консерваторлар. Кешеләргә аңлаешлы аш-су әзерлисе килә, – ди Станислав.

– Ә иң популяр деликатесыбыз – ат мае. Безгә кадәр аны беркем дә әзерләмәгән. Ул, канны куа торган ат ите кебек үк, бик файдалы, – ди Константин Николаевич.

Менә безгә әзер ризыкны китерделәр. Карап торышка гаҗәпләнерлек бернәрсәсе дә юк кебек. Пешкән яшелчәләр уртасында ит кисәгә ята. Миңа бер телем кисеп бирәләр, мин авызыма кабам… һәм борынгы болгар гаскәрләре лагерена күчәм, анда учакта пешкән ризык исе борынны иркәли, хуш исле үләннәр өстеннән төнге томан күтәрелеп килә…

– Сере – тәмләткеч үләннәрдә. Аларны бөтен кеше куллана, тик бөтенесе дә дөрес кулланмый шул, – ди администратор, үзенә тагын бер телем ит кисә-кисә.

PRESSA.RU

ЭХ, СИН, ТАТАР КАЗЫ!

Теге яки бу шәһәрдә булып та, аның базарына бармыйча һәм андагы тәмнәрне тоймыйча, андагы җирле деликатесларны татымыйча, сез үзегезне ул шәһәрдә булдым, дип саный алмыйсыз.

– Кызлар, каймак алыгыз! – дип кычкыралар безгә банка һәм кәстрүлләр тулы прилавка артыннан.

Каймак ул – майга әйләнә башлап та, ярты юлда туктап калган сөт өсте. Янәшәдә – корт һәм кортлы май – эремчектән әзерләнгән тәм-томнар. Әчегән сөт ризыклары сатучы Кәүсәрия апа аларның ничек әзерләнүен аңлата.

– Май атлаганда, әйрән кала. Шуңа эремчек, катык, шикәр өстәп, сүрән утта пешерәбез дә пешерәбез...

Ул бу бик тәмле кызгылт-көрән сыйны әзерләүнең тагын берничә төрле рецептын санап китә. Кәүсәрия апа безнең аш-су өлкәсендәге мондый наданлыгыбызга гаҗәпләнә:

– Ничек инде кортның нәрсә икәнен белмисез? Корттан башка бернинди гөбәдия дә пешереп булмый бит...

Ит рәтләрендә испан хамоннан да тәмлерәк милли сыебызны – каклаган казны табабыз.

– Декабрьдә алты айлык казны суябыз, ул симез, түгәрәк булырга тиеш. Яхшылап чистартабыз. Кило ярым тоз тутырып, балавызланган кәгазьгә төрәбез дә, кибәргә элəбез. Кызым, иң яхшысы – авылдагы йорт чормасына элү, – дип сөйли миңа Фирдәвес апа. – Майда алып төшеп, суыткычның туңдыру камерасына куябыз. Кунаклар килгәч, шуннан алабыз да, тозын бушатып, яхшылап юабыз, бер тәүлеккә салкын суга салабыз. Икенче көнне кирәк кадәрен кисеп алабыз да, калганын, яхшылап корытып, суыткычка куябыз. Ул анда бозылмыйча өч ел да саклана ала.

Татарның каклаган казы ул – күчмә кош, чөнки аны күчтәнәч итеп кайларга гына җибәрмиләр, хәтта океан артына да еш барып эләгә ул.

КАКЛАГАН КАЗ (1 КГ) – 1200 СУМ. БЕР КАЗ ЯКЫНЧА 3 МЕҢ СУМГА ТӨШӘ.

ҮЗӘК БАЗАР 7.00 ДӘН 18.00 СӘГАТЬКӘ КАДӘР ЭШЛИ (ӘММА ИҢ ТӘМЛЕ СЫЙЛАР ТӨШ ҖИТКӘНЧЕ САТЫЛЫП БЕТӘ)

ЧҮЛМӘКТӘ БӘРӘН ИТЕННӘН ПЕШЕРЕЛГӘН ШУРПА – 530 Г/ 410 СУМ

РЕСТОРАННЫҢ УРТАЧА ЧЕТЫ: 2–2,5 МЕҢ СУМ (АЛКОГОЛЬСЕЗ)

ПЕШЕР, ЧҮЛМӘК!

Таҗикча шурпа казанда яки чиләктә пешерелә. Төрекмәнчә шурпа кәстрүлдә әзерләнә. «Татарская усадьба» ресторанының аш пешерүчесе Сәхиб әйтүенчә, татарлар үз шурпасын утын ягыла торган мичтә чүлмәкләрдә пешерә.

Сүз уңаеннан әйткәндә, шурпа һәм башка күп кенә ризыклар биредә дә, Казандагы бүтән рестораннардагы кебек үк, бер сәгать чамасы вакытта әзерләнә. Эш, мөгаен, технологиядәдер – ит һәм ашларны мичтә әзерләү өчен якынча шулкадәр вакыт кирәк, ә мич хәзер Казандагы үзен хөрмәт иткән һәр милли аш-су ресторанында бар. Әмма, миңа калса, эш әле гореф-гадәтләрдә дә. XIX гасыр Казанында булырга туры килсә, сез татар кунакчыллыгының нәрсә икәнен һичшиксез аңлар идегез – бу ашау-эчү дә, чәй эчү дә – җисми һәм рухи азык кабул итүгә багышланган чын ритуаллар булып тора...



Сәхиб бик оста сөйләүче дә булып чыкты. Вакытның үткәнен сизми дә калдык.

– Иртән килгәч, мин төн буена утын мичендә томаланып пешкән итле шулпаны алып куям. Заказ китергәч, шулпага кишер, суган, борыч салам, алар тәм бирә. Ярты сәгатьтән бәрәңге салам. Ярты сәгатьтән соң кабып карыйм. Әгәр миңа ошаса, кешеләргә дә ошаячак. Һәм киресенчә.

Шурпадагы бәрән ите бик йомшак булырга тиеш. Әгәр каты икән, димәк, аны аерым пешергәннәр һәм шулпага салып кына биргәннәр.

Мин чүлмәктәге шурпадан авыз итәм. Ит йомшак кына түгел, авызда эри. Әмма иң мөһиме – шулпа. Үтә күренмәле, кайнар, алтынсу май түгәрәкләре йөзеп йөри – әнием ашын ашаган кебек, шунда ук ашап бетерәсе килә.

ТАТАРЧА ФУГУ

– Бу – калҗа, әзерләү традицияләре тамырлары белән Идел Болгары тарихына барып тоташкан милли татар ашы, – ди «Туган авылым» ресторандары шеф-повары Максим Красков, безгә бик затлы итле катламаны күрсәтеп.

– Беренче карашка, аны әзерләү рецепты гади. Сыер итен (яки менә хәзерге кебек сарык ите) суккалап йомшарталар, маринадлыйлар. Тоз, борыч, сарымсак, серкә өстиләр. Өч йомыркадан тәбә кыздыралар. Аннары шуны ит эченә җәеп, катлама итеп төрәләр, – дип тәмләп сөйли Максим, – һәм иң кызыгы башлана. Серкә, сарымсак һәм тәбә ашкайнатуны бозарга тиеш кебек. Һич юк! Катламаны шулпага салып, әзер булганчы томалап пешерәләр. Шулпа ингредиентларның бөтен «шартлаткыч» үзлекләрен юкка чыгара. Нәтиҗәдә бик затлы кабымлык килеп чыга.

Без японнарның фугу балыгын искә төшерәбез: әзерләү вакытын төгәл үтәмәгәндә, ул агулыга әйләнә.

– Татар милли аш-суы үзенчәлекләреннән берсе шунда да. Аңа шәрык, славян, Урта диңгез кухняларының пешерү алымнары керә. Беренче карашка үзара ярашмый торган ризыклар, әзерләгәндә, бик шәп яраша, – дип нәтиҗә ясый Максим.

Менә ул, зур татар кулинария маҗарасының төп сере!

КАЛҖА – 350 Г/ 850 СУМ

РЕСТОРАННЫҢ УРТАЧА ЧЕГЫ: 2 МЕҢ СУМ

МУЗЕЙГА КЕРҮ БӘЯСЕ: ӨЛКӘННӘР ӨЧЕН ЭШ КӨННӘРЕНДӘ 350, ЯЛ КӨННӘРЕНДӘ 400 СУМ.

КАЗАНДА БУЛДЫМ, ЧӘЙ ЭЧТЕМ, ЧӘКЧӘК АШАДЫМ!

Татар кондитер-кулинария аттракционының йөрәге ул – чәкчәк. Йә, нәрсәсе бар инде аның, дисезме? Камыр, бал... Чынлыкта исә сезнең алдагы тәлинкәдә – пространство һәм вакыттан тыш булган мәдәни код кисәкчеге. Бер яктан караганда, бу алтынсу, татлы бал ширбәте сеңгән камыр кисәге безгә татарлар турында күп нәрсә хәбәр итә – тәме һәм консистенциясе буенча идеаль тәм-том булдыру өчен никадәр осталык, хезмәт сөю, кунакларыңны ярату кирәк бит. Икенче яктан караганда, чәкчәк әле ул – тарих көзгесе дә, гасырлар үтү белән татар халкының гореф-гадәтләре һәм көнкүреше үзгәрү турында да ул күп нәрсә сөйли ала. Сезгә аның бөтен серләрен ачмыйм әле. Борын заманнарда чәкчәк бөтенләй башка кыяфәттә булган, һәм аны бик мөһим вакыйгалар хөрмәтенә генә пешергәннәр...

Әлеге тәм-том турында тагын да күбрәк беләсегез һәм аның белән сыйланасыгыз килсә, һичшиксез, Казандагы Чәкчәк музеена барырга кирәк. Экскурсия бер сәгать дәвам итсә дә, сезнең үзегезгә татар сәүдәгәре йортында 15 минутлап кына булгансыз кебек тоелачак.

– Бездән еш кына, кайсы чәкчәк дөрес, кайсы дөрес түгел, дип сорыйлар. Әлбәттә, азык-төлек продукты буларак аның билгеле бер характеристикалары бар – әле генә пешерелгән булуы, йомшаклыгы, ширбәт сыйфаты. Аларны санап тормыйча, һәркемнең үз чәкчәге, дип әйтеп була, – ди музейны оештыручы Раушания Полосина-Сөләйманова. – Әмма безгә, сезнең чәкчәк «әбинеке кебек» диләр икән, бу – безнең өчен иң зур мактау.

Әлбәттә инде, чәкчәктән авыз итү чәй эчмичә, чәй эчү исә рәхәтләнеп сөйләшеп утырмыйча булмый. Димәк, Чәкчәк музееннан сез татарча – озаклап хушлашып, бөтен чәйне эчеп бетереп кенә китә аласыз.

АЛДАН ЯЗЫЛЫРГА КИРӘК, МУЗЕЙГА БОЛАЙ ГЫНА ЭЛӘГЕП БУЛМЫЙ.

Реклама хокукында

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН»
МАХСУС
журналы өчен
Журнал
ТАТАРСТАН
Обращение
к народам всего мира
Татарстан
СПУТНИК АГИТАТОРА
ТАТАРСТАН
ЖИЗНЬ
ЛЕНИНА
в истории РКП(б)
ТАТАРСТАН

КОРТНЫҢ БУЛА ТӨРЛЕСЕ...

Урамда эссе... Әллә шуңа да майлы, итле ризыкларга ис китми. Җиңелчә ризык ашыйсы килә. Тик әлегә бакчада яшелчә, җиләк-җимеш өлгереп җитмәде. Җәйнең соңаруы үзен сиздерә. Шушы нечкәлекләрне исәпкә алып... корт ясарга булдык.

Автор:
Руфия Фазылова

«ЭШСЕЗЛЕК ЭТӘРДЕ»

Иген игү белән бергә, борынгы бабаларыбыз терлекчелек белән дә шөгыльләнгән. Менә шуңа да татарның өстәлендә гомер-гомергә катык, каймак, эремчек, әйрән һәм корт булган. Соңгысының исеме бигрәк матур яңгырый.

Балтач районында мал тотучылар бик күп. Монда, гадәттә,бер хуҗалык ике-өч сыер асрый. Шуның өчен дә корт ясарга нәкъ менә шушы төбәккә кузгалдык. «Бездә корт ясаучы иң оста кеше – Алсу», – диделәр Балтачта. Шулай дигәч күз алдына күп итеп мал асраучы, үзе җитештергән сөттән корт ясаучы ханым килеп басты. Ялгышканмын икән, корт остасының хуҗалыгында бер генә сыер да юк. Ризыкны ул кибеттән алган эремчектән ясый.

– Тәмле эремчектән корт тәмле була, – диде Алсу Хәкимҗанова. – Гадәттә, өйдәге шартларда эремчекне әчегән сөттән ясыйлар. Шуңадыр корт әчерәк чыга. Ә кибет эремчеген әчетеп ясамыйлар.

Без килгәнче Алсу апаның корты газда кайнап утыра иде. «Монысы әзер дияргә була. Хәзер сезгә күрсәтер өчен, тагын бер партиясен куеп җибәрәм», – диде. Баксаң, хуҗабикә ханым атнасына берничә тапкыр корт кайната икән.

– Ураза булгач, халык авыз ачтыра. Дуслар, туганнар, гөбәдия, бәлеш өчен корт кайнатып бирүемне сорыйлар. Юк дисәм, әллә ничек инде.

– Бәясен ничек сөйләшәсез? – дим.

– Килосын 300 сумнан бирәм.

– Ә эремчекне күпмедән сатып аласыз?

– 140 сумнан. Эремчекне Балтач сөт-май комбинатыннан алам. Анда эшләүчеләр безне белеп бетерде инде.

– Корт ясау белән күптәннән мавыгасызмы?

– Берничә ел. Эшсезлек этәрде дисәм дә була. Балтач гимназиясендә башлангыч сыйныфларны укытам мин. Аерым сәбәпләр аркасында, эштән киткән идем. Өч ел гимназиядән аерылып яшәдем. Менә шулвакыт корт кайнатып сата башладым. Аннан янә үз эшемә кайттым. Корт «бизнесы» арткы планга күчте.

ЭРЕМЧЕК ХИКМӘТЕ

Алсу Хәкимҗанова башта кәстрүлнең төбен сыек май белән майлады. Корт төпкә утырмасын өчен шулай итәргә кирәк. Аннан 5 кг эремчекне кәстрүлгә салып өстенә сөт, су агызды. Һәм утка куйды.

– Эш бетте шуның белән, – дип елмайды Алсу апа.

– Безнең шундый тиз арада аш-су әзерләгәнебез юк иде әле, – дим.

– Корт якынча талгын утта ун сәгать кайный. Әйдә, әзер булганын көтегез, иң озак әзерләгән аш-суыгыз булыр…

Әйе, әзер корт булганда ун сәгать көтеп утырасы итмәдек. Кашыкларны алып Алсу апаның татлы ризыгын авыз итәргә керештек. Аш-су әзерләгәндә: «Кулдан килә», – дигән әйтем бар. Бу очракка ул бик туры килә. Кечкенәдән корт ашап үстем, тик монысы үзгә. Ваграк, уалып та тора.

– Мин ясаган корт оешкан була, төсе дә икенчерәк, – дим Алсу апага.

– Ә сез нәрсәдән ясыйсыз? – ди.

– Катыктан…

– Әйе, әчегән сөт, кефир, катык салсаң, корт оешкан була. Азрак кайнатсаң, минеке төсле үк куе коңгырт төскә дә керми. Үзеңә ашар өчен корт катыктан әйбәт чыга, тик менә гөбәдия, бәлеш өчен эремчектән ясаганы әйбәтрәк.

Ул арада Алсу апа алдан кайнаткан кортын сөзгечкә салды. Суы агып беткәнче, шулай берничә сәгать торырга тиеш икән.

– Кортыгыз баллы, шикәр комын кайчан салдыгыз? – дим.

– Корт әзер булганда гына салам. Югыйсә ул төбенә утырырга мөмкин. Гадәттә, ашарга дигән кортка тагын өстәп шикәр комы, май салам, шуңа баллы тоеладыр ул сезгә.

– Газны бер дә карамыйсыз,– дим, кәстрүлдә кайный торган эремчеккә ишарәләп.

– Юк, аны карыйсы юк инде. Үзе шулай кайнап утыра. Элек буташтыра идем, хәзер кагылмыйм. Кешеләр дә аптырап: «Ничек төбенә утырмый?» – диләр. Осталыкмы, кулдан киләме, белмим. Мин, гадәттә, кортны төнгегә куеп калдырам. Әйтик, кичке унда газны кабызам, иртәнге алтыда сүндерәм.

– Төнгегә газ калдырырга курыкмыйсызмы?

– Аллага тапшырган инде. Төнлә бер тапкыр торып карыйм үзе.

Алсу апа кортны килолап, граммлап та сата икән. Сөзгечтә

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

КОРТ РЕЦЕПТЫ:
(ЯКЫНЧА 4 КГ КОРТ ЧЫГА)

1. Эремчек – 5 кг
2. Сөт – 1 литр
3. Су – 1 литр
4. Шикәр комы – 0,5 кг
5. Сыек май – чама белән

КОРТЛЫ МАЙ РЕЦЕПТЫ:

1. 2 стакан иләнгән корт
2. 1 стакан сөт
3. 150 грамм шикәр комы
4. 300 грамм сарымай яисә атланмай.

Киптерелгән кортны төеп, илиләр. Аннан соң шуңа сөт өстәп, ботка сыман булганчы, сүрән утта кайнаталар. Һәм эретелгән атланмай, шикәр комы өстәп, яхшылап болгаткач, янә 10 минут чамасы сүрән утка утырталар. Әзер массаны тәлинкәләргә салып, салкынга куялар.

суын агызып бетергәннән соң, иттарткычтан чыгарта. Һәм нәкъ кибет корты кебек була.

– Әзер кортны суыткыч камерасында саклыйм. Аны теләсә кайчан алып ашарга була. Шикәр комы, каймак яки май өстисең дә.

– Сезнең гаиләдә корт яраталармы? – дим.

– Бик исләре китми. Шулай да безнең өстәлдә бу ризык һәрчак бар.Кучтәнәчкә җибәрергә дә әйбәт.

– Эремчек сатып алып корт ясау үз-үзен аклыймы соң?

– Мин бит аны хәзер табыш алу максатыннан эшләмим, бер хобби кебек. Үзегез беләсез, хобби зур акча китерми.

«УРМАН ҖЕНЕ», ЯКИ АУ СЕРЛӘРЕ

Корт белән чәй эчәргә Хәкимҗановларның күршеләре Сөмбелә Садыйкова да керде. Кайгыда да, шатлыкта да бергә икән алар:

– Безнең Алсу артык тыйнак, – дип сүзен башлады күрше ханым. – Аның пешерә белмәгән ризыгы, эшләмәгән эше юк, әйтми генә. Дистә еллар дәвамында күршеләр арасында барлыкка килгән традициябез дә бар. Ураза, Корбан бәйрәмнәрендә Гает коймагы ашарга Хәкимҗановлар өенә җыелабыз. Мич төбендә, күршебезнең ялкында пешергән коймагын көтеп утырабыз.

– Әйе, андый хәлләр була, – дип елмайды Алсу апа. – Утын белән яга торган мичне сүттермәдем, махсус коймак пешерү өчен тотам. Ирем дә, балаларым да мин пешергән коймакны ярата. Янына корт, май куям. Гает намазыннан кайткач, коймак белән башта ирләр чәй эчә, аннан хатын-кызлар утыра. Бала-чагалар да килеп кушыла. Үзенә күрә бер бәйрәм ул.

Алсу апа рәсемнәр дә ясый икән. Мичкә дә бизәкләр, төрле сурәтләр ясап куйган, әнә. Тагын аның тормыш иптәше Альберт бик кызык һөнәр иясе – районның баш аучысы. Ни өчендер шушы сүзне ишеткәч, күпләр Альберт абыйны мылтык тотып, кыргый җәнлекләрне атып йөрүче дип уйлый икән. Баксаң, киресенчә, ул аларга ярдәм итә.

– Иремне өйдә күргән юк дисәм дә була, – ди Алсу апа. – Урман кешесе ул. Иртән чыгып китә, кичен кайта. Белмәгән кешеләр: «Шул гомер урманда нишләп ятарга мөмкин?» – диләр. Җавап бик гади: кыргый җәнлекләрне ашата, аларны явыз кешеләрдән яклый. Аучылык модада бит хәзер. Теләсә кем урманга барып җәнлекләрне атарга мөмкин. Менә шундый кешеләрне ирем тикшереп, карап йөри. Берсендә хәтта аттылар да үзенә. Ядрә аягына тигән иде.

Кызганыч, Альберт Хәкимҗанов белән танышып булмады, эштә чагы иде. Курку белмәс бу ир Балтач урманнарында ничә кабан, поши барлыгын, башка җәнлекләрнең санын да белә икән. Гомер буе аучы ир белән яшәп, Алсу апа Балтач урманнары турында барысын да белеп бетергән.

– Сезнең урманда бүре, аю бармы? – дим Алсу апага.

– Бүре кереп чыккалый. Ә менә аю яшәми, шулай да бер елны кышлады ул бездә. Ирем аны карап, саклап торды. Гомумән, Альберт кыш буе кабан, пошиларга ашлык ашата. Аучылар булмаса, бик күп кыргый җәнлекләр үлеп бетәр иде. Ә аларны ауларга килгәндә, тәҗрибәле сунарчы кайсы җәнлек-

не, ничәне атарга кирәк икәнлегеН исәптә тота. Табигатьтәге баланс турында күпләр белә дип уйлыйм: бер кыргый җәнлек артса, икенчесе кими. Ирем менә шул балансны өйрәнеп, тикшереп тора.

– Ирегезгә кыргый җәнлекләрнең тигәне юкмы? – дим.

– Юк, алар Альбертны таный булса кирәк. Ул үзе дә табигатьне бик ярата: яраланган кыргый җанварларны карый, имгәнгән кошларга булыша. Кыргый булсалар да, алар яхшы белән яманны аңлый, күрәсең.

– Альбертны яратып кына «урман җене» дибез, – дип сүзгә кушылды Сөмбелә апа. – Ул урманның теләсә кайсы почмагында нәрсә бар икәнен белә. Җәен аның белән җиләккә, гөмбәгә барсаң, һичшиксез, юлың уңа.

«МИН ХЫЯЛЫЙ!»

Сүз башым бит Шүрәле дигәндәй, Алсу Хәкимҗановадан корттан ризык әзерләү төрләрен сорашам.

– Әлеге ризыктан гадәттә корт сумсасы, гөбәдия пешерәм, – диде хуҗабикә. Уртача зурлыктагы гөбәдиянең төбенә 350 грамм корт салам. Тәмле корт гөбәдияне бозмый, күбрәк булган саен татлырак кына итә. Ризыкны әзерләгәндә күбрәк фантазиягә таянам. Гомумән, тормышта да хыялый мин. (Хуҗабикә ханым тагын кортлы май рецепты белән дә уртаклашты – авт.).

Алсу апа бүген Балтач гимназиясендә башлангыч сыйныфларны укыта. Шулай ук әлеге белем йортында «Хыялый тургай» исемле балалар театр түгәрәге алып бара. Концерт, кичәләр өчен сценарий яза. Тагын шигырьләр иҗат итә.

Өч балага гомер биргән әлеге мөләем ханымның дөньясы түгәрәк. Ике кызлары зур инде, оныкта бүләк иткәннәр. Әтөпчек уллары Ариф 17 яшендә: Казанда укып йөри.

– Яшеллекне, тереклекне яратам, – диде Алсу апа. – Менә тагын ямьле җәйләр килде. Тормыш матур, шуны белгән, аңлаган кешегә. Балалар кайгысы күрми, тигезлектә, саулыкта яшәргә язсын. Ә калганы була аның. Кортын да кайнатабыз, башкасын да әзерлибез…

Алсу апа корт рецепты белән генә түгел, шигырь язу рецепты белән дә бүлеште. Сезгә аның бер шигырен тәкъдим итәбез. Корт белән чәйләп утырганда, күңелләрегезне хушландырсын!

1. Сөт салабыз!



2. Су кушабыз!

3. Газга утыртабыз!

4. Шикәр комы салып, янә кайнатабыз!

ГАЕТ КОЙМАГЫ

Гает иртәсендә коймак салам,
Өч газизем тезелеп утырган:
Элеккечә коймак көтә алар.
Чекелдәшеп яна утыннар.

Коймак инде тансык ризык түгел,
Йола кызыктыра баланы.
Сирәк кенә күрә хәзер кеше
Ялкынланып утын янганны.

Балаларны тыю онытылган,
Ни алса да рөхсәт – табыннан.
Көнкүрешнең бер тәрәге – мич тә
Кызык өчен генә салынган.

Истә... әни көн дә мичне яга,
Ләкин сирәк коймак пешерә.
Бары берне биреп ашата да,
Әти кайтыр төшне көттерә.

Сабыр сабагына бәлки шунда
Өйрәнгәнбез, тыеп нәфесне.
Тормыш юлын аңлап тартабыз бит –
Әнкәйләрнең биргән дәресе...

Безнең яшьлек үтте ишетмичә,
Намаз укыганын картларның.
Бик аз күрә идек әбиләрнең
Качып кына тәсбих тартканын.

Гает кебек изге йолалар да
Безнең өчен булды никтер чит.
Әбиләрнең дога укыганын
Уйладык тик бишек җыры дип.

Биргәнеңә шөкер, хәзер инде,
Бисмилланы белә балалар.
Изге догаларны яттан укый,
Азанга да колак салалар.

...Җаннарында бер-берсенә игелек,
Һәм туганлык уты дөрләсен.
Әти-әни, туган йортка, илгә
Сөю хисе мәңге сүнмәсен.

Утын яна....
Ялкын күмер сала.
Пешә мичтә гает коймагы.
Балаларым, беләм, онытмаслар,
Гает дигән изге йоланы.

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

ЧЫН КЛАССИК ҺӘМ ЧЫН ИНТЕЛЛИГЕНТ

Гадәттә, без күренекле шәхесләрнең туган якларына – район-төбәкләргә юл тотабыз. Бу очракта юлыбыз әллә ни еракка сузылмады: Казанның Иске Татар бистәсенә китерде. Париж Коммунасы белән Татарстан урамнары тирәсендәге элеккеге йортларның күбесе инде сакланмаган. Хәзерге Нурулла мәчете дә узган гасыр башындагы ихатасыннан шактый аерылып тора, ди, Иске Казанны белүчеләр. Әйтүләренә караганда, каһарманыбызның балачагы узган йорт кайчандыр шушында урнашкан булган. Ә гомеренең соңгы елларында Ирек мәйданында – тәрәзәсе Тукай һәйкәленә карап торган йортларның берсендә яшәгән ул. Монда аны хәтерләтеп мемориаль такта эленеп тора. Сүзебез композитор Мансур Мозаффаров турында.



Әзерләде:
Луиза Янсуар

ТЫНГЫ БИРМӘҮЧЕ МУЗЫКА

Заманында… бәләкәй Мансурга тере Габдулла Тукай үз фатихасын биргән була. Кибеттә йомышчы малай булып йөргәндә, ул аңа яңа китаплар һәм газеталар китерә, аларны шагыйрьгә кертеп үк бирә торган була. Композитор соңыннан Тукайның аны якты итеп каршылавын, «Беләсеңме, малай, мин бит бүген фәрештәләр белән сөйләштем», – дип әйтүен искә алып сөйли.

Мансур Мозаффаровның әнисе, атаклы Маһруй Мозаффария, үз заманының иң укымышлы хатын-кызларыннан булып, кызлар гимназиясендә укыта, шагыйрә, Казан шәһәр советында депутат була. Әтисе Хуҗахмәт мулладан биш яшендә үк калса да, аның халык арасындагы абруе хакында да ишетеп-белеп үсә кечкенә Мансур.

Мәрьям Рахманкулова, Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы:

«Бик иртә хәреф тануым аркасында 5–6 яшьтән үк әтием мине Маһруй апага укытырга илтеп тапшырган. Хәтердә: мәктәп Маһруй апаның үз йортында иде. Дәрестән соң әти килеп алганчы, мин мәктәп бүлмәсендә утырып торам. Мансур бик шаян малай иде. Ул артык шаярып җибәреп мине рәнҗетә, чәчләрдән тарта, җылата иде. Бу хәлне ишетеп Маһруй апа керер иде һәм мине үз бүлмәсеннән алып чыгып, прәннек, конфетлар белән сыйлый иде».

Салих Сәйдәшев белән дуслыгы турында билгеле Мозаффаровның. «Балачак дустым» мәкаләсендә ул 1913 елны аларның танышу елы дип искә ала. Казандагы «Шәрык» клубына йөргән җизнәләре малайларны еш кына биредә узган спектакльләргә алып килә торган була. Антракт вакытларында анда Гали Зайпин җитәкчелегендәге кыллы уен кораллары оркестры уйный.

«Без Салих белән аны бик тәэсирләнеп тыңлый идек, – дип искә ала Мансур Мозаффаров. – Оркестр белән мавыгу безне якынлаштырды, музыкага мәхәббәт уятты, тормыш юлын сайлауда зур йогынты ясады».

«Язмышлар уртаклыгы да берләштергәндер үзләрен», – ди бу дуслык хакында Мансур Мозаффаров иҗаты буенча монография авторы, музыка белгече Клара Таҗиева. Ике малайның да әтисез үсүләренә басым ясый ул. Җитмәсә, өйләре дә бер-берсеннән ерак түгел генә урнашкан: Париж Коммунасы белән Татарстан урамы – кул сузымында. «Безгә бер-беребездән бик ерак торабыз кебек тоела, шуңа күрә без еш кына койма аркылы сикереп төшә идек. Март-апрель айларында кузна уйныйбыз. Салихның кыска гына пальтосы бар иде, уйный-уйный ул пальто шомарып, ялтырап, кузна җелегенә буялып беткән иде. Шуның өстенә икебез дә музыка белән мавыгабыз, ул гармунда уйный, ә мин – мандолинада…»

Мансур Мозаффаров тирән бер җылылык белән искә алган бу дуслык аларның гомере буена сузыла. Башлангыч белемне Мансур Мозаффаров татар мәдрәсәсендә ала. 1916 елда татар-рус укытучылар мәктәбенә укырга керә. Әмма музыка аңа барыбер тынгылык бирми. Һәм алар Салих Сәйдәшев белән студентлар, гимназия укучыларыннан оркестр оештырып җибәрәләр. «Салих – быргыда, мин кларнетта уйнарга өйрәнә башладык», – дип искә ала Мансур Мозаффаров соңыннан. «Сәйяр» труппасы спектакльләренең антракты вакытында уйный торган булалар егетләр. Мулланур Вахитов чыгыш ясаган митингтан соң уйнаулары турында да мәгълүмат теркәлеп калган.

Фотолар: Мансур Мозаффаровның шәхси архивыннан

– Мозаффаров татар көйләрен һәм җырларын Мәскәүдә граммофон язмаларына язу эшен оештырды. Ул эш исә бик катлаулы һәм зур эш булса да, Мозаффаров аны бик матур төгәлләде. Бик күп татар көйләре һәм җырчылары пластинкага язылып, совет иле буенча таралып та өлгерде. Язма өчен җырчыларны һәм көйләрне сайлаганда һәм язмага хәзерлек вакытында Мозаффаров зур җаваплылык белән талантларны күрсәтеп, язмаларның яхшы сыйфатлы булулары өстендә күп хезмәт куйды.

Мәрьям Рахманкулова.

«ИПИ КЕБЕК КАДЕРЛЕ»

Профессиональ музыкантлык юлына Мансур Мозаффаров 1919 елда аяк баса. Казан училищесының кларнет курсына укырга керә. 1923 елда, училищены тәмамлагач, ТАССР хөкүмәте юлламасы белән Мәскәү дәүләт консерваториясенә укырга китә.

Сара Садыйкова, Татарстанның халык артисткасы, композитор:

«Татар вәкалиятендәге бер тулай торакта яшибез булып чыкты. Татарстаннан, Башкортостаннан килгән барлык студентлар шушы тулай торакта яшәделәр. «Тихий» – тын студентлар, ягъни техник югары уку йортларында яки университетта укучылар өчен (без аларны «җитдиләр» дип атап йөртәбез) тулы тынлык, тынычлык кирәк булганга, алар безне подвалга яки кочегаркага куып төшерәләр иде. Мансур үзенең кларнетында күнекмәләрне подвалда уздырса, мин кочегаркада үземнең вокал күнекмәләрне җырларга яки арияләр, Рахманинов романсларын өйрәнергә тиеш була идем.

Ул чактагы студентларның тормышы авыр булса да, бездә музыкаль белемгә, аның байлыкларын үзләштерүгә булган омтылыш, уку дәрте бик көчле иде. Без бит ул чакта сәнгатькә һөнәр итеп кенә түгел, ә нииндидер изге, илаһи, бөек, ипи кебек кадерле нәрсә итеп карый идек».

1924 елның 22 гыйнварында Мансур Мозаффаров Мәскәүнең Кызыл мәйданында Ленинны күмү җеназасында җыелма тынлы оркестрда кларнетчы булып катнаша. Бик салкын көн була ул, Мозаффаров шунда аякларын өшетә. Кат-кат операцияләр кичерергә туры килә аңа, әмма алар барыбер эзсез узмый: йөреше үзгәреп, салмакланып кала. Кларнет классы буенча дәресләрен туктатып, Казанга әйләнеп кайтырга мәҗбүр була музыкага гашыйк егет.

Бер ел дәвамында педагогия техникумында җыр укытучысы булып эшли ул. Әмма музыка теориясе белән тирәннәнрәк танышу заруриятен сизеп, яңадан Мәскәү консерваториясенә, педагогия факультетына укырга керә. Бер елдан соң Мозаффаровны композиторлык факультетының этнография бүлегенә күчерәләр. Бу бүлек яшь милли музыкаль мәдәниятләр өчен кадрлар әзерләргә булыша торган була. Мозаффаровның һәм композитор, һәм белгеч булып формалашуына зур йогынты ясаган шәхес – укытучысы, композиция классы буенча профессор Анатолий Николаевич Александров. Ул татар музыкасына зур ихтирам белән карый торган шәхес буларак билгеле.

СӘЙДӘШТӘН ИЛҺАМЛАНЫП...

Укуы белән беррәттән Мозаффаров Мәскәүнең татар урта мәктәбендә җыр дәресләре дә бирә торган була. Үзен Мәскәүнең Эшче татар театрында сынап карый – спектакльләрнең музыкаль бизәлешен башкара. 1929 елдан шул театрның музыкаль җитәкчесе һәм дирижеры да булып китә. Сара Садыйкова искә алганча, ул театрда барган пьесалар өчен музыка яза, аны оркестрлаштыра, халык көйләрен гармониягә сала, кечкенә составлы оркестрга дирижерлык итә, үзе дә анда кларнетчы буларак катнаша.

Кызганыч, спектакльләргә язган музыканың кульязмалары сакланмаган. Әмма ул җырларның кайберләре Мансур Мозаффаровның татар һәм башкорт көйләреннән торган, төрле башкаручы составлар өчен язылган кульязма җыентыгына кергән. Җыентыкка борынгы озын көйле «Карурман», «Зәңгәр шәл», «Әллүки», «Салкын чишмә» һ.б. җырлар тупланган. Бу эше белән Мансур Мозаффаров ул елларда матбугат битләрендә һәм интеллигенция вәкилләре арасында барган бәхәсләрдә үзен тарихына һәм милләтенә тугры булып калу позициясен алга сөрүче итеп таныта.

1931 елда Мәскәү консерваториясен тәмамлап, Мозаффаров Казанга әйләнеп кайта. Татарстан радиокомитетында домра квартетына музыкант булып эшкә урнаша. Халык көйләрен эшкәртә, беренче мөстәкыйль җырларын иҗат итә, симфоник музыка өлкәсендә көчен сынап карый. «Мин һөнәрем буенча башкаручы, ә композиторлык сукмагына мине Сәйдәш иҗаты этәрде. Аның музыкасы белән илһамланып, мин дә музыка яза башладым», – ди торган була композитор.

«ГАЛИЯБАНУ»НЫ СЕЗНЕҢ ӨЧЕН ЯЗДЫМ...»

1932 елда Мансур Мозаффаровны Мәскәү консерваториясенең Башкорт бүлегенә музыкаль теория дәресләре бирергә укытучы итеп чакыралар. Монда ул 1937 елга кадәр эшли. Мәскәү консерваториясе каршында Татар опера студиясе ачылу татар музыка мәдәнияте үсешендәге гаять әһәмиятле вакыйгаларның берсе була. Студия студентлары ел саен Казанда отчет концертларында чыгыш ясыйлар.

Мансур Мозаффаров. 1919 ел.

PRESSA.RU

Мәскәүдән олы кызы Миләүшә кунакка кайткач төшкән фотосурәт. 1960нчы еллар.

– Музыкаль спектакльләргә йөрү, аларны җыйналып тикшерү, фикер алышулар ул заманның бер үзенчәлеге булган, моны татар интеллигенциясенең шул чордагы вәкилләренең барысы да диярлек раслый. Татар сәнгате өчен яңа жанр – опера белән мавыгу чоры да ул. Нәкъ менә шул вакытта опера студиясендә өч опера иҗат итеелә – Нәҗип Җиһановның «Качкын» белән «Ирек» опералары, Мозаффаровның «Галиябану»ы, – ди Клара Таҗиева.

Галия Кайбицкая, Татарстанның халык артисткасы:

«1934 елны Мансур Мозаффаров, Мәскәү консерваториясендә укып йөргән чагында, Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасына опера язды. Аңа ул бик күп үзенчәлекле сыйфатлар кертеп, нечкә-сузмалы моң, искиткеч лирикага бай арияләр, дуэтлар, хор-балет, увертюралар белән баетып, беренче төзеләсе татар опера театрыбызга зур бүләк ясады. Беренче композитор Нәҗип Җиһанов тарафыннан әле генә язылып өлгергән «Качкын» операсы булды. Икенче булып Мозаффаровның «Галиябану» операсы дөньяга килеп туды.

Беркөн шулай Мозаффаров: «Галиябану» – Сезгә, партиясен Сезнең тавышка карата яздым. Тавышыгызга уңайсыз җирләре булса, борчылмагыз, бергәләп үзгәртербез, – дип, Галиябану партиясен миңа китереп бирде. «Галиябану»ның ялгыз җырлый торган арияләре ифрат дәрәҗәдә уңышлы һәм уңайлы язылган иде. Югары интонация белән художество байлыгында саф татар моңы. Колакка тиз ятышып кала. Җырлаган саен йөрәккә якын булып, җырлыйсыны гына китереп торды. Мансур «Галиябану»ның арияләрен үзе дә җырлап йөри башлады…

Аннан, «Галиябану» бик тиз арада эшләнеп, сәхнәгә куелганнан соң, Мозаффаров тарафыннан «Зөлхәбирә» дигән тагын бер опера язылды. «Зөлхәбирә»нең партия дәфтәренә: «Галия ханым! Сезгә багышлап язылды, уңышлы булсын. М. Мозаффаров», – дип, үзенең кулын куеп, миңа китереп тапшырды. Бер үк композитор, үзенең икенче операсын: «Сиңа багышлап яздым», – дип, ноталарын күтәреп килгәч, минем өчен чиксез дәрәҗәдә сөенеч булып яңгырады».

«Галиябану» операсының премьерасы 1940 елга карый – аны Татарстан АССР төзелүнең 20 еллыгына туры китерәләр. Опера алдыннан кереш сүз белән Муса Җәлил чыгыш ясый.

«БӘЙЛӘҮ БЕЛӘН УТЫРГАНЧЫ, МУЗЫКА БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘН!»

Сәламәтлеге аңа сугышка китәргә мөмкинлек бирми. Әмма башта ТАССР Министрлар Советының Сәнгать эшләре идарәсе каршындагы фольклор кабинетында, ә 1944 елдан Татар радиокомитетының музыкаль тапшырулар редакторы вазыйфасында киеренке эшчәнлек алып бара ул. Фортепианога кушылып түбән тавыш белән башкару өчен татар халык җырларының зур циклын эшкәртүе генә дә зур игътибарга лаек. Цикл ул чакта радиода штатта эшләгән солистка – Гөлсем Сөләйманова өчен махсус эшләнә. Аны шартлы рәвештә «Сөләйманова дәфтәрләре» дип тә йөртәләр.

Гөлсем Сөләйманова бик күп халык җырларын белә торган була, ләкин, эшкәртелеше булмаганга, күбесен радиодан җырлый алмый. Мансур Мозаффаров аңа бу кимчелекне юк итәргә сүз бирә, һәм сүзендә тора. Үз иҗатының да төрле юнәлешләрдә үскән чоры бу: «Зөлхәбирә» операсы өстендә эш, җырлар язу, романс жанрын үзләштерү, консерватория ачылганнан башлап, педагоглык эшен алып бару…

Миләүшә Мозаффарова, Мансур Мозаффаровның олы кызы:

– Безнең әтине музыкасы аша ачык күз алдына китерергә мөмкин. Аның бөтен барлыгы – музыкада. Йомшак, рәхимле характеры, гаҗәеп намуслылыгы, сәнгатькә тугрылыгы әсәрләрендәге һәр авазда, һәр аһәңдә чагыла. Ул искиткеч дәрәҗәдә ярдәмчел, беркем турында да начар сүз әйтмәс. Әти өйгә кунак килүне бик ярата иде, һәм алар безнең өйдә бик еш була. Әнинең хәтта һәр очрак өчен камыры әзер, әти кунаклар чакырса дип, алдан әзерләп куя иде.

Муса Җәлилне яхшы хәтерлим. Ул чакта без бер өйдә яши идек, ул еш кына бездә була иде. Ә ул фронтка киткән чакта, без аны бөтен гаиләбез белән озаттык. Инде Муса Җәлил өстенә хыянәтче дигән шикләнү тамчысы төшкәч, аның шигырьләре тыелгач, әни Мусаның бездә булган бөтен әйберләрен ягарга тәкъдим итте, әмма әти моңа ирек куймады. Ул Мусаның сафлыгына, намуслылыгына ышанды, шигырьләрен кадерләп саклады, аны яратудан туктамады.

Безгә – балаларга карата булган олы мөнәсәбәтен онытa алмыйм. Дөрес, ул бу тойгысын ачыктан-ачык күрсәтми. Ул бервакытта да тавышын күтәреп, ачуланып сөйләшмәс. Аның: «Кызым, татарча җавап бир», – дигән сүзләре истә калган. Йомшак, ягымлы тавышы хәтердә. Чиста, саф, әйтергә буладыр, музыкальлеге белән аерылып торган тавыш иде. Әти безнең музыкант булуыбызны бик тели иде. «Кызым, бәйләү белән утырганчы, музыка белән шөгыльлән», – дия иде. Һәм без, аның өч кызы да, өебездәге музыкага булган хөрмәт атмосферасы аркасында музыкаль белем алдык.

«ТӘРӘЗӘДӘН ИДЕЛ КҮРЕНӘ...»

Гомеренең соңгы ун елы эчендә композитор симфониетта, скрипка һәм оркестр өчен ике концерт, «Туган як» дигән өченче симфоник поэмасын иҗат итә. «Галиябану» операсының яңа редакциясен эшли, бик күп санда җырлар яза, халык җырларын эшкәртә, балалар музыкасына зур игътибар бирә. Бу чорны композиторның вокаль иҗатындагы кульминациясе дип атарга да буладыр. Музыка белгечләре әйтүенчә, җыр жанрындагы яңа төрнең тууына нигез булды аның эзләнүләре.

Мөнир Мазунов, язучы, журналист:

«Сугыштан соң язмыш мине Казанга китерде һәм мин радиога редактор булып эшкә кердем. Без беренче тапкыр шунда очрашып таныштык. Мансур Мозаффаров җыр текстларын алгач: «Бу җире миңа ошамый, бу җире болай, теге җирен тегеләй итәргә кирәк», – дип беркайчан да әйтми иде. Ул: «Уйлап карарга кирәк булыр», – дип әйтә иде. Әлбәттә, бу һич тә ул текстларга карата таләпчән түгел иде дигән сүзне аңлатмый. Берара вакыт үткәч, ул музыка язса, шун-

да ук хәбәр итә иде. Ә инде музыка язмаса, үзең аңла дигән сүз».

Мансур Мозаффаровның иҗатында зур урын алып торган ике күләмле әсәр – «Габдулла Тукай истәлегенә» һәм «Мулланур Вахитов истәлегенә» симфоник поэмалары. Болар – аның, музыкаль авангард вәкиле булуына карамастан, милли традицияләргә гомере буена тугрылыклы булып калган композитор икәнлеген раслаучы дәлилләр. Мозаффаровның җырларын гына түгел, ә күләмле, эре әсәрләрен дә гаять зур тирәнлек белән берләштән, гади, ипле яктылыкка ия дип табалар. Гомеренең баешында Роберт Әхмәтҗанов сүзләренә иҗат иткән «Саумы, кояш!» җырында бу якты, тормышчан лейтмотив ачык чагыла. Һәм тирән лиризмның, чоңгыл төбеннән күтәрелгәндәй бөтерелеп-бөтерелеп, дулкыннар сыман җәелеп китүе, эпиклыкка күчүе сокландыра.

Ә аннан да бигрәк – аның, зур шәхес, олпат иҗатчы һәм педагог була торып та, үтә гади, тыйнак, кече күңелле була кала алуы.

Мирсәет Яруллин, композитор:
«Мансур абый белән беренче танышуым 1951–1952 елларга туры килә. «Карагыз әле, тәрәзәдән Идел күренә!» – дигәне хәтердә.

1962 елны әти белән әни Казанга күчте. Мансур абый белән бик еш очрашалар иде. Өлкәннәрдән сирәк калган кешеләр иде алар. Әти Мансур абыйның расписаниесен яттан белә. Мансур абый ул вакытта укыту эшләрен инде киметкән иде. Мансур абыйның, буш көннәрендә минем әти Воровский тукталышыннан троллейбуска утырып Кольцога хәтле бара иде, Мансур абый белән очрашып, җәүләп Идел портына китәләр, борылып, Киров дамбасына чыгалар, Кремль асты тукталышына җәяү киләләр һәм троллейбуска утырып безгә кайтып китәләр. Әти вафат булганчы – 1964 елга хәтле – бу шулай дәвам итте. Кыш, җәй, көз, яңгыр дип тормыйлар иде».

1966 елның 20 ноябрендә, озак авырудан соң, Мансур Мозаффаров вафат була. Тәрәзәсеннән, кайда гына яшәмәсен, эшләмәсен, һәрчак елмаеп сәлам бирүче кояш һәм дулкыннарын тәгәрәтеп агып ятучы газиз Идел күренгәндәр кебек тоела миңа.

Композиторлар (сулдан уңга): Р. Яхин, Ш. Фәйзи, М. Мозаффаров, М. Коваль, Н. Җиһанов. 1959 ел.

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ...

Марат Әхмәтов, Татарстанның сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт консерваториясе профессоры:
– Әти мине 1943 елда Казанның Чайковский исемендәге 1нче музыка мәктәбенә бирде. Сугыш еллары. Безне «Татарстан» радиосына чакырдылар. Килдек тә, турыдан-туры эфирга чыгасы вакытыбызны көтеп, бакчадагы фонтан янында утырып тордык. Мин Екатерина Соколова дигән атаклы, татар музыка сәнгатен халыкка танытуда үзеннән зур өлеш керткән концертмейстер белән уйнадым. Мансур абый Мозаффаровның «Тын бакчада» әсәре иде ул. Икенче көнне безнең өйгә Мансур абый үзе килеп керде. Кәефе көр, күтәренке. Мине бик мактады. 7 яшьлек малай өчен зур мәртәбә иде инде бу, билгеле. Шуннан соң мине һәртөрле абруйлы концертларга чакыра башладылар.

Консерваториядә укый башлагач та, аны тәмамлап, үзем укыткан елларда да Мансур абый скрипка һәм фортепиано өчен язылган әсәрләрен һәрчак миңа ышанып тапшыра иде. Техник редакция ясар өчен. Җыентыкларына да шул минем редакциядә кереп киттеләр. Мансур абыйның скрипка өчен поэмаларын мин бөтен Союз буйлап яңгыраттым – Саратов, Ульяновск, Әстерхан, Себер, аннары чит илләргә алып чыгып уйнадым. Бик яратып кабул итә иде тамашачы аларны. Мозаффаровның музыкасы – югары кимәлдәге чын классика, шул ук вакытта гаҗәеп милли дә.

Мансур абый үзе гаять дәрәҗәдә интеллигент кеше иде. Бөтен тәрбиясе, рухы белән, нәселдән килгән ул интеллигентлык. Йомшак, кешегә карата искиткеч игътибарлы, чиста күңелле. Консерваториядә композиция бүлеген җитәкләгәндә бик күп студентларга ярдәм итте, киләчәккә юл ярды ул.

Илһам Шакиров, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты:
– Музыка училищесында бер ел укыганнан соң, консерватория студенты булдым. Беренче курстан ук сольфеджиодан безне Мансур ага укыта башлады. Ул консерваториядә композиторлар факультетының кафедра мөдире иде. Без класста 7-8 җырчы гына. Ике сәгать буе Мансур ага өйгә биргән эшләрне тикшереп, яңа дәресләр бирү генә түгел, һәммәбезнең дә тормышы, ничек яшәве турында сораштырып өлгерә иде. Бер атна үттеме, юкмы ул безнең барыбызны да биш бармак кебек белә иде инде. Кемнең алдап-йолдап хәйлә белән укырга маташканын, кемнең чын күңелдән тырышканын, кемнең булырдай, кемнең төшеп калырдай икәнен бик тиз чамалап алды. Кайбер студентлар йомшаграк булып та, чынлап тырышканын күрә икән, Мансур ага искиткеч сабырлык белән аңлатырга, өйрәтергә омтыла. Ә фальшны колагы белән дә, күзе һәм җаны белән дә гаять тиз тоя...

Камера концерты яки симфоник концертмы, яңа опера яки балетмы – боларның берсен дә калдырмыйча тыңларга йөри иде Мансур абый. Ул кеше күзе артык ташланмый торган җиргәрәк урнашкан була, һәм бер генә нотасы да игътибардан читтә калмасын дигән кебек, бөтен барлыгы белән музыка дөньясына кереп чума. Бу заман белән бергә атларга, бер генә яңалыкны да төшереп калдырмаска тырышуының бер дәлиле.

PRESSA.RU

Язык һәм телевизор от!

1 Язык
30.06.2017 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына язык ***(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)***

2 Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр ***(телефон номерыңны күрсәтергә онытма):*** 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 От
Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр!

Акцияне үткәрү вакыты: 15.05.2017 - 20.09.2017

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер - 1261

16+
Реклама

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Идел Болгарында **КАЙСЫ** кала «гаять зур шәһәр» саналган

Наил Дунаев **КЕМ** өчен уйный

НИНДИ шәһәрдә кер юуга багышланган музей бар

Пычак авылы атамасы **КАЙДАН** алынган

PRESSA.RU

ИДЕЛ БОЛГАРЫ ТАРИХЫНДАГЫ АК ТАПЛАР

«ТАТАРСТАН» журналы өчен МАХСУС

Кайвакыт «соңгы елларга кадәр галимнәр ерак тарихыбызның болгарлар чорын гына өйрәнделәр, Алтын Урдага да, Казан ханлыгына да игътибар булмады», дигән сүзләр ишетергә туры килә. Бер карасаң, бу чыннан да шулай. Әмма моңа галимнәр гаепле түгел. Алтын Урда һәм аның «кыйпылчыгы» дип йөртелгән Казан ханлыгы тарихын өйрәнү, йомшак кына әйткәндә, Мәскәү тарафыннан хупланмады. Әле бу, галимнәр гел болгар тарихын өйрәнделәр дә, хәзер бу өлкәдә чишелмәгән проблемалар калмады, дигән сүз түгел. «Ак таплар» күп әле. Бу мәкаләбездә шуларның кайберләренә тукталырбыз.

Автор:
Фаяз Хуҗин

Идел Болгары IX–X гасыр чикләрендә дәүләт буларак оешып бетә һәм тиз арада ул, күрше-тирә (Киев Русе, Хәзәр) һәм ерак Шәрык илләре белән бәйләнешкә кереп, тарих битләрендә үз эзен калдыруга ирешә. Болгарларда рун графикасына нигезләнгән язмачылык борынгы төркиләр чорыннан ук килә, ә X гасыр башларыннан ислам дине белән параллель рәвештә гарәп язуы тарала. XII гасырда исә, Андалусия (Көньяк Испания) гарәбе Абу Хәмид әл-Гарнати хәбәр иткәнчә, болгарларның Йакуб ибн-Ногман кебек үз тарихчылары да булган. Кызганыч, аларның әсәрләре сакланмаган, ә чит ил язучылары (башлыча гарәп-фарсы географлары, сәяхәтчеләр) калдырган хезмәтләрдә болгарларга кагылышлы язмалар бик кыска һәм мәгълүматка ярлы. Шуңа күрә Болгар дәүләтенең монгол-татар яуларына кадәрге тарихын объектив рәвештә һәм теләгәнчә тулы итеп күз алдына китерү мөмкин түгел. Әлбәттә, археология материаллары да безнең өчен бик кыйммәтле чыганак булып хезмәт итә, әмма алар күп очракта бер яклы, башлыча матди культурага караган информация бирәләр.

АЛАРНЫ ӘЛЕ ӨЙРӘНӘСЕ ДӘ, ӨЙРӘНӘСЕ

Археология материаллары нигезендә без Идел Болгары биләп торган территорияне ярыйсы гына төгәл билгели алабыз. Дәүләтнең үзәк биләмәләре Идел белән Кама елгалары кушылган җирләрдә – Кама аръягында урнашкан. Биредә X гасырда ук Биләр, Болгар, Сувар ише эре калалар, йөзләгән авыллар калкып чыккан. Күп санлы болгар истәлекләре (шәһәр-авыл урыннары, борынгы зиратлар, акча һәм әйбер хәзинәләре, аерым табылдыклар) Татарстанның башка төбәкләрендә дә, күрше Чувашиянең көньяк-көнчыгыш районнарында, Ульян, Самара, Пенза якларында да бихисап. Монгол-татар яуларына кадәрге болгарларның эзләре соңгы елларда Әстерхан өлкәсендә (Самосделька шәһәрлеге) һәм Пермь краенда да (Рождествено, Кыласово шәһәрлекләре, мөселман зиратлары) ачылды.

Рус елъязмаларында болгар гаскәрләренең 1229 елда Җаек елгасы тирәсендә монгол-татарлар тарафыннан җиңелүе турында хәбәр урнаштырылган. Күрәсең, Җаек, ягъни Көньяк Урал далалары һәм анда яшәүче халыклар болгарлар контролендә булган, әмма бу якларда, шулай ук хәзерге Башкортостан җирләрендә болгар истәлекләре билгеле түгел.

Соңгы елларда тупланган материаллар Болгар дәүләтенең Идел белән Урал арасында ярыйсы ук зур территория биләп торганлыгын күрсәтәләр. Әмма безнең кулдагы чыганаклар илнең административ-территориаль бүленешен тулырак күзаллау өчен җитәрлек түгел әле. Сувар X гасыр ахырларына кадәр мөстәкыйль бер кенәзлекнең (билекнең) баш шәһәре булгандыр дип фаразлана, чөнки биредә, Болгар каласындагы кебек үк, акча сугу үзәге дә булган. Ошель/Ашлы – Иделнең уң ягындагы төбәкләрдә яшәүче болгарларның административ үзәге. Шундый ук үзәкләр вазыйфасын Самара якларында Муром шәһәрлеге, Пенза якларында Юл (Юлово) шәһәрлегенә үтәгән. Кашан белән Җүкәтау да аерым төбәк үзәкләре булгандыр дип фаразлана. Кызганыч, әлеге шәһәрләр дә, аларның тирә-юнендәге археологик истәлекләр дә әлегә начар өйрәнелгән.

Фотолар автордан алынды

КЕМНӘР АЛАР – СЛАВЯНМЫ, ТӨРКИМЕ?

Идел Болгары күз алдыбызга күпмилләтле дәүләт буларак килеп баса. Болгарлар килеп утырыр алдыннан безнең якларда имәнкискә кабиләләре яшәгән. Идел–Кама төбәкләрендә аларның 600дән артык (!) археологик истәлекләре билгеле. Имәнкискәлеләрнең этник йөзен галимнәр әле һаман ачыклый алмыйлар. Кемнәр алар – славяннармы, әллә төркиләшкән сарматлармы? Бүгенге көндә фәндә шушы ике фараз өстенлек итә. Беренче караш тарафдарлары күбрәк. Бу версияне бигрәк тә Мәскәү галимнәре алга сөрәләр. Имәнкискәлеләрне, болгарлар килеп утыргач, тулысынча көньяк-көнбатышка, славяннар җиренә кысрыклап чыгарылган кабиләләр дип санныйлар. Шик юк, аларның бер өлеше, Идел-Кама төбәгендә калып, болгарлар белән кушылып беткән булырга тиеш. Академик В.В. Седов, мәсәлән, славяннар Дунай буйларында Дунай Болгариясен, Урта Иделдә исә Идел Болгарын оештыруда актив катнашканнар, дип язып чыкты, тикмәгә генә Ибн Фадлан Алмышны сәкалиблар/славяннар патшасы дип атамаган, имеш.

Кыскасы, имәнкискәлеләрнең этник йөзен ачыклау принципиаль характердагы проблемага әйләнеп бара. Сораулар күп. Аларга җавап табу өчен максатчан казу эшләрен җанландырып җибәрергә кирәк. Кызганыч, Татарстан Фәннәр академиясенең Археология институтында әлеге проблема белән шөгыльләнүче татар белгечләре юк.

Тарихчылар арасында еш кына, Болгар дәүләте чикләрендә яшәгән халыклар арасында болгарлар үзләре күпчелекне тәшкил итмәгән, шунлыктан алар элек-электән бирелә яшәгән абориген фин-угыр халыклары тарафыннан йотылып беткән булырга охшый, дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Болгарларның антропологик сыйфатлары фин-угырларныкына якын, имеш. Сафсата! Йотылып беткәннәр икән, нишләп соң алар, исемнәрен һәм бигрәк тә телләрен саклап калганнар? Матди культуралары да, рухи мәдәниятләре дә төрки бабаларының борынгы традицияләрен дәвам итә? Аннан соң шуны да онытмаска кирәк: болгарлардан кала Урта Иделгә бит Хәзәр иленнән тугандаш барсил/берсула, сувар, бәләнҗәр ише кабиләләр дә күченеп килә. Аларның саны аз булгандыр дип уйламыйм. Ә менә болгарлар килеп төпләнгәнчегә кадәр дә, аннан соң да Идел Болгары калкып чыгачак территориядә фин-угыр археологиясенә караган истәлекләр юк дәрәҗәсендә.

Фин-угыр телләре төркеменә кергән мари, удмурт, мордва, коми ише халыкларның борынгы бабалары болгарларның якын күршеләре булган. Аралашып яшәгәннәр, әлбәттә. Бәгланышлар бер яклы гына булмагандыр дип уйларга кирәк. Менә шул бәйланышларны археология, антропология, фольклор һәм тел материалларына таянып өйрәнү безнең киләчәк бурычыбыз булырга тиеш.

Болгар чоры яугире. XII гасыр азагы – XIII гасыр башы. О.В. Федоров реконструкциясе.

БОЛГАР-БИЛӘР ПРОБЛЕМАСЫ

Идел Болгарының әүвәлге башкаласы кайда булган – хәзерге Болгардамы, Биләрдәме? Бу сорауга галимнәр XIX йөздә үк җавап бирергә тырышып караганнар. Күренекле Шәрык белгече В.В. Григорьев әле 1836 елда ук Биләр һәм Болгар/Бл'ар атамаларының мәгънәләре бер һәм алар тамыры Б-л-р булган сүзнең ике төрле диалекттагы әйтелеше генә», – дип язып калдырган. Болгар иленең башкаласы мәсьәләсенә килгәндә, Григорьев аны Болгарда түгел, ә Биләрдә булгандыр дип уйлаган. Сүз уңаенда әйтеп үтик: Болгар-Биләр тиңдәшлеген лингвистик яктан XIX йөздә Н.И. Золотницкий, безнең көннәрдә Польша галиме М. Адамович яңадан исбатладылар.

Казан университеты профессоры С.М. Шпилевский 1877 елда чыккан китабында яңа концепция тәкъдим итә: X гасыр башыннан алып XII гасыр урталарына кадәр Болгар иленең башкаласы Болгарда була, соңыннан еш кабатланып торган рус яулары хан резиденциясен Биләргә, ягъни тынычрак урынга күчерергә мәҗбүр итәләр.

Биләр төзелә. Ф. Халиков картинасы.

PRESSA.RU

Алтын һәм көмеш йөгертеп эшләнгән бизәкле Коръән савыты. Эрмитажда сакланучы Борынгы Болгар Коръән савытының репликасы (күчерелмә нөсхәсе). Автор: Р.А. Мөхәммәтшин. Казан Кремле музее.

Биләрдә табылган фаянс тустаган. XI гасыр. Иран яки Гыйрак җирлегендә эшләнгән дип фаразлана.

Аббасидлар династиясе хәлифләренең көмеш дирһәмнәре. VIII-X гг.

Болгар хакиме. XII-XIII гг. М.В. Горелик реконструкциясе.

С.М. Шпилевскийның бу фаразына кискен каршы чыгучылар булуга карамастан (А.А. Спицын, П.А. Пономарев, М.Г. Худяков, А.С. Башкиров, В.Ф. Смолин), 1938 елда Болгар шәһәрлегендә системалы рәвештә казу эшләрен башлап җибәргән Мәскәү профессоры А.П. Смирнов тырышлыгы белән «Болгар – беренче башкала» концепциясе төрле бәхәсләргә урын калдырмаслык итеп рәсмиләштерелә.

1967 елда күренекле археолог профессор А.Х. Халиков җитәкчелегендә Биләрдә киң масштаблы казу эшләре башланып китә. Моңа кадәр археологлар биредә 1915 һәм 1928 елларда гына эшләп алалар, Биләр алар өчен чын мәгънәдә Terra incognita була. Яңа ачышлар А.Х. Халиковны инде күптән онытылган бәхәсләрне яңартып җибәрергә мәҗбүр итәләр.

1973–1975 елларда Мәскәүдә чыга торган «Советская археология» журналында Биләр–Болгар проблемасына багышланган мәкаләләр басылып чыкты. Әлеге мәкалә авторлары, А.П. Смирнов, Т.А. Хлебникова, Р.Г. Фәхретдинов кебек болгарчы-галимнәр, С.М. Шпилевский концепциясен яклап чыксалар, А.Х. Халиков исә В.В. Григорьевның «Биләр–Болгар дәүләтенең монгол яуларына кадәрге бердәнбер башкаласы» дигән фаразын яңа ачышлар нигезендә исбатларга омтылып карады. Соңрак әлеге бәхәсләргә бу юлларның авторы да кушылып китте.

Кайберүләр, археологлар гадәттә үзләре казып тикшерә торган истәлекнең тарихи әһәмиятен күпертеп күрсәтергә яраталар дип, мәсьәләгә җиңел генә карасалар да, яңадан күтәрелгән проблема бик җитди һәм катлаулы иде. Моның өчен инде күптән билгеле тарихи чыганакларны да яңа күзлектән карап тикшерергә кирәк иде.

Башта шуны искәртеп үтик: борынгы урыс елъязмаларында монгол-татар яуларына кадәрге вакыйгалар турында сүз барганда Болгар шәһәре бер тапкыр да телгә алынмый, Биләр исә Олуг шәһәр («Великий город на Черемшане») исеме белән 6 мәртәбә телгә алына (дөрес, бары тик 1164 елдан башлап). Аның каравы, Болгар белән Сувар турында X гасырның беренче яртысында яшәгән гарәп географлары язалар. Әл-Балхи хезмәтендә, мәсәлән, мондый юллар бар: «Болгар – халкы ислам дине тотучы илнең һәм Җәмигъ мәчете булган шәһәрнең исеме. Аннан ерак түгел җирдә тагын бер шәһәр урнашкан, Сувар исемле, биредә дә Җәмигъ мәчете бар. Бу шәһәрләрнең икесендә дә халык саны 10 меңгә җитә». 1135–1136 һәм 1150 елларда Болгар илендә булып киткән гарәп сәяхәтчесе Әбү Хәмид әл-Гарнати: «Болгар – гаять зур шәһәр, бөтенләе белән нараттан салынган, ә шәһәр диварлары – имәннән», – дип язып калдырган.

Дөнья картасы. Әл-Истәхри.
Б.э.ның 934 елы.

Кош рәвешендә ясалган атаклы
Болгар алкалары.
Болгар зәркәнчеләре тарафыннан
XI-XIII гасырларда эшләнгән.

КАЙДА СИН, ЗУР ШӘҺӘР?

Нинди «гаять зур шәһәр» турында язганнар икән соң алар? Биләр белән Болгарның монгол яуларына кадәрге мәйданнарын чагыштырып карыйк: Биләр 620 гектар (шәһәр яны бистәләре белән 800 га) мәйданда урнашкан, Болгарның X–XI гасырдагы мәйданы 9 гектар (бистәләре белән 12 га), XII гасырда ул 25, бистәләре белән 35–40 гектарга кадәр киңәя.

Безне нәкъ менә X–XI гасырлар кызыксындыра, чөнки Биләрнең XII гасыр урталарында башкалага әверелүе беркемдә дә шик уятмый. Димәк, Болгарның ныгытылган мәйданы 9 гектар. Шуның 1 гектар (100 х 100 м) чамасын хан резиденциясе биләп торган дип фаразлыйк. Тагын бер гектарын урамнарга, җәмәгать биналарына, шул исәптән мәчеткә һәм аның каршындагы мәйданга «бирик». Һөнәрче остаханәләре булганын да онытмыйк. Шәһәр халкы яши торган йортлар 7 гектар, бистәләрен дә кертеп 9–10 гектар җирдә урнашкан булып чыга. Халык саны күпме булган? Әл-Балхи хезмәтендә күрсәтелгән 10 меңме? Ай-һай, 1,5–2 меңнән артмагандыр, минемчә (якынча үзегез дә исәпләп чыгара алачсыз). Халкы 10 меңгә җиткән шәһәр ул заманнар өчен бик зур шәһәр инде ул, Биләрдә дә шулкадәр үк халык яшәде микән әле, шигем бар. Нәтиҗә: Әл-Балхи Болгар турында язганда хәзерге Болгарны түгел, башка шәһәрне күз алдында тоткан. Бу шәһәрнең Биләр булуы мөмкин.

Хәзер Болгарда берөзлексез 80 ел чамасы алып барылган археология материалларына мөрәҗәгать итик. Искәртеп үтәм: Болгарны өйрәнүче археологлар үзләре дә шәһәрнең монголларга кадәрге, бигрәк тә X–XI йөзләрдәге тарихын, тышкы «кыяфәтен» юньләп күз алдына китерә алмыйлар. Чөнки шул чорларда тупланган борынгы катламнардан чыккан табылдыклар һәм корылмалар күп түгел. Әз булса да торак йорт һәм хуҗалык чокырлары бар әле, һөнәрчелек эзләре дә сакланган, әмма таш-кирпечтән салынган биналар юк, мәчет урыны да билгеле түгел. Мондый шәһәрне дәүләтнең башкаласы сыйфатында күз алдына китерүе кыен, әлбәттә.

Биләрдә, гәрчә ул әлегә бик начар өйрәнелгән булса да, башка хәл. Аэрофото материалларына караганда, биредә өч дистәдән артык кирпеч бина булган. Казып тикшерелгән өч бинаның икесе X гасырда төзелгән. Эчке шәһәр уртасында торгызылган Җәмигъ мәчет – мәйданы 2500 квадрат метрга җиткән таш һәм агач бина – уникаль архитектура корылмасы. Ул тарихи 922 елда төзелгән дип фаразлана. Аның янында ак таштан салынган төрбәләрдә югары катлау кешеләре күмелгән некрополь – «ханнар зираты».

Биләр белән Болгарны археологик яктан чагыштыру, минемчә, Болгар иленең әүвәлге башкаласы проблемасын дөрес хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк. Бу өлкәдә тикшеренүләрне киләчәктә дә дәвам итәргә кирәк, дип саныйм.

Болгар хатын-кызлары кия торган кием.
VIII-X гг. О.Р. Гасыймов реконструкциясе.

PRESSA.RU

«ТАЛАНТЛЫ ТАМАШАЧЫ ӨЧЕН УЙНЫЙМ...»

«И матур да кеше инде безнең бу Дунай», – дип, чын күңелдән сокланa иде әнием, әбиләрем, түтиләрем. Телевизор экранында ул пәйда булса, кырык эшләре ярылып ятуга кармастан, шунда ук экранга капланалар. Ә өйдәге ир затлары, сабыр һәм тыенкы гына: «Шәп уйный шул», – дип хуплыйлар һәм үзләренчә, ирләрчә, якын итәләр иде аны. Ә мин әле аңлап җиткерә алмыйм: нишләп «безнеке»? Якташыбызмы? Ерак туганмы?! Сәхнәгә «Гөргөри кияүләре» чыккач, аңладым. Якын туган икән.

Автор:
Луиза Янсуар

Аның шундый бер гыйбарәсе бар: «Тискәре геройларымның да уңай якларын эзләдем». Безнең сөйләшү барышында ул моны бераз гына башкачарак формалаштырды: «Тормышта бу авыррак бирелә шул...» «Димәк, тормыш белән сәхнә барыбер дә аерыла?», – дип елмаям. Ә ул, киресенчә, җитдиләнә төшә: «Әлбәттә, аерыла. Сәхнәгә инде синең аша үтеп, режиссер тарафыннан фильтрланып, күпмедер дәрәҗәдә типаж рәвешен алган, тамашачы кабул итәргә әзер образ чыга. Хәер, монда тамашачының таланты да бик мөһим. Кемдер өстә яткан нәрсәләрне, бик примитив моментларны гына тотып ала, кемдер әллә никадәр катламнар ача, гүя синең белән бу рольне бергәләп эшләгән, кичергән... Әнә шундый тамашачы өчен уйныйм мин – һәр чыгуымда...»

Кызганыч, мин аның театр дөньясын шаулаткан, соклану, бәхәсләр уяткан, матбугатта яңгыраган Тукаен, Фигаросын, Шамил Усмановын, Газизен, Сәярен, Азнаен, Паратовын, Бәхтиярен, Хаинен, шулай дип әйтергә яраса, «яшьлек рольләре»н күрмәдем. Кайберләрен телевидение язмаларында күрдем-күрүен, әмма театр залыннан күрү белән экраннан күрү – җир белән күк арасы.

Күз алдыма беренче булып «Өч аршын җир»дәге Мирвәли сурәтендә килеп басты ул. Образы ничек кенә каршылыклы булмасын, аяз көндә суккан яшендәй тәэсир... һәм әсир итте. Хәзер аңлыйм: Мирвәли-Дунайның фаҗигасе безне, 80нче елларда туып-үскән яшүсмерләрне, зур катаклизмнар артында җимерүче яисә җимерелгән кеше язмышлары торуына төшендергән икән. Бу спектакльне ул вакытта телевизордан еш күрсәттеләр. Аяз Гыйләҗевне кулына алып карамаучыларны да Дунай тудырган образ уйландыра, тетрәндерә иде. Ә аннары аның «Бичура»дагы Күрше роле инде авылларыбызның һәм тулы бер дәвернең кая тәгәрәвенә аермачык күрсәткеч булды.

Очраштык та озаклап сөйләшеп утырырга җай таптык әле бу көндәлек шәһәр ыгы-зыгысында. Станиславский һәм Хрущев, бал кортлары һәм Третьяков музее, керәшеннәр һәм пентатоника турында...

Сүзне «үзебезнең Дунай»га тапшырам.

УЛ ТӨШНЕ МИҢА КАТ-КАТ СӨЙЛӘТТЕЛӘР...

– Әти сугышка җиде кат барып, җиде тапкыр кире кайтарылган кеше. Соңгы кайтуын яхшы хәтерлим. Бер иртәне уянып киттем дә әнигә төшемне сөйлим: имеш, әти комбайнны хәтәрләткән ниндидер зур бер машина алдына утырган да юлны кардан көрәк белән як-якка чистартып кайтып килә.

Ул төшне кат-кат сөйләттеләр, яхшыга юрадылар. Икенче көнне кичкә таба, ни күзебез белән күрик, бакча артыннан бил тиңентен кар ерып әти кайтып кермәсенме! Казаннан аңа район военкоматына тапшырыр өчен белешмә дә биреп җибәргәннәр булып чыкты. Анда «бу кешене кабат җибәрмәгез» дип язылган иде.

БАЛ КОРТЫНА ТИМӘГЕЗ!

– Әтием – умартачы Иван – җаны-тәне белән үз һөнәренең остасы иде. Колхоз чүннигендә 150 баш умарта тотты ул. Шуннан артыгын үрчетергә ярамый. Планны үтәргә генә кушылган. Әти Мәскәүдән умарта карау буенча газета-журналлар яздыртып ала иде, аларны җентекләп өйрәнә. Ул кортларны бала урынына күрде, бөтен күңелен биреп хәстәрләде. Без – мин, Вера түтам, Игнат дәдәм – аның уң куллары.

Мин бик җитез булганмын, күрәсең, умарта күч аерганда агач башына баскычсыз-нисез елдам гына үрмәләп менеп китәм дә аерып алып төшәм. Әле дә хәтеремдә: җәйнең иң эссе вакытында гектарлаган чүнникнең бер башыннан икенче башына авыр-авыр балы рамалар тутырылган тартмаларны омшанникка ташыйсың. Рамнар өстендәге балавызны юнып алып, балларын суыртасың. Кич җиткәч, бал тутырылган кисмәкләрне төяп, урман буйлатып күрше Кадер авылына – складка бал тапшырырга китәсең. Син балны үлчәтеп, тапшырып кайтып җиткәндә, авыл яшьләре инде уеннан тарала башлаган була, шунысы үзәкне өзә иде.

Кызганыч, Хрущев сәясәте башлангач, умартачылык эшенә зур зыян килде. Әти моңа бик әрнеде. Сүзләре хәтердә: «Бал кортының авыл хуҗалыгына бернинди зыяны тигәне юк, ул тик үз җае белән оча, басу-кырларны серкәләндерә, шуннан бал җыеп алып кайта. Аннары үз эшен мыштым гына оясында башкара. Ничек шул тырыш-булдыклы бөҗәккә кул күтәреп була инде, җә?!»

«КАЯН ОЧАСЫ КИЛСӘ, ШУННАН ОЧСЫН»

– Чүнниктән ерак түгел, икенче аланлыкта үзебезнең умарта бар иде – анда 30–40 баш умарта. Әти өстеннән анонимкалар язылганлыгы ачыкланды берзаман. Нишләп ята ул урманда, янәсе? Мылтыгы, наганы да бар икән үзе белән, имеш.

Дүрт кеше өйгә килделәр: район милиция начальнигы, авыл



Фотолар: Юлия Калинина, Наил Дунаевның шәхси архивыннан

PRESSA.RU

1

2

3

1. А. Островский «Бирнәсез кыз». Паратов ролендә. 1983 ел.

2. П. Бомарше. «Шау-шулы көн, яки Фигароның өйләнүе». Фигаро ролендә. 1970 ел.

3. Т. Миңнуллин «Гөргөри кияүләре». Гөргөри ролендә. 1995 ел.

советы рәисе, колхоз рәисе, тагын бер кораллы кеше. Безне урамга куып чыгардылар. Тентүне караңгы төшкәч кенә тәмамлап, атларына утырып китеп бардылар. Шөкер, этине алып китмәделәр.

Аннары аны тикшерергә дип Хрущев заманында да килгәләделәр. Крестьянга биш баштан артык умарта тотарга ярамагач, эти эчтән бүленгән озын умарталар ясады. Кортлар ике баштан да чыгып оча. Авыл халкы бер умартада берничә баш умарта тота икән, дип «властька» җиткергән. Кәефләрәк чакта эти үзе дә мактанып сөйләп ташлагандыр инде, күрәсең.

Тагын килделәр, сорыйлар: «Иван дәдәй, – диләр, – нишләп синең умарталарың теге тишектән дә, бу тишектән дә очып чыгып йөри соң?» Эти боларга сабыр гына җавап кайтара: «Ник шуңа аптырыйсыз, корт ич ул, кай җирдән тишсәң, шуннан очып чыга инде, менә бу урыннан тишсәң, хәтта моннан да...» Шулай ди дә, үзе бармагы белән умарта түбәсенә төртеп күрсәтә. Тегеләр, умарта серләренең тамчысын да белмәгән бәндәләр, ни әйтергә белми аптырап тик басып торалар.

«ӘЛЛӘ КЛУБ САЛАСЫҢМЫ, ИВАН ДӘДӘЙ?»

– Бик оста кеше иде ул: итеген дә үзе басты, бүреген дә үзе текте, өебезне дә балкытып үз куллары белән торгызып куйды. Мичене кадәр үзе чыгарды. Бура бурап куйгач, авыл халкы төрттеребрәк: «Әллә клуб саласыңмы, Иван дәдәй», – дип дәшеп узгалады. Чөнки ул бураны уртадан бүлмәде, бүрәнә буе белән озын итеп сузды. Инде эти өйне салып бетергәч, авылдашлар да өйләрен безнекенә охшатып сала башлады.

Ясаган умарталары да шкатулка кебек ялт итеп тора иде. Шулай бервакыт, инде олыгая төшкәч, ишегалдында утырганда, меңәрләп өелеп, эленеп торган рамнарына озак карап торды-торды да, әйтеп куйды: «Бу йортка бездән соң кереп утырган кеше, нигә дип шулкадәр чыра телде икән бу дурак, дип көләр инде миннән». Бу аның Игнат дәдәй белән миңа төрттерүе, үзенчә шелтәсе иде. Нигездә калмыйсыз бит, димәк, ул таралачак, диюе.

Еллар үткәч кенә мин бу сүзләрне бар тирәнлегендә аңладым. «Бичура» спектаклендә минем килмешәк ролем бар. Акылга зәгыйфь бер хатынга кереп көн итүче әнә шул килмешәкне уйнаганда безнең авыллардагы ятим нигезләр турында уйландым. Бик негатив образ ул килмешәк – пьеса буенча. Әмма мин аны ягымлы, халык ярата торган итеп уйнарга тырыштым. Сәхнәгә сарык ияртеп алып чыгып булмый бит, ә халыкка аңлатырга, күрсәтергә кирәк. Шунда мин бау күтәреп чыгам да, үземне иләс-миләс тотам: «Күрше, – дим, – минем бит хәзер сарыгым бар!» Биеп китәм... Янәсе, менә, мин дә адәм хуры түгел, карагыз, минем дә малым барлыкка килде, мин дә – нәкъ сезнең кебек...»

Аны уйнаганда Мәскәүдән килгән театр тәнкыйтьчеләре дә утыра иде залда. Фәрит Бикчәнтәев кинәт: «Блестяще!» – дип кычкырып җибәрмәсенме. Бу – режиссер тарафыннан актерга карата сирәк була торган югары бәя.

КҮҢЕЛЕМДӘГЕ БӘЙРӘМ УЛ – ӘНИ

– Без биш бала үстек. Һәммәбезне карап, тиешле тәрбия биреп, тәртиптә тоту, гомумән, гаиләучагын кирәкле температурада саклау – монысы әни җилкәсендә иде. Барлык йорт мәшәкате, гаилә бюджеты өчен дә ул җаваплы.

Коеп куйган бер чибәр булмаса да, туган-тумача да, барлык бала-чага да аны «Матур түти» дип атап йөртте. Кеше хакын хаклый белә, ягымлы бер эчке матурлыкка, үзенә тартып тора торган көчкә ия зат иде әни. Бәлки, шуңа да безнең өйдән кеше өзелмәде, өстәлдән ризык төшмәде. Бер партия кунак торып китүгә, өстәлнең икенче башында яңа партия кунак өчен табын әзер була торган иде. Артык бай да, ярлы да яшәмәдек. Әмма әнинең өйгә аяк баскан һәр кеше өчен сые да, ягымлы йөзе белән сүзе дә әзер булды.

Килен булып кайткач, хатыным Таня, бу хәлне күреп, сездә гел шундый конвейермы дип, бик гаҗәпләнде. Аннары үзе дә ияләште. Әни телне йотарлык итеп ризык әзерли иде, бигрәк тә бәйрәм ашларын. Ә керәшендә, үзең беләсең, бәйрәмнәр күп!

Ул җыйнак кына, бәләкәй генә гәүдәле булса да, сулышы иркен, тавышы моңлы иде. Аш-сулардан бер дә калдырмыйлар иде әнкәйне. Башлап җырлаучы булып йөрде ул мәҗлесләрдә. Безнең театр ар-

тистлары авылда гастрольдә, бездә кунакта булганда, өч сеңел – Софья, Мария, Ульяна, ягъни минем әни, – аларга өч тавышка җырлап, кич буе сыйлаганнар үзләрен.

Табын вакытында, бәйрәм җыеннарында җырлаганда әни, җырудан тукталып торып, кемгә нәрсә эшләргә икәнлеген күрсәтә иде дә, туктаган урыныннан кабат җырлап китә иде. Әйтерсең, эчтә көйләп куйган бер механизмы бар. Ә эти аны һәрчак, исе китеп, йотлыгып тыңлый белә иде.

ЗӘЙ БАЗАРЫННАН КАЙТКАН «КЫДЫЛ БОДАУ»

– Без атеизм хөкем сөргән чорда үстек. Мәчеттә – мәктәп, чиркәүдә клуб иде. Мәләкәс авылында Питрауны нәкъ 12 июльдә бәйрәм итәләр. Бөтен тирә-як керәшеннәре Төнге Питрауга җыела. Кичкә таба ак җон носкиларын, җалтыраткан калушларын кулга алалар да, түтиләр, агайларны ияртеп, бәйрәм күлмәкләрен күтәреп, Зичә елгасын ерып чыгып, тауга менеп китәләр. Тауның аръягында – Мәләкәс. Зичә буенда авыл советы председателе һәм җирле идарә кешеләре аларны туктатырга маташа. Тик туктатып кала алмыйлар барыбер.

Безнең авылда Татар очы һәм Керәшен очы бар иде. Татар очындагы мәчетне Мәннан хаҗи абзый төзеткән. Ул заманында тегермәннәр тоткан, бик хәлле, гадел кеше булган. Минем этине ындыр артында лобогрейка белән урак урып йөргән җирендә күреп алып, яхшы түләрмен, кил тегермәнгә, дип, үзенә эшкә алган. Эти дөбер-шатыр әйләнгән тегермәннең боз сала торган урынына уклау кебек бер таяк кыстырып куеп, аның тавышын басу җаен тапкан. Хаҗи абзый аңа зур рәхмәтләр укып, үзендә эштә калдырган, ярдәм иткән. «Миннән бер постау костюм – күчтәнәч!» – дигән. Әтинең, бай сүзендә торды, урыны оҗмахта булсын, дип искә алганнарын әле дә хәтерлим. Мөнә шул хаҗи төзеткән айлы мәчеткә башлангыч класска укырга йөрдек без.

Искиткеч матур мәчет иде ул! Ул елларда, галимнәрдән ишеткәнем бар, Татарстанда ае киселмәгән өч кенә мәчет калган булган икән. Шуның берсе – безнең Әхмәт мәчете. Бала-чага вакытта белмәгәнбез генә, үсә төшкәч төшендек: төннәрен, каравылчы Фазыл абыйдан мәчетне ачтырып, шунда керең намаз укый торган булган авылның аеруча дини кешеләре. Мөхәммәт абзый исемле мөәзин бар иде авылда. Ул ясин чыгарга да барды, бала тугач та йөрде.

Чиркәвебез агачтан төзелгән иде, без инде аны «клуб» дип үстек. Хәзер аны сүттеләр, урынында хач тора. Без үскәндә керәшеннәр келәүгә Поповка дигән авылга йөри иделәр, анда иман укый торган керәшен кешесе булган. Ул чакта поплар юк, бала чумылдыруларны да шунда башкарганнар, күрәсең.

Безнең бәйрәмнәрне исә Татар очы да, үзебезнекеләр дә җыйнаулашып бәйрәм иттек гел. Күкәй җыюлар, тәгәрәтүләр дисеңме. Май чабу вакытында бөтен тирә-як авыллары базарга килә. Ул да уртак җыенга әверелә.

Көнкүрештә, бәйрәмнәрдә аерылу юк иде, әмма сөйләмдә – бар. Моның серенә һаман төшенә алганым юк: югыйсә бер совет мәктәбендә укучы балалар бит, бер авылда яшәүче, әмма Татар очлары «кыдыл бодау» дип сөйләшә, без, Керәшен очлары, рәхәтләндереп зырылдатабыз. Тегеләрне такмак әйтеп үрти дә идек хәтта: «Безнең эти Зәй базарыннан кызыл бозау апкайтты, үзе таза, үзе симез, үзе зерә зур!» Ә алар «з» хәрефен әйтә алмагач, нишләсеннәр, кабатларга оялалар инде.

ДИН – СӘЯСӘТ ТҮГЕЛ, ДИН – ИМАН

– Миңа соңгы вакытта дин белән сәясәтне бергә укмаштыра башлаулары ошамый. Дин – сакраль әйбер, ул иман, кешенең эчке инануы. Ә хәзер ничек килеп чыга? Маяковскийның теге атаклы шигырендәгечә: «Мы говорим Ленин, подразумеваем – партия, мы говорим партия, подразумеваем – Ленин», дигәндәй. Бу – куркыныч юл. Беркайчан да дин белән милләт арасына тигезлек билгесе куярга һәм динне сәясәткә тыкшындырырга ярамый. Яшәсен мәхәлләләр үз рухани тормышы белән, халыкны агартсын, арулндырсын. Һәр дин вәкиле – үзенекен. Ә дәүләт эше белән белдекле, акыллы сәясәтчеләр шөгыльләнсен, поплар да, имамнар да, раввиннар да түгел.

Милләт, этнос, субэтнослар мәсьәләсенә килгәндә, иманым камил: аларны, иң беренче чиратта, тел саклый, гасырлар буе тупланган рухи кыйммәтләр – җырулары, биюләре, милли эшләнмәләре, уен кораллары, традицияләре. Диннәр безне, инде XXI гасырда яшәсәк тә, һаман яу чабарга гына этәрә. Аяныч күренеш.

– Мәскәүгә укырга киткәндә, әни мине олы юлга, күпер башына кадәр ат белән озата барды. Аерылганда бары бер җөмлә әйтте: – Улым, Аллага ышанмасаң да, күңелеңнән өзеп беркайчан да ул юк, дип әйтмә, яме.

ЧИБӘР БИТ, КАҺӘРЕҢ!

– Бер районнан булсак та, булачак хатыным белән беренче мәртәбә Мәскәүдә генә очраштык. Түбән Биш авылында белем алабыз. Минем алдагы партада Кабан-Бастырык авылы кызы Зина утыра. Көннәрдән бер көнне бу Алабугада библиотека техникумында укучы ахирәтеннән хат алган, хат эчендә кечкенә фото да бар икән. Бөтен класс мәш килеп шул фотоны карый. Кулдан-кулга йөри торгач, миңа да килеп җитте. Нәкъ шул вакытта дәрес башланырга дәшеп кыңгырау шалтырады. Фото миндә калды. Бер карыйм, ике... Чибәр бит, каһәрең! Зинадан ул кызның адресын алып, Алабугага хат яздым. Җавап килмәде.

Институтка кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырып, йөк машинасы кузовына утырып, Мәскәүгә Щепкин исемендәге театр училищесына укырга китеп барам. Кирәк бит, каршы килүче йөк машинасы кузовында Зина кайтып килә. «Татый да Мәскәүгә китте, шуны озатып кайтып киләм», – дип кычкырды ул миңа.

Мәскәүгә килдем, укулар башланды. Башта уй: «Татый кайсы институтка керде икән? Библиотечныйгадыр инде...»

Көннәрдән бер көнне якташым һәм сабакташым Батулла белән җыендык та киттек Левобережныйга – библиотека институтына. Эзләп таптык. Татьяна Батаева дигән кыз, чыннан да, шушында укый булып чыкты.

Таня институтны бездән алданрак тәмамлап, Казанга кайтып китте һәм Ленин библиотекасына эшкә урнашты. Без бер елга соңрак кайттык. Тормыш җиңел

PRESSA.RU

Татьяна белән Кызыл мәйданда. 1 Май, 1958 ел.

генә башланмады. Хезмәт хакы аз, вәгъдә ителгән фатирлар бирелмәде. Хәер, без бит барыбер өйләнешәсе, дидек тә, киттек ЗАГСка. Анда паспортны карадылар да, пропискасы юк икәнне күрделәр. Минем паспортның срогы да чыккан булды. «Сез кайда эшлисез соң?» – дип сорадылар. «Театрда», – дим. Бик шөбһәле генә карап: «Ах, театрда!» – диделәр дә, безне бөтенләй борып чыгардылар.

Инде паспортны рәтләп, пропискаларга кереп, икенче тапкыр ЗАГС ишеген без өчәүләп – Таня, мин һәм улыбыз Владик – ачтык. Кияү егете булып Туфан Миңнуллин, кәләш ахирәте булып Нәҗибә Ихсанова бардылар. Ак фаталар, кара смокинглар киеп шаулатып туйлар үткәрмәсәк тә, шөкер, гомер буе иңгә-иң куеп яшибез. Ә теге безне таныштырган шедевраль фото миндә әле һаман да саклана, хәзер инде гаилә альбомында, билгеле.

ПАРТНЕРШАЛАРЫМА ҺӘРЧАК ГАШЫЙК БУЛАМ

– Миңа үз театрыбызның иң чибәр, затлы актрисалары белән партнер булырга насыйп булды: Шаха, ягъни Шахсәнәм Әсфәндиятовадан башлап, Рузия Мотыйгуллина, Алсу Гайнуллиналарга кадәр. Инде хәзер, менә, яшьләр белән уйныйбыз. Щепкинчыларга караган актрисалар турында әйтеп тә тормыйм, анысы табигый.

Партнершаларыма һәрчак гашыйк була идем. Ничек инде гашыйк булмыйсың – син бит адәм баласы, таш кисәге түгел. Мин гомумән еш гашыйк булучан кеше, бар андый гөнаһым, аны яшермим дә. Гашыйк булуны гөнаһка санарга яраса, әлбәттә. Әмма Таня көнләшә торган хатын булмады, ул минем профессиям үзенчәлекләрен аңлады. Мин аңардан бик нык уңдым.

Гаилә мәхәббәте – ул бөтенләй башка нәрсә бит. Баштарак бер-береңә ияләшү, холык-фигыльләрне өйрәнү, аннары, инде уртак яшәеш нигезен булдыргач, бер-береңә терәк булу, дус булу. Безнең Таня белән сөйләшер сүзебез бар. Мин – аны, ул мине хөрмәт итәбез. Ул – фән кешесе, мин – иҗадирак шәхес. Хисләрәктер дә, бәлки. Ләкин шулай кызыграк та бит…

Гаиләне хатын-кыз саклыймы, ир-атмы – анык кына әйтә алмыйм. Төрле гаиләдә төрлечәдер. Безнең бу мәсьәләне анализлап утырганыбыз булмады, ничек булдыра алдык, шулай яшәдек.

ОЧРАКЛЫ БУЛМАГАН ОЧРАКЛЫК

«Мин сәхнәгә очраклы килеп эләктем», – дияргә ярата ул. Әмма кояш астында бер генә нәрсә дә очраклы түгел. «Щепкинга укырга барганда үз районыбызның, тирә-як авылларның атказанган артисты идем инде мин», – ди дә көлеп җибәрә Николай Дәдәй. Ә сәбәпчесе – Түбән Биш мәктәбендә аларны укыткан әдәбият укытучысы Мәрвәрия Җиһаншина. Ул, укытырга кайтканчы, Казанда театр белән сихерләнгән була. Мәктәп укучыларына Камал театры спектакльләре турында сөйли, сөйләп кенә калмый, уйнап та күрсәтә. Балаларны җыеп, драма түгәрәге оештырып җибәрә.

– Мин туып-үскән яклар ул чакларда бигрәк караңгы яклар иде. Менә шул кара авыл малае Мәскәүнең данлыклы уку йортына укырга керсен инде! Казаннан озатканда безне кисәттеләр: кайда эләккәнегезне белегез, бу һәркемгә тәтеми, белем туплагыз, җүләр сатып йөрмәгез.

Педагогыбыз Гладков искиткеч кеше иде. Табигый, мантыйклы итеп уйнарга өйрәтте. Театрда «раствориться в актере» дигән төшенчә бар. Үзе күләгәдә кала – галиҗәнап актерга бирә иде бөтен мөмкинлекне. Мәскәүдә укыганда, безгә чын мәгънәсендә мәдәни ликбез уздырдылар. Махсус беркетелгән кураторыбыз бар иде: бөтен театрларга, музейларга, истәлекле урыннарга йөртеп чыкты. ИЗО дәресләре Третьяковкада уза иде! Йосыпов, Шереметьев сарайлары, Останкино, Лев Толстой утары, ВДНХ – берсе дә калмады…

Большой театрда беренче күргән спектаклем «Князь Игорь» булды. Андагы кыпчаклар биюеннән әсир булып, күземә яшь килде хәтта. Икенче спектакль «Король Лир» иде. Һич онытасым юк: спектакль бетми дә, бетми. Ярар, театр шулай булырга тиештер инде, дип, сабырымны җыеп утырам да, утырам. Театрдан чыкканда карасам, икенче ун минут. Бөтенләй кәефем китте. Без дә шулай озак итеп, төнгә кадәр уйнарбыз микәнни артист булгач? Тулай торакка җәяү кайттык ул төнне. Баксаң, таҗиклар куйган спектакль «Король Лир»ның кыскартылмаган, темпоритмы көйләнмәгән варианты булган икән.

Керәшен халкы кушаматсыз булмый – безнеке «Дунай». Бу фамилия Ак патша заманыннан килә, дип сөйләгән хәтерлим әтинең. Имеш, болай килеп чыккан: Тимри дигән крестьянның (безнекеләр әүвәле «Тимринекеләр» дип йөртелгәннәр) улы Константин патша армиясенә китә. Аның сабые Данила (минем бабай) «Атаң кайда?» – дип сораганнарга: «Дунайда», – дип җавап бирә икән. Менә шулай итеп кушамат булып берегеп калган инде.

Соңгы курсларга җиткәндә, Малый театрның сәхнәсендә андагы олпат артистлар белән бергә массовкага чыгу бәхете тәтеде. Мин «Макбет», «Стакан воды», «Когда горит сердце» спектакльләрендә катнаштым. Хезмәтебез өчен акча да түлиләр иде: репетиция өчен – 1 сум, спектакль өчен – 1 сум 50 тиен.

Ул зур мәктәп булды: һөнәргә өйрәнү мәктәбе дә, тормыш мәктәбе дә. Күп милләт вәкилләре белән аралашып, укмашып яшәдек. Шәриктәшләрем хәзерге көндә Россиянең һәм Европа театрларының әйдәп баручы актерлары һәм сәнгать эшлеклеләре.

– Ходай биргән язмышыма, тигән өлешемә мин рәхмәтле. Шактый күп уйнадым, дөнья репертуарын берәү дә йотып бетерә алмый – мин канәгать. Ләкин безнең профессия – башка һөнәрләрдән аермалы буларак, эштән туймый торган профессия. Башка һөнәр ияләре тизрәк ялга чыгу яки аз эшләп күбрәк хезмәт хакы алу турында хыяллана. Безнекеләргә эш булсын, эш хакы турында оныта да ул хәтта, анысы иҗат процессында икенче планда кала. Шуңа иҗат кешеләрен кешечә яши алырдай итеп тәэмин итәргә кирәк. Аның бит эше – иҗат, ул галәмәт олы хезмәт, димәк, бәясе дә булырга тиеш. Артист өстәмә акча эшләү юллары эзләп, шамакайга әйләнеп, театрының һәм һөнәренең дәрәҗәсен төшерергә тиеш түгел. Халык аны арзанлы корпоративларда бер күргәннән соң, ничек инде Камал сәхнәсендәге җитди рольдә кабул итсен дә, хөрмәт итсен, ди?!

ОҖМАХ КАПКАЛАРЫ АЧЫЛГАЧ...

Камалга кайткач, оҗмах капкалары ачылгандай булды. Безне бит көтеп алдылар, шунда ук, бер-бер артлы рольләр бирелде, рәхәтләнеп уйна гына. Артистның роле булса, ул инде бәхетле диган сүз. Роль катлаулы, тирән дә булса – икеләтә бәхетле!

Миңа төрле режиссерлар белән эшләү бәхете тәтеде. Марсель белән без театр мохитендә генә түгел, ә көндәлек шартларда, табигатьтә, дачада, балыкта да бергә була идек. Бик күп сөйләшергә, фикер алышырга туры килде. Ул репетициягә, актерлар янына спектакльнең әзер концепциясе белән килә торган режиссер булды. Ул сиңа образың нинди булырга тиеш икәнлеген әйтеп бирә. Ә көндәлек тормышта... утыра шулай Марсель аккан суга карап, ә үзе бөтен төеннәрне төйнәп, спектаклен тәгәлләгән була.

Фәрит белән эшләү икенче – ул актерга образын уйларга, табарга, эшләп бетерергә, эчке каршылыкка барырга, үзендә «казынырга», ягъни рольне тудыру процессында аң-хис белән бәйле бөтен ресурсларын эшкә җигәргә мөмкинлек бирә. Уенга, «театральность»ка зур игътибар юнәлтә. Төрле стильләрне кулланып карарга, абсурдка, пародия, фарска йөз борырга да мөмкин. Ләкин ул әнә шул театральлек, беренче карашка «җиңел» күренгән форма аша бик тә тирән, фаҗигале әйберләрне үтемле итеп җиткерә белә тамашачыга. Аны да, актерны да нәкъ менә шулай дөрес булуына ышандыра.

Балыкчы Дунай.

БАЛЫК ТЕЛЕН ДӘ БЕЛӘМЕ?!

Ринат Таҗетдинов, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты:

– Мин аның студентларны укытуы турында рәхәтләнеп әйтә алам. Профессор булуы да күп нәрсә турында сөйли. Чөнки укыту ул – аерым бер талант. Мин үзем укыта алмадым, вакытым да аз иде, дөресен генә әйткәндә, курыктым да. Дунай курыкмады.

Ул күп укый торган, белемле кеше, каләме бар, бик күп пьесалар тәрҗемә итте. Аның тәрҗемәсе шәп була, бу эш тә зур талант сорый.

Дунай белән балыкка чыксаң, хурлыкка каласың. Ул 10 кг балык тота, ә син бер-икене генә эләктерәсең. Ачу килә бит. Әллә минәйтәм, ул балыкларның телен беләме икән? Ничек шулай аңа гына эләгә соң? Әнә шундый уңган һәм булган ул безнең Дунай.

Раушания Юкачева, Татарстанның халык артисты:

– Без театрга килгәндә, щепкинчылар безнең өчен олы шәхесләр иде. Репертуарны тартып баручы, төп рольләрне башкара торган карап туймаслык артистлар. Наил абыйга залда утырганда да гашыйк буласың. Ул һәрвакыт синең хәлеңне сорашыр. Балык киптерә дә, безгә кучтәнәчкә китерә. Ул токкан балыкларны күп ашадык.

Рабит Батулла, Татарстанның халык язучысы:

– Дунай һәр эшендә, һәр шөгылендә дә үҗәт булып яшәде. Йә, нәрсә калган инде ата кешегә, бабай кешегә зәмһәрир суыкларда боз ватып, бәке тишеп, кармак салып, сәгатьләр буе чиерткәнен көтеп утыру? Җәйге эссе чөлләләрдә? Юкса Дунай үзе балык яратмый, дусларына өләшә эләккән балыкларын.

Ул җанатар да. Хоккей белән футбол ярышы буласы көнне Дунай үзенә урын таба алмыйча йөри. Сәхнәдә эше булмаса, һичшиксез, ул стадионга чабачак яки телевизор экранына ябышып утырачак.

PRESSA.RU

Мәдәни маршрут:

БАШКАЛАДАН ЕРАККАРАК КИТСӘК...

Татарстан буйлап сәяхәтебезне дәвам итәбез. Футбол мәйданындагы энергия белән рухланганнан соң, башкаладан ераккарак китсәк тә була. Анда да безне гаҗәеп урыннар көтә. Ул урыннарны сез озакка хәтерегездә калдырачаксыз, ышанып әйтә алабыз.

«СИНЕ ДӘ ДӘВАЛАРБЫЗ»

Урта гасыр Лондоны да, Парижы да шау-шулы көнчыгыш сулышы бөркелеп торган Болгар белән тиңләшә алмый, билгеле. Монда тормыш кайнаган, сәүдә чәчәк аткан, сәнгать белән мәдәният үсеш кичергән. XIII гасырда Болгар басып алучылар тарафыннан җимерелгән-җимерелүен, әмма гасырлар узгач, бу бөек шәһәр янә аякка басты. Бүгенге көндә ул – ил картасындагы туристик нокталарның иң эресе һәм Татарстан Республикасының бренды. Аның капкаларын ЮНЕСКО тамгалары бизәп тора. Болгар музей-тыюлыгының кызыклы борынгы объектлары арасында яңалары да бар – мәсәлән, «Табиб йорты». «Уйлап табарга һәм булдырырга мөмкин булган музейларның иң кызыклысы», – дип соклана килгән туристлар. Чынлап та, борынгы заманнарда ничек дәвалауларын тагын каян белер идек әле? Европа үләттән җәфа чиккәндә, бездә, әле ул заманда ук, катарактага операция ясый белгәннәр. Әбү ибн Зәкәрий ар-Рази, Әбүгалисина, Таҗетдин әл-Болгари – бу галимнәрнең исемнәре дөнья медицинасы һәм фармакологиясе тарихына язылган. Урта гасыр табиблары кулланган җиһазлар һәм кораллар, табиблык буенча китап-әсбаплар нәкъ шул чордан калган рәвештә сакланган. Бу чыннан да «Табиб йорты» – атрибутикасы буенча да, рухы белән дә.

Адрес: Спас районы, Болгар шәһәре

Ничек барып җитәргә:
Җәмәгать транспортында: «Южный» автовокзалыннан кузгалып китүче автобуста яки Казан Елга портыннан китүче тиз йөрешле «Метеор» теплоходында барырга мөмкин.
Машинада: Оренбург трактыннан Алексеевск бистәсенә илтүче чатка кадәр барырга, аннары, уңга борылып, Левашевога юл тотарга, яңадан уңга борылып, Антоновкага илтүче чатка барырга, янә уңга борылырга һәм Болгарга керергә.

≈ **Казаннан – 200 км**

ТРОЦКИЙ КАБИНЕТЫНДА



≈ **Казаннан – 60 км**

Свияжск утрау-шәһәре, аркылыга-буйга исәпләсәң, километрдан бераз гына артыграк буладыр. Җирле халкы исә өч йөзгә дә тулмас. Әмма мондагы тарихи һәйкәлләрне саный башласаң, аларның исәбенә чыгып булмый. Кайберләре XV йөзгә үк карый. Утрауның иң түр почмагына кадәр җитүчеләр белә: Щука елгасы буенда «Колонналы йорт» урнашкан, аны утрауда борын-борыннан яшәүчеләрнең оныклары шулай дип атый. Гражданнар сугышына багышлаулы йорт ул, кабатланмас кыйммәте бар. Беренчедән, монда заманында хәрби штаб булган, диләр. Икенчедән, анда аерым тематикага караган башка музейлардагы шикелле совет чорыннан калган әйберләрдән тупланган экспозиция юк. Абыйсы – энесен, энесе абыйсын үтерергә мәҗбүр булган канлы чорларның тарихы киңкырлы итеп күрсәтелә биредә – баррикаданың ике ягыннан торып та. Аерым игътибарга Лев Троцкий лаек дип табылган. Монда аның хәтта шәхси кабинетына кадәр бар. Музейны тәүге күрүчеләрнең берсе – Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев: «Биредәге чор документларының байлыгы хәйран калдыра. Мин соклануымны яшерә алмыйм!» – ди. Ә ул, сезгә сер итеп кенә әйтәбез, тарихны яхшы белүе белән дан тота.

Адрес: Яшел Үзән районы, Свияжск утрау-шәһәре

Ничек барып җитәргә:
Җәмәгать транспортында: Казан Елга портыннан Свияжскига көн дә рейслы теплоходлар кузгалып китә.
Машинада: М7 трассасына чыгарга, Исаково авылы алдыннан, юл чишелешендә, уңга борылырга, Свияжск борылышына кадәр баргач, кабат уңга борылырга һәм утрау-шәһәрнең үзенә кадәр туп-туры барырга кирәк.



≈ Казаннан – 90 км

Әкияттә кунакта

Беругә дә сер түгел, Габдулла Тукай – татар поэзиясенең кояшы ул. 27 яше тулганда дөньядан киткән бу даһи никадәр бай мирас калдырган! Утыздан артык китап чыгарган, татар теленә рус классикасы үрнәкләрен тәрҗемә иткән. Нәкъ менә аның тәрҗемәләрендә татарларның китап киштәсендә Пушкин, Лермонтов, Толстой пәйда була. Татарстанда Тукайга берничә музей багышланган, әмма Яңа Кырлайдагысы аерым игътибарга лаек. Чөнки нәкъ менә шушы йортта – Сәгъди Салихов исемле крестьян гаиләсендә тәрбияләнгән дә булачак шагыйрь. Музей зур агач йорт эчендә урнашкан, ул XIX гасырны менә дигән итеп чагылдыра – барлык җиһазлары, атрибутлары белән. Монда сез Тукайның шәхси әйберләрен күрә аласыз: намазлыгын, Пушкин шигырьләре тупланган яраткан сайланма китабын. Музейның икенче катында исә – чып-чын тылсым дөньясы. Биредә Тукай әкиятенең атаклы каһарманы – бермөгезле бөкре Шүрәле яши. Аның белән бергә Убырлы Карчык, Су анасы, Аждаһа да тупланганнар. Ә сез аларның кемнәр икәнлеген беләсезме? Юк икән, интерактивта катнашыгыз һәм белерсез! Ә аннары күркәм буасы һәм бик матур сыннары булган гаҗәеп матур паркта йөреп килегез. Анда кайчандыр бәләкәй Габдулла утырткан нарат үсеп утыра, дип сөйлиләр.

Адрес: Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 4 йорт

Ничек барып җитәргә:
Җәмәгать транспортында: автобуста, йә булмаса электричкада Арчага кадәр барырга, аннары автобуста Яңа Кырлайга юл тотарга кирәк.
Машинада: Себер тракты буенча Арчага кадәр барырга, аннары Яңа Кырлай борылышына кадәр төньякка юл тотарга кирәк.

Крестьяннан – мәгърифәтчегә кадәр

Бу музейның язмышы искиткеч. Ул ачылган йорт бөтенләй башка урында – Кече Шырдан авылында төзелгән булган. Кече Шырдан – күренекле татар этнографы, галиме һәм мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның кече ватаны. Аны барлык эчке кыяфәте һәм җиһазлары белән бергә җирле кеше саклап калган. Һәм тарихи кыйммәте буенча тиңе булмаган әлеге ызбаны музейга бүләк иткән. Үзе китереп үк биргән хәтта! Шул вакыттан башлап бу инде гади авыл ызбасы гына түгел, ә Каюм Насыйри исемен йөртүче архитектура-этнография комплексы объекты. XIX гасыр татар крестьянының тулы бер йорты! Ул хәзер утарны хәтерләтә: тирәсендә абзар-курасы, сарайлары, мунчасы һәм хәтта ат җигү кирәк-яраклары саклар өчен лапасы да бар. Залның эчке ягында – шәһәр тибындагы бүлмә, юыну бүлмәсе һәм хатын-кызлар яши торган як. Ул чактагы яңа өйләнешкән парларның ничек яшәгәнен беләсегез киләме? Килә икән, «кияү келәте»нә кереп чыгарга да онытмагыз. Экспозициядә барлыгы 500 предмет! Аларның бер өлеше – Каюм Насыйриның шәхси, үз әйберләре. Кызыклы экспонатлардан түбәндәгеләрне атарга мөмкин: Насыйри үз куллары белән ясаган шкаф, шәхси мөһере куелган, үзе төзегән тулы рус-татар сүзлеге, үзенчәлекле гарәп орнаменты белән бизәлгән атаклы Кузнецов заводы касәләре, күрәсең алар заказга ясалган булгандыр. Тагын бик күп әйберләр.

Адрес: Яшел Үзән районы, Олы Ачасыр авылы, Тукай урамы, 44 йорт

Ничек барып җитәргә:
Җәмәгать транспортында: Казаннан поезд белән «21нче километр» станциясенә (Кирига кадәр) барырга кирәк.
Машинада: М7 трассасы буйлап Олы Ходяш юл чишелешенә кадәр барырга, аннан Кирига таба сулга борылырга, ә Олы Ачасырга – уңга.

≈ Казаннан – 70 км

Фото: idel-rus.ru

Сез күрергә тиеш тагын өч урын:

- Тәтеш районындагы Молоствовлар йорты. Бу гаҗәеп яхшы сакланган дворян утары каен аллеяләре һәм экзотик агачлар белән куаклардан гыйбарәт паркы белән дан тота.
- Яшел Үзән районының Октябрьск бистәсендәге Энгельградт исемендәге КФУ Астрономия обсерваториясе. Аңа 1901 елда нигез салынган Арсеналында – борыңгы телескоплар да, шулай ук өр-яңа җиһазлар да. Аеруча зур игътибарны сфера рәвешендәге кинотеатры булган планетарий җәлеп итә.
- Биектау районындагы «Иске Казан» музей-тыюлыгы. Монда гаҗәеп бай этнографик коллекция тупланган. Казан татарларының тормыш-көнкүреш шартларын чагылдыручы предметлар урын алган – һөнәри әйберләр, кием-салым, бизәнү әшләнмәләре һ.б.

PRESSA.RU

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН

АЛАБУГА: ИҢ БАШТА… ШАЙТАН БУЛГАН?!

Фото: Ната Смирнова

Казан

Казаннан
208 км ераклыкта

Алабугада булганыгыз бармы? Юкмыни?! Берничек тә гафу итеп булмый торган югалту бу. Төрле заманнарда төрле даһи шәхесләрне үзенә сыендырган, туган тарихын да, анда яшәп-булып китүчеләр турындагы хәтерне дә кер кундырмыйча саклый алган бу җыйнак, күркәм провинциаль шәһәрчеккә кичекмәстән барырга кирәк сезгә.

Алабуга сезне сәүдәгәр йортларының һичкем кулы орынмаган фасадлары, аларда яшеренеп сакланучы раритетлар белән каршы алыр: патефоннар, шәһәр башлыкларының костюмнары, үлчәү өчен герләр, фисгармонияләр, Алабуга «муха»лары*. Боларга өстәп, борын-борыннан килгән риваятьләрне дә исәпкә алсак. Монда һаман да Цветаева шигъриятенең «көмешсу» рухы һәм Шишкин киндерләренә ягылган майлы буяуларның куе-тыгыз тылсымы яши. Кавалерист-кыз Надежда Дурова биләмәләрендә һаман да Наполеонны җиңү тантанасы яңгырап тора. Академик Бехтеревның Земский хастаханәсендә кулланылган дәвалау үләннәренең тымызык сулышы әле дә сизелә төсле…

Ә риваятьләренең үзенчәлегенә килсәк… мондыйларны сезнең башка беркайда да ишеткәнегез юк, чын әйтәбез. Шайтан каласында яшәгән күрәзәче Шайтан үзе генә дә ни тора – Алабуга нәкъ менә аңардан башлана дисәк тә, ялгыш булмас. Бу корылма әле шәһәргә нигез салынган чорлардан ук калкып тора. Әйтергә кирәк, Чулман белән Тойма елгалары кушылган урындагы тауның башында – Алабуганың иң матур ноктасында урнашкан ул. Иң башта бирегә, әлбәттә инде, әлеге дә баягы Шайтан килеп урнашкан, аннары гына – Дурова, Шишкин, Бехтерев, Цветаевалар… Һәм – үз шәһәрләре тарихына зур ихтирам вә саклык белән караучы тагын бик күп алабугалылар.

Бүгенге Алабуга – үткәндәге барлык риваять-тарихларын саклаган хәлдә, заманча йөзле, гаять чиста һәм уңайлы шәһәр. Урамнары буйлап көннәр буе йөрергә мөмкин – шәһәрне дә профильгә һәм анфаска төшерә-төшерә, аның фонында – үзеңне дә, әлбәттә… Музейларга, трактирларга кереп чыгарга була, креатив фикер йөртүче музей хезмәткәрләре кунаклар өчен махсус уйлап тапкан интерактив уеннарда катнашырга.

Йә, ничек, сез инде Алабугага юлга чыктыгызмы? Сәлам әйтергә онытмагыз безнең яраткан калабызга! «Татарстан» якын арадагы елларның берсендә анда тагын юл тотачак әле. Без бит әлеккеге баруыбызда атаклы Портомойняны** күрергә өлгермичә калдык. Һәм, менә хәчтерүшләр, «муха»сыз да кайтып киткәнбез булып чыкты…

«Муха»* – 15 мл сыйдырышлы чәркә. Революциягә кадәрге Россиядә беренче чәркәне бушлай бирә торган булганнар. Бу кабакларны трактир белән алыштырырга омтылган Петр I нең боерыгы буенча эшләнгән. Ни өчен алыштырганнар соң? Чөнки трактирларда халык эчеп кенә калмыйча, ашый да алган. Кунакларның беренче чәркәне эчкәч тә кайтып китү гадәтен белеп алгач, трактир хуҗалары чәркәләрне бик бәләкәй итеп

ясый башлаганнар. Мондый чәркәгә нибары бер аш кашыгы эчемлек кенә сыйган. Бик бәләкәй булганга, исемен дә «муха», яки «чебен» дип кушканнар. Әмма «салып» алырга яратучылар монда да үзләрен алдатмаган – бер-бер артлы берничә трактирга керә торган булганнар. Берничә «муха»дан соң әфәнделәрнең кәефләре күзгә күренеп күтәрелгән, билгеле. Ә халыкта «под мухой» дигән гыйбарә барлыкка килгән – бу бездәге «кәефләнеп алган» төшенчәсенә тиңдәш инде.

** Портомойня – кер юу йорты, Россиядәге бердәнбер кер юу тарихына багышланган музей. XIX гасырның беренче яртысында төзелгән.

PRESSA.RU

Академик Бехтерев һәйкәле.

Бехтерев житәкчелек иткән Земский хастаханәсе шундый булган.

PRESSA.RU



АЛАБУГА: КҮР, СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИНДИ МАТУР!

Фисгармония – клавишалы музыка уен коралы. XIX гасыр. Шишкиннар йортының Кече кунак бүлмәсендә тора.

Портомойня – кер юу йорты, Россиядә кер юу тарихына багышланган бердәнбер музей. XIX гасырның беренче яртысында төзелгән.

PRESSA.RU

Фото: Слава Степанов (Gelio)

ФОТОТАТАРСТАН

«Парижны күрергә һәм үләргә» дигән атаклы гыйбарәне хәтерлисездер. Юк, юк, Татарстанга килгәч, һич тә үләргә ярамый, ә менә мондагы матурлыкка сокланудан адым саен диярлек телсез тору – анысына рөхсәт. Казан ул – Париждан бер җире белән дә калышмый торган тормыш тантанасы. Күпкырлы, киңколачлы тантана турында бара сүз – һәм аны һәрберебез үзенчә ача…

Яр Чаллы.

ТАТАРСТАН **ТҮБӘЛӘРЕ**

Слава Степанов (блогер Gelio):

– Биеклекне һәрчак үз иттем: эш экстримда түгел, ә җан халәтендәдер, мөгаен. Шәһәрне бар колачында биеклеккә күтәрелеп кенә тоярга мөмкин, җирдә чакта һәммәбез дә – аның нибары кечкенә бер өлеше генә. Әле мәктәптә укыганда ук хыялымда кош биеклегенә күтәрелеп, әкияти шәһәрләр торгыза идем. Шуңа, мөмкинлек чыгуга, туган шәһәрем Новосибирскиның иң биек – 21 катлы йорты түбәсенә менүем гайре табигый хәл түгел. Озак вакытлар дәвамында югарыдан шәһәр күренешләрен күзәтеп, аларга сокланып кына утырдым, ә аннан кулыма «мыльница» килеп керде. Күп тапкырлар сокланган күренешләрне фотога төшереп, Интернетка урнаштырдым. Халыкка нык тәэсир итте ул фотолар. Бик күп яздылар. Шуннан соң 10 ел вакыт узды инде, ул арада хобби дигәнем чын мәгънәсендә һөнәргә әверелде. Новосибирск чоры тәмамланды: аның йөзләгән түбәсен йөреп-төшереп чыкканнан соң, дусларым белән башка шәһәрләргә юл тоттык.

Беләсезме, югарыдан төшерелгән сурәтләр теләсә нинди шәһәргә дә туры килми, әмма Казан – үзе бер тарих. Биредәге архитектура өлкәсендәге амбицияләр гаҗәеп фотолар ясарга мөмкинлек бирә! Төшерергә керешкәнче, мин дистанцион рәвештә карталарны өйрәндем, ракурслар сайладым. Аннары шактый ялыктыргыч эш башланды – боларның барысын да үзара яраштыру. Һич кенә дә зарлана алмыйм: Казанның кайсы гына бинасын алма, һәммәсенә менеп төшерә алдым, хосусый милек ияләренең берсе дә каршылык тудырмады.

Казанны беренче тапкыр Универсиада алдыннан төшердем. Бер күрүдә гашыйк булдым һәм монда тагын берничә кат әйләнеп кайттым. Шулай берсендә ТР Хөкүмәте өчен проект эшләдек. Бу чын мәгънәсендә карт-бланш иде! Вертолеттан тәүлекнең теләсә кайсы вакытында һәм һава шартлары нинди булуга карамастан төшерү мөмкинлеген тәэмин иттеләр миңа. Ул чакта Казан күз алдыма пәрәннек кебек шәһәр булып килеп басты: җыйнак, төзек, менә дигән җәяүле маршрутлары бар, үзеннән тарих бөркелеп тора. Әмма мин әле ул чакта аның күз ачып йомган арада үзгәреш кичереп торуын абайлап өлгермәдем, соңрак кына тойдым моны. Шуңа да бу шәһәр белән «эшләү» тагын да кызыклырак, мавыктыргычрак булып әверелде. КФУның Физика институты бинасына менгән мизгелне һич онытасым юк. Җылы гыйнвар киче, колакны яра торган тынлык һәм... күз явын алырдай шәфәкъ. Шәһәр минем алдымда бар матурлыгында җәйрәп ята – сокланудан тыным кысылды хәтта. Камераны бер читкә алып куйдым да, берара күз дә алмый сокланып карап кына тордым.

ТАТАРСТАН СПОРТЫ

Михаил Бормин:

– Спорт, бигрәк тә ул профессиональ дәрәҗәдә булса, «без иң яхшысы» дигән хокукка ия булыр өчен бөтен көчне түгәргә кирәклегенә инандыра. Ул фальшны өнәми һәм кире кага. Тагын кайсы һөнәрдә кешеләр уңышка шулкадәрле көч һәм күз яшьләре аша ирешә микән? Минем иң зур теләгем – үзем төшерә торган каһарманнарга лаеклы булырдай сурәтләр тудыру. Аларны күргәч, кешеләрнең спортны үз күзләре белән күрергә теләге туып кына калмыйча, спорт дөньясына кереп китәргә дә омтылышлары уянса, менә бу җиңү булачак. Шуны максат итеп, өч ел элек Казанга килдем мин. Һич шаярмыйм, Казан – минем өчен Россиянең иң шәп спорт шәһәре ул! Спортчы булмасам да, фотограф буларак, үз өлкәмдә иң шәп белгеч буларак танылып, үз Олимпыма үрмәләү мөмкинлеге бар. Бу эштә ярдәм иткәннәре өчен юлымда очраган һәркемгә рәхмәтлемен: спортчыларга – түккән көчләре һәм тирләре; коллегаларга – тәҗрибә уртаклашулары; басмаларга – фотоларымны урнаштырырга мәйдан биргәннәре өчен. Фото тамашачыдан башка яши алмый бит ул!





PRESSA.RU

ТАТАРСТАН БАЛАЛАРЫ

Иван Заманухин:

– Олы улым Ярослав тугач, мин аны кулга алган беренче кеше булдым. Ул чакта безнең өчен бар да яңа иде – әти-әни булырга өйрәнеп кенә килгән чаклар. Ә менә Мирослава тугач, инде ул кадәр курыкмадым, ул халәтнең чиксез ярату һәм наз белән тулы рәхәтлеген үземә туйганчы сеңдердем. Бәләкәчебез туганнан соң, беренче көннәрнең тиңсез мизгелләрен истә калдырырга, «тарих» өчен төшереп калырга ашыктым. Аның дөньяга беренче тапкыр гаҗәпләнеп караулары, нәп-нәни бармаклары, тәпиләре, борыны... Нәкъ менә шул чакта мин фотографиянең бу төре белән Казанда чынлап торып берәүнең дә шөгыльләнмәвен абайлап алдым һәм гаҗәпкә калдым. Бу эшкә җитди рәвештә тотындым. Катлаулы хезмәт булып чыкты. Яңа туган сабыйларны фотога төшерер өчен махсус әзерлек кирәк икән. Нәни җан иясен ничек итеп теге яки бу рәвештә яткырырга, елый башласа, ничек тынычландырырга? Бу өлкәдә белем тупларга керештем. Сабыйларны фотога төшерү белән шөгыльләнүче Канада, Россия, Украина фотографларының мастер-классларын үзләштердем – бу бәһасе юк тәҗрибә булды...

Бүген сабыйларны фотога төшерү минем карьерамның бер өлеше генә түгел, йөрәгемне яулап алган шөгыль дә. Бәләкәч модельләрнең хис-тойгылары, үзүзен тотышлары шулкадәр риясыз һәм самими ки, алар янында үзең дә уңай энергетикага көйләнәсең, күңелеңә яктылык һәм дәрт тула.

ТАТАРСТАН «СТАРОСТАЛАРЫ»

Саша Гром:

– Казан миңа һәр тыкрыгы, борылышы саен матурлык һәм үзенә бер атмосфера бөркеп торган, әле ачылып өлгермәгән планетаны хәтерләтә. Иске ишегалларында хөкем сөргән җимереклек, ташландык рух ошый миңа. Менә, күпне күргән бер болдыр, ул ишелеп төшәм, дип тора. Йә булмаса, кемдер урамга чыгарып куйган, һәм онытып калдырган урындык – утыра тик моңаеп. Аңа шулай килешә дә – әйтерсең, гомер бакый биредә торган ул. Шушы сәерлекләр белән тулы мохиттә, ничек кенә пародоксаль булмасын, чын тормыш сулышы сизелә – пафоссыз, ялгансыз, ул ничек бар, шулай.

Менә инде елдан артык мин даими рәвештә «фотоау»га чыгам. Игътибарлылыкны сынау буенча бер уен, дисәк тә була моны. Заманча матур мегаполисыбызның иске ишегалларында яшеренеп яткан кызыклы тарихларны һәр чыккан саен күбрәк «алып кайтасы» килә. Ул тарихлар белән бүлешергә дә яратам. Хештыгым: #шлашлаиувидела.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАННЫҢ КӨНДӘЛЕК ТОРМЫШЫ

Солтан Исхаков:

– Тормышны бар чагылышында төшерергә яратам – портретмы ул, пейзажмы, натюрмортмы… Ә жанрлы фотография төре миңа һәрвакыт иң кызыклысы булды. Яхшы кадр төшерә алсаң, күңелгә рәхәт була – менә бит, мин аны «эләктереп» алдым! Тарихта бит заманыбызның, тормышның тере сурәтләре калачак, аның ритмын, сулышын, кәефен кешеләргә җиткерә алырдай кадрлар. Бүген алар безгә гадәти, көндәлек тормыш чагылышы гына булып күренсә дә, кыйммәтләре зур.

Көндәлек тормышны сурәткә төшергәндә, теләсә нинди вакыйгага реакция белдерергә әзер булырга тиешсең. Сине тәэсирләндерә алырдай нәрсәне дә булса «күрергә», «тотып алырга». Гади күренеш: кешеләр узып бара. Ис китәрдәй берни юк. Кинәт син бу хәрәкәттә үзенә күрә бер кабатланмас ритм барлыгын тоеп аласың, бу очракта кадр сюжеты буенча әллә ни үзенчәлекле булмаса да, төзелеше, рәвеше буенча әйбәт килеп чыгачак – димәк, төшерергә кирәк.

Иң яраткан портретларымның берсен ничек төшергәнне яхшы хәтерлим – канәфер тоткан ветеран сурәте иде ул. Кемдер бу ир-атка чәчәк бүләк итеп китте, шул мизгелдә аның йөзенә бөтен хис-тәэсирләре бәреп чыкты, күзләреннән яшь тамып төште. Мин очраклы рәвештә янәшәсендә туры килдем һәм бу халәтне камерага «эләктереп» өлгердем. Бары бер мизгел! Аннан – чираттагы кадр. Әмма теге халәт инде башка кабатланмаячак…

ТАТАРСТАН ТУЙЛАРЫ

Ната Смирнова:

– Ун ел элек мин эшләгән газета редакциясендәге коллегабыз кияүгә чыкты. Фотографка яшьләрнең бюджетында акча җитеп бетми иде, шул чакта мин аларның туен төшерергә ризалаштым. Бик тә символик бәягә – миңа «Друзья» сериалының бөтен сезоннары да кергән дисклар коллекциясен вәгъдә иттеләр. Беренче зур тәҗрибәм булды ул.

Миңа төшерү процессы гаҗәеп дәрәҗәдә ошый. Туй көнендә, гадәттә, барысы да шат күңелле була. Чып-чын бәхет һәм һәр мизгелне балаларча бер ихласлык белән кичерү – менә шул аеруча кыйммәт туйларда. «Икәү өчен» генә каралган туйлар – үзе бер могҗиза. Биредә бернинди ыгы-зыгы юк, ярдәм итәргә, киңәш бирергә әзер торган туган-тумача да бозмый кадрны, «кызып өлгергән» дуслар да комачауламый. Монда бер-берсен яраткан ике кеше кадерле урыннарын иңләп йөри, кадрлар да гадәти, «тапталган» булудан туктый. Яшь парларның тышка бәреп чыккан эмоцияләре һәм детальләр – менә нәрсә иң әһәмиятлесе. Шундый мизгелләр була: яшьләр, үзләренә төбәлгән объектив барлыгын онытып, бер-берсе белән мавыгып китәләр һәм шулкадәр ихлас, табигый сурәтләр килеп чыга. Мин шундый кадрларга балаларча сөенәм. Ә бит еллар узгач, гаилә тормышының барлык халәтләрен кичергәннән соң, аларның әнә шушы – бер-берсенә кадерле булган, бәхетле чакларына кайтасы киләчәк. Киләчәк, һичшиксез.

PRESSA.RU

ЕЛ ТАБИБЫ – АК ЧӘЧӘКЛӘР

ПРОФЕССИЯДӘ РИЯСЫЗЛЫК СИМВОЛЫ

Татарстанда сәламәтлек саклау эре адымнар белән алга бара. Югары технологияле яңа медицина үзәкләре ачыла, гамәлдә булганнары яңартыла һәм камилләштерелә. Беренчел медицина звеносын модернизацияләү һәм ныгыту программасы нигезендә республикада быел гына да Казандагы, Яр Чаллыдагы, Түбән Камадагы һәм Әлмәттәге 43 дәваханәгә ремонт ясалачак, медицина учреждениеләренә яңа җиһазлар кайтарылачак.

Шулай да шәфкатьлелек тармагында иң мөһиме – табиблар үзләре, аларның югары профессиональлеге, хәтта иң катлаулы очракларда да ярдәмгә килә белүләре. Бу мәсьәләдә «Ел табибы – Ак чәчәкләр» республика конкурсы – ак халатлы кешеләрнең абруен күтәрергә тиешле игелекле традицияләрнең берсе булып тора. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан оештырылган конкурс профессиональ яктан аеруча әзерлекле, тирән белемгә һәм югары квалификациягә ия белгечләрне ачыкларга ярдәм итә. Ул елдан-ел популярлаша бара. Әгәр беренче конкурста 92 табиб катнашкан булса, быел биш номинациядә 146 номинант җиңү өчен көрәшә. Номинацияләр:

- **Сәламәтлек саклау легендасы**
- **Ел табибы**
- **Беренче звеноның иң яхшы табибы**
- **Ел медицина хезмәткәре**
- **Уникаль очрак (табиблар коллективы)**

16 ИЮНЬ

Җиңүчеләрне, республиканың иң яхшы медицина хезмәткәрләрен котлау тантанасы 16 июньдә Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрында була. Традиция буенча иң яхшы табибларны, республика халкының фикерләрен искә алып (министрлык сайтында интернет-тавыш бирү үткәрелә), ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет билгели. Бүгенге көндә «Ак чәчәкләр» премиясе тапшырылу – барлык медицина хезмәткәрләре өчен чын бәйрәм булып тора.

Ел саен үткәрелә торган «Ел табибы – Ак чәчәкләр» конкурсы 2008 елдан бирле уза. Ул татар язучысы Габдрахман Әпсәләмовның ак халатлы кешеләргә багышлап язылган шул исемдәге романы хөрмәтенә шулай аталган. Әсәрдәге геройларның берсе – профессор Әбүзәр Таһировны үзенең революциягә кадәрге табиблык практикасы чорындагы бер очрак гомерлеккә тетрәндергән: анда кечкенә баланы дәвалап терелткән доктор рәхмәт йөзеннән аның әнисеннән... ак чәчәкләр китерүен сораган. Шуннан бирле гап-гади ак чәчәкләр профессор өчен медицина профессиясендә чисталык һәм риясызлык символына әверелгән.

ИРКӘЛӘРГӘ ҺӘМ СӨЯРГӘ...

Үпкәңне тикшерер, тамагыңны карар, температураңны үлчәр, тиешле дару язар өчен яңгырда да, чатнама суыкта да өегезгә килеп йөргән балалар табибын хәтерлисеңме? Безнең балачактан соңгы еллар эчендә участок педиатрлары хезмәтендә әллә ни үзгәреш булмады – эшләре генә артты. Казанның 7 нче шәһәр балалар дәваханәсе баш табибы Таиса Чернова «Татарстан»га бу хезмәтне саклау ни өчен мөһим һәм балалар сәламәтлеге тулаем алганда нәрсәгә бәйле икәнлеге турында сөйләде.

Таиса Чернова,
7 нче шәһәр балалар дәваханәсе баш табибы

– Институттан соң беренче тугыз елымда мин балаларның участок табибы булып эшләдем, һәм бу иң эчтәлекле, иң кызыклы еллар иде. Баштарак бер гаиләгә унар гына минут китә иде, берничә айдан соң яртышар сәгать кирәк була башлады. Гаилә әгъзалары белән яңалыклар турында сөйләшеп утырмыйча китеп булмады, – дип искә ала Таиса Мирзахановна. – Һәм бу кирәк тә, әһәмиятле дә иде. Мин һәр баланың сәламәтлеге турында хәбәрдар булдым. Кайсы гаиләдә билгеләнгән дәвалануны төгәл үтиләр, ә кайсында үземә игътибарлырак булырга кирәклеген яхшы белә идем. Минем участоктагы хәлләр һәрвакыт күзәтү астында булды.

Бу эш схемасын Таиса Чернова 7 нче балалар дәваханәсенә беркетелгән участокларда да сакларга тырыша.

– Участок табибы карамагындагы балалар санының 800–900дән артмавы мөһим, чөнки эш күләме болай да зур, табибның шуннан артыгына көче җитмәячәк. Ә бит дөрес диагноз кую һәм тиешенчә дәвалану участок педиатры һәм амбулаториядә кабул итүче педиатрдан тора. Бездә һәр белгеч үз эшен сыйфатлы, нәни пациентлар һәм аларның ата-аналары өчен уңайлы булган шартларда башкара алсын өчен бөтен мөмкинлекләр тудырыла. Быел дәваханә шәһәрләр һәм муниципаль районнар дәваханәләренә капиталь ремонт ясау һәм заманча медицина җиһазлары белән тәэмин итүне күздә тоткан «2017–2018 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклауның беренчел звеносын модернизацияләү һәм ныгыту программасы»на керде. Бу мөмкинчелек өчен республика җитәкчелегенә без бик рәхмәтле. Үз чиратыбызда зур стажлы тәҗрибәле кадрларны саклап калу һәм диагностиканың заманча ысуллары белән таныш булган яшь белгечләрне җәлеп итү өчен бөтен көчебезне куябыз. Һәм яхшы нәтиҗәләргә ирештек – 32 участокта 27 табиб эшли, ягъни безгә 5 белгеч кенә җитешми. Бернична белгечне үз хисабыбызга укыттык, алар өчен кабинетлар җиһазладык. Болар берсе дә ансат кына булмады, әмма безгә ышанып тапшырылган территориядә балаларга медицина хезмәте күрсәтү тиешле дәрәҗәдә булсын өчен бу бик кирәкле, – ди Таиса Мирзахановна.

Шул ук вакытта ул дәүләтнең һәм ата-аналарның педиатрларга булган таләпләре бик югары икәнлеген дә билгеләп үтте.

– Эшебезнең төп юнәлешләренең берсе – балалар авыруларын алдан кисәтү. Бала сәламәтлеге бернична бик гади нәрсәгә – дөрес туклану, йокы, саф һавада булу, ата-ана игътибарына бәйле. Әмма хәзерге заманда әлеге гади генә тоелган эшләрне башкару яшь ата-ананың хәленнән килми. Бәләкәчләрнең күбрәк паркларда түгел, ә сәүдә үзәкләрендә йөрүенә игътибар иткәнегез бармы? Аларга айлар буе бозылмый саклана торган катнашмалар ашатуларын да беләсездер. Башкача игътибар итәсе урында, бер яшьлек, кайчакта хәтта яше дә тулмаган сабыйларының кулына гаджет тоттыралар. Ә бит болар белән без кешелек тарихында беренче тапкыр очрашабыз. Моның киләчәктә нәтиҗәсе ничек булачагын белеп бетермибез әле. Баланың психик һәм физик сәламәтлегендә бу ничек чагылачак? Күп кенә ата-ана сабыйларын күбрәк иркәләргә һәм сөяргә кирәклеген онытып җибәрә шул.

Яшь әниләрнең һәм әтиләрнең педиатрлар фикере белән исәпләшмичә, мәгълүматны күбрәк интернет аша алырга һәм шуның нигезендә эш итәргә омтылуы да хәлне катлауландыра.

– Үзебездә ясалган вакцина – сыйфатсыз, һәм ул көтелмәгән нәтиҗәләргә китерергә мөмкин дигән фикергә таянып, балаларына прививка ясатудан баш тартучы ата-аналарның саны арта бара. Ә бит бума ютәл, дифтерия, столбняк кебек куркыныч авыруларны вакцинация ярдәмендә генә бетерергә мөмкин булды, – ди Таиса Чернова. – Яисә, мәсәлән, ата-аналар туберкулезга каршы проба алуга да ризасызлык белдерәләр. Янәсе, без – имин гаилә, бездә туберкулез булуы мөмкин түгел. Ә бит туберкулез – башкалары кебек үк йогышлы авыру. Баланы саклап калу өчен кирәкле барлык чараларны кабул итмичә торып, аның сәламәтлеге өчен җаваплылыкны ничек үз өстеңә алырга мөмкин?

Аңлату эшләренә дәваханә белгечләре аеруча зур басым ясый. Дәваханә каршында Сәламәтлек үзәге эшли, анда бала белгечләр тарафыннан беренчел медицина тикшеренүе уза ала. Узган елдан башлап, үзәк бригадалары шәһәр мәктәпләренә дә чыга.

– Дәваханә хезмәт күрсәтә торган Яңа Савин районы үсә һәм киңәя. Ел саен безгә яңа балалар килә. Һәм дәваханә өчен мәйданнар җитми. 1979 елда безне вакытлыча көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты территориясенә урнаштырганнар иде. Хәзергәчә бирдә эшлибез, өстәвенә, балалар саны баштагы 12 меңнән 20 меңгә кадәр җитте, – дип сөйли Таиса Мирзахановна. – Шуңа күрә яңа, яхшы балалар дәваханәсе (аның өчен җир күптән бүлеп бирелгән иде инде) – безнең зур хыялыбыз. Шәһәрнең аны төзү өчен мөмкинлеге чыгуын бик күптән көтәбез. Ә хәзергә табиб таләпләренә – норматив буенча да, кешелеклелек ягыннан да – һәрвакыт туры килү өчен камилләшүебезне дәвам итәбез.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

Реклама

PRESSA.RU

КИЕК КАЗ ЮЛЫ БУЙЛАП, ЯКИ «БУ ТАРИХТА МИНЕМ УРЫНЫМ КАЙДА?»



Акка кара белән язылган, кәгазьгә төшерелгән текст алар телендә гадәттә «сценарий» дип атала. Һәм бу чималны гадәттә нинди дә булса язучы, сценарист тәкъдим итә. Монысы – Голливуд, ягъни эре бюджетлы киноиндустрия варианты. Әмма гадәти күренешләрдән чыгармалар да була. Һәм бу чыгармалар нигездә «автор киносы» вәкилләре белән бәйле. Мин бу юлы «режиссер» белән «язучы» дип атала торган ике функцияне үзендә берләштереп, алар арасында күпмедер дәрәҗәдә тигезлек билгесе дә куя алган шәхескә тукталырга телим. Ул – XX йөз кино сәнгатенең торышына сизелерлек дәрәҗәдә өлешен керткән, аның юнәлешен, шулай ук безнең дөнья картинабызны да үзгәрткән режиссер һәм... язучы Эмир Кустурица.

Китаплары: «Сто бед», «Где моё место в этой истории?»
Фильмнары: «Андерграунд», «Жизнь как чудо», «Завет», «По млечному пути» һ.б.



Автор:
Луиза Янсуар

Бу елның май аенда Кырымда узган «Золотой Витязь» XXVI Халыкара кинофорумын Эмир Кустурицаның «По млечному пути» фильмы ачты. Ул бертавыштан фестивальгә тон бирүче, алай гына да түгел, аның төп девизын һәм миссиясен бар тулылыгында чагылдыручы картина буларак игълан ителде. Хәтерләсәк, «Золотой витязь»ның девизы болай яңгырый: «Әхлакый идеаллар, кеше җанын олылау өчен». Кустурицаның картинасына кинематографка керткән өлеше өчен алтын медаль дә тапшырылды. Бу җәйдә Кустурица Кырым халкын үзенең «Тартмый торган» (The No smoking orchestra) оркестры чыгышлары белән сөендерәчәк, дип көтелә.

Шушы җәһәттән без дә фильмнарында күтәргән проблемалары аша рухыбызга якын булган режиссер иҗатына ретроспектива ясап кайтырга булдык.

«ЙӨЗ ЕЛЛЫК ЯЛГЫЗЛЫК»ТАН СОҢ...

«Человек склонен все забывать, и человеческий род со временем превратил это умение в настоящее искусство. После бедствий, принесенных балканскими войнами, после бомбардировок Сербии, я тоже стал учиться забывать или, по крайней мере, подавлять мысли, не дававшие мне покоя. Я как раз только начал упражняться в этом нелёгком умении, когда мне нанес визит один кинокритик, который в 1990-е годы делал погоду в Голливуде. Он внезапно напомнил мне, что причиной забвения может быть простая неосведомленность. Когда Джонатан во время кинофестиваля в Кустендорфе включил телевизор, чтобы посмотреть русскую программу на английском языке, он испытал глубокое потрясение. В это время показывали документальный фильм, посвященный очередной годовщине победы над фашизмом. Взволнованный Джонатан пришёл ко мне и сказал:

– Я всегда был уверен, что это мы, американцы, освободили Европу от фашизма. Но судя по тому, что я увидел по телевидению русских, без них не было бы никакого освобождения?

– Да уж русские немного потеряли в этой войне с нацизмом, всего каких-то двадцать пять миллионов человеческих жизней. Сущая безделица!

Я опасался, как бы мой высокий гость не оскорбился, решив, что я потешаюсь над его невежеством. Было очевидно, что эти пробелы являются следствием дезинформации, но, поскольку он уже привык жить с таким представлением, исправлять что-либо было бессмысленно. Если он попытается выбраться из этой пропасти, то может начать сомневаться во всем подряд, возможно, даже в подлинности кока-колы, гамбургеров и Голливуда.

– Продолжай жить с идеями, к которым привык, – дружески посоветовал ему я.

Все-таки хорошо, что я пишу книгу. По крайней мере, останется документальное подтверждение моей жизни. А то может произойти как у русских с их борьбой с фашизмом: в будущем кто-нибудь станет говорить обо мне как о булочнике или каком-нибудь токаре».

Әнә шул үз ирониясе, һәрчак урынлы юморы, сарказмы, фаҗигадән – көлдерә, көлке хәлләрдән елата белүе белән үзенә җәлеп итә дә аның фильмнары. Бәлки, алар да режиссер-нонконформист буларак даны таралган Кустурица тарафыннан «ак таплар»дан арыну өчен төшерелгәндер?

Идеаллар алышынган, иллюзияләр җимерелеп, аларга алмаш булырдай яңалары әле ныгып өлгермәгән 80нче еллар азагы – 90нчы еллар башы өчен Эмир Кустурица исеме һәм ул тудырган дөнья сурәте, эстетикасы үтә якын. «Андерграунд», «Время цыган», «Черная кошка, белый кот», «Жизнь как чудо»... – постсовет җирлегендә «Кустурица бумы» башлангач, бу фильмнарны күтәп алып, йотлыгып карадылар. Кустурицаны карау модага әверелде, аңлау – югары интеллектуальлек билгесенә.

Аны Голливудта, Каннда «балкан Феллиние» дип йөртәләр. Минем өчен Кустурица исә Габриэль Гарсиа Маркес белән янәшә тора. Маркес тудырган реализмны «магик» дип атап йөртү гадәткә кергән булгач, Кустурицаныкын да шулай атарга кирәктер, бәлки. Әмма эш -измнарда, терминнарда түгел. Ә бу шәхесләрнең үз чорын, аның иң сызланулы яралары белән җөйләрен кәгазьгә, пленкага ничек төшерүендә. XX йөзнең иң шәп романнары исемлегендә беренче позицияләрдә исәпләнгән «Сто лет одиночества» авторы белән югослав (ә Кустурица Югославиянең таркалуына кискен каршылык белдерүчеләрнең берсе, ул үзен хәзер дә горур рәвештә югослав дип атый. – Авт.) режиссерының, очрашып, гәпләшеп утырсалар, сөйләшер сүзе табылыр иде, минемчә. Фантазияләр дилбегәсен тагын да йомшарта төшеп, болар янына Сергей Параджановны да китереп утыртсаң...

Әйе, чөнки сүз бит милли колорит, төрле культуралар, инануларның үзара кушылуы, аларның бер-берсенә тәэсире нәтиҗәсендә гасырлар дәвамында формалашкан менталь күзаллаулар системасы, код, геном турында бара. Шулай ук – еракка киткән тамырлар, борынгы чорларда шаны булган халыклар һәм империалистик система басымы астында аларның трансформациясе хакында да. Кустурицаның фильмнарында да, гамәлләрендә дә, инде югарыда искә алганча, системага мөнәсәбәтне ачыктан-ачык белдерү, сәяси позициясендә ахыргача тору аермачык чагыла. Бу мәсьәләдә ул «песиле-тычканлы» уйнамый һәм, кирәк тапса, сәяси карашлары өчен дуэльгә чакырырга да әзер. Һәрхәлдә, биографиясендә андый очрак бар.

«САРАЕВО РОЗАЛАРЫ», ЯКИ ЯҢА САЛА

Босния сугышы вакытында Сараево урамнарында артиллерия снарядлары төшкән урында калган бүрәнкәләрне «Сараево розалары» дип атыйлар. Снайперлар пулясыннан кешеләр һәлак булган, снарядлардан асфальт асты-өскә килгән бу урыннарны сумала, пластик һәм кызыл буяу агызып катырып куя торган булалар. 1992–1996 еллардагы Сараево камалышы вакытында шәһит киткәннәрне искә төшереп торсын өчен халык тарафыннан саклаган хәтер билгесе алар. Әмма шәһәрнең йөзе яңарган саен, «розалар»га да урын калмый, ди анда булып кайтучылар. Әйтүләренчә, туристларга күрсәтер өчен генә саклана алар хәзер.

«Минем туган шәһәрем башка юк», – дип, Кустурицаның Сараевога кайтудан баш тартуы – билгеле факт. Югославиясен Голливудка алыштыруны гайре табигый хәл дип исәпләгән «гыйсъянчы» бүгенге көндә Сербиянең Мокра Гора тирәсендәге Златибор өлкәсендә үз авылында көн итеп ята. 2005 елда Эмир Кустурица үзе ясаган архитектура проекты – Дрвенград авылы (икенче исеме – Кустендорф, 2008 елдан биредә Халыкара кино һәм музыка фестивале уза. Кустурица, белүебезчә, музыкант та. – Авт.) өчен Филипп Ротье премиясенә ия була. Бу урыннарны ул әле шул ук Балкан темасын күтәргән «Жизнь как чудо» фильмын төшергәндә үк яратып кала. Бу фильмда, хәтерләсәк, төп каһарман Лука Балкан ярымутравы белән калган дөнья

PRESSA.RU

арасында бәйләнеш булдырыр өчен, туннель төзү белән мәшгуль. Бу символик туннель ярдәмендә Кустурица үзенең тамашачысын әле шул фильмы аша үк төрле мәдәниятләр, тугандаш һәм гомумән җир йөзендәге барлык халыклар арасындагы гармониягә сусау идеясенә тоташтыру омтылышын ясаган иде.

Һәм менә, аны төшереп бетереп прокатка чыгаргач, ул күңеленә хуш урынга килеп урнашып, үз куллары белән авыл төзи. Дрвенград тулаем агачтан торгызылган: йортлары гына түгел, хәтта юлларының да күп өлеше агач белән түшәлгән. Борынгы серб авыллары нинди булган, нәкъ шулай. «Туган Сараевомны югалткач, мин җирдәге җәннәтне, һәрхәлдә, аның моделен үз кулларым белән төзергә теләдем», – ди Кустурица әлеге авыл турында.

Монда да системага, бу очракта инде дөньядагы котылгысыз глобализм нәтиҗәләренә каршы бара ул: дуэльләргә чакырып, мәйданнарга чыгып, йә булмаса фильмнары, китаплары аша тәэсир итеп кенә түгел, ә матди, көндәлек тормышында гармония тудырып. Хәл алып, башын күтәреп килгән «Кустурица ватаны» вәкилләре өчен бу адым чыннан да уен гына түгел икәнен югарыда искә алынган Голливуд режиссерыннан аермалы буларак, ерактан торып та аңлыйбыз. Чөнки азмы-күпме хәбәрдар без. Ирексездән, чагыштыру варианты буларак, хәтергә Маргарет Мадзантининың «Рожденный дважды» әсәре килә. Һәм аның буенча Серджио Кастеллито куйган фильмның кадрлары күз алдыннан йөгереп үтә.

Җимерелгән Сараево хәрабәләре арасында бер-берсе белән тоташкан кеше язмышлары турында сөйли Мадзантини белән Кастеллито романда һәм фильмда. Боснияле Гойко, мөселман кызы Аска, Италиядән килгән, җитеш гаиләдә тәрбияләнеп үскән Джемма һәм аның сөйгәне, фотограф Диего. Сербияле офицерларга Сараеводагы яулардан соң үзләре хасил иткән лагерьларда мөселман хатын-кызларын даими мәсхәрәләүләре турында Гаага трибуналындагы судта ачыктан-ачык сөйләргә туры килә. «Рождённый дважды»ның каһарманы Аска – шуларның берсе. Ул дөньяга тудырган бала – туган шәһәрендә тугандаш халыклары тарафыннан кылынган явызлыкның, ерткычлыкның нәтиҗәсе. «Әле кичә генә без бер үк чәйханәләргә йөри, урамнарда сәлам биреп узыша идек...» – дип үрсәләнә үтерелгән туганнарының гәүдәләре өстенә капланып гап-гади шәһәрлеләр. Бу сугыш – аларның сугышы түгел. Һәм шушы сугыш эчендә дөньяга аваз салган гөнаһсыз сабыйны йортның хәрабәләре өстендә кулларына күтәреп, күңеле белән шагыйрь, рухы, омтылышы белән иминлек көрәшчесе булган Гойко – аны үзенә уллыкка алыр өчен зур акчалар түләгән Джеммага тапшырганда: «Бу баладан гомер буена Сараево белән тәмәке исе киләчәк», – ди.

Кустурицаның «По млечному пути» фильмын караганда да, «Сто бед» китабында да без «безнеке» һәм «безнеке түгел»ләр белән кешелеклелек һәм ерткычлык дигән чикләр аша өзлексез узып йөрибез. Мадзантининың Гойкосы җиткергән хакыйкать Кустурица геройларыныкына да тәңгәл:

«Хочешь достойно выглядеть, заведи речь о международной политике, только эти пустые лицемерные разговоры ничего не дают нового ни миру, ни нам самим. Мёртвый ребенок, которого обмывает мать-мусульманка, ничего не значит. На этой веранде ведётся игра в Цивилизацию».

ЦИВИЛИЗАЦИЯ ӨЧЕН КӨРӘШ

Сараевоның шәһәр читендәге «чегәннәрнеке» дип атап йөртелгән районында туып-үскән бәләкәй Эмирларның йорты янында, ул үзе язганча, дүрт гыйбадәтханә бер-берсе белән янәшә диярлек тора: католикләр, православиелеләрнең храмнары, синагога һәм мәчет. Әти-әнисе мөселманнар булса да, борынгы бабалары арасында православие динен тотучы серблар барлыгын ачыклый һәм православие динен кабул итә инде җитлеккән Кустурица. Аның өчен Сараево һа-

ман да элеккеге – «Европа Иерусалимы» булып кала бирә.

Сүз уңаеннан, 2004 елның 25 сентябрендә ачылган Дрвенград саласыннан туристлар өзелми. Урамнары һәм мәйданнары Кустурица гомере буе хөрмәт иткән атаклы кешеләрнең исемнәре белән тамгаланган. Әйтик, режиссер үзе Дрвенградның Брюс Ли урамында, 1нче номерлы йортында яши. Авыл территориясендә православие чиркәве, музей, китапханә, кинотеатр бар. Кустурица һәм аның тормыш иптәше Майя бүгенге көндә актив рәвештә хәйриячелек белән шөгыльләнәләр. Режиссер үзе, «христианин» буларак, дөньяда иминлек урнаштыру өчен һәркемнең җаваплы булуы хакында даими кабатлый.

«Сто бед» китабында аның нәкъ менә шушы тарафка юл тотуы азмы-күпме ваемлана иде инде. Ә менә Моника Белуччи катнашында төшерелгән, тәнкыйтьчеләр шактый каршылыклы кабул иткән «По млечному пути» фильмында ул безгә шушы яшенә җитеп формалашкан карашларының һәм фәлсәфәсенең тулы квинтэссенциясен тәкъдим итә. Фильм хакында биргән бер интервьюсында Кустурица болай ди: «Бу минем күз алдымнан узган барлык сугышларның бер җыелмасы. Сугыш нинди генә сәбәптән башланса да, һәлакәткә илтә. Сугыш вакытындагы мәхәббәт турында әлеге фильм. Ә мәхәббәт нәкъ менә сугыш вакытында аеруча кирәк».

Моңа кадәр төшергән картиналарында, әйтик, «Андерграунд»та, реаль этник җирлеккә, реаль милләт вәкилләренең ярасына басым ясалса, соңгы фильмында Кустурица гомумиләштерүгә таба адым ясый. Кемнәрдер моны режиссерның «аруы», «кризисы» белән аңлатырга тырыша. Минем үземә аның бу тарафка юл тотуы гаять табигый тоела. Бу – «Голодные игры» рәвешендәге Голливуд блокбастерларына кыек атып туры тидерелгән ирония ядрәсе дә, бәлки? Бәлки, цивилизациянең барыбыз өчен дә бер булуына ачыктан-ачык ишарә булып яңгыраган гуманистик акттыр? Хәер, без хәзер артык ихласлыкка һәм самимилеккә ышанырга куркабыз шул...

Ә бу акт, үз чиратында, тарихка эчтән, йә булмаса, кырыйдан карау формасы булудан туктап, өстән карау рәвешен ала. «По млечному пути» фильмын караганда, мин баштарак аңлый алмыйча аптырадым: нәрсә шулкадәр сәерсендерә, борчый соң? Аннары төшендем: перспектива. Өстән караш. Дөрес, моңарчы да Кустурица фильмнарында гашыйклар оча һәм җир тормышына биектән күз ташлый иде. Әмма монда без – тамашачысы да – «очабыз».

Кемнәрне күрәм мин бу югарылыктан: ишәгенә атланып, пулялар явы астында кешеләргә сөт ташудан туктамаган Костаны, ул гашыйк булган ярымсербияле, ярымиталияле Невестканы (монда Кустурицаның Тарантинога пародиясенә игътибар итмичә узу мөмкин түгел, әлбәттә. – Авт.), Костаның сөт ташый торган цистернасына ядрә тиеп, сөте агып чыккач, явып торган пулялар астында тәвәккәлләп сөт эчәргә чыккан, соңрак героебызны үлемнән саклап калган ач еланны, кулга ияләшкән, тоташ снарядлар сызгырып торган Босния күген рәхәтләнеп колачлап оча алмый интеккән бөркетне... Бу фильмда җәнлекләр белән кешеләр бертигез. Аларны яшәргә теләк, омтылыш берләштерә.

АБОНЕНТ БЕЛӘН ТОТАШТЫРУ... МӨМКИН ЧАКТА

Гиперреалистик, урыны-урыны белән фантасмогория, абсурдны хәтерләтүче фильм дөньясы, ничек кенә сәер булмасын, берсүзсез ышандыра. Канлы ваннага казларны куып кертеп башлаган, миналарга абындырып, бәтиләрне канлы калҗага әверелдереп дәвам иткән фильмын гаять аскетик һәм кырыс төгәлли режиссер: канлы иттарткыч урыны булган урынга монах Коста тарафыннан ташлар ташытырып, аларны тезеп, төрбә ясатып. Екклесиаст әйтмешли, «Ташларны җыяр вакыт», димәк. Ә үткәннәрне җиргә иңдереп, дога белән юып, юаныч табарга. Яшәргә.

Без белгән «милләтче» Кустурицаның, христиан тәгълиматы тәэсире, инанулары нәтиҗәсендә, яңа караш ноктасына килүе, әйтерсең, «Күктәге» Әткәсенең караш ноктасына тоташырга омтылу ул. Нәкъ менә инану призмасы аша режиссер буларак кына түгел, ә язучы буларак та соңгы әсәрләрендә масштаблырак колачлауга ирешә Кустурица. Миллилек төшенчәсе белән иман төшенчәсе арасында тигезлек хасил була.

Бүгенге Кустурицаның фильмда белдергән позициясе һәм эстетикасы дөньяда барган вакыйгалар ясылыгында бик акыллы, зирәк, котылгы илтүче юлны күрсәтүче маяк булып тоела. Бер миңа гына да түгел. Шул ук бурычны ул үз алдына язучы буларак та куя:

*«Кризисы и войны изменились, и со временем умение забывать стало формой утешения. Иначе как бы человек смог свыкнуться с порочными идеями современного мира? Как он смог бы, к примеру, согласиться участвовать в войне во имя гуманизма? Когда вы принадлежите к маленькому народу, который отказывается покорно следовать идеям великих держав и в самый разгар передела мира настойчиво задается вопросом «Где наше место в этой истории?», великие державы забрасывают вас бомбами, которые называют «ангелами милосердия»**

Я хочу написать книгу и навести порядок в моих мозговых извилинах, по которым бродит множество воспоминаний. Я хочу избежать любых недоразумений. А также избежать судьбы телефонного абонента, которому тщетно пытаются дозвониться родственники и друзья, не зная, что его больше нет в мире живых, и после бессчётного количества звонков слышат в трубке лишь женский голос, равнодушно повторяющий: «Вызываемый абонент временно недоступен».

Кустурица турында язам... Әмма, асылда, «үз абонент»ым турында уйлыйм. Ул да Киек Каз юлын хәтерләтә миңа. Совет чоры астрономия дәреслекләрендә «сөтчел юл, сөтле юл» дип тәрҗемә ителгән Киек Каз юлын. Ул чакта без әле Дәрдемәнднең «Сөт калыр, ватан китәр...» дигән юлларын яттан белми идек... T







* НАТО 1999 елның язында Сербиядә шартлаган бомбаларга шундый исем бирә.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ



«Татарстан» журналының әдәби премиясе

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы әдәби премиягә бәйге игълан итә

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибарны арттыру максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы – бәйгенең төп шарты!**

Кульязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2017 ел дәвамында «Татарстан» журналы Экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2017 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кульязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – бәлешмә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кульязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кульязмалар tatarstan@tatmedia.com электрон тартмасына «КОНКУРСКА» тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны үткәрү вакыты 2017 елның 19 гыйнварыннан 2017 елның 15 декабренә кадәр.

Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында.

«Татарстан» махсус журналы өчен

Сания Юныс кызы Әхмәтҗанова 1962 елның 20 апрелендә Татарстанның Арча районы Курса Почмак авылында туган. Арча педагогия училищесын, Казан дәүләт педагогия институтының рус-татар бүлеген тәмамлагач, хезмәт юлын укытучы булып башлый. Ике дистә елга якын балаларга белем бирә, аннары күп еллар дәвамында укытучылар журналы – «Мәгариф»тә эшли. Хәзерге көндә «Татар-информ» Мәгълүмат агентлыгының татарча яңалыклар сайты редакторы. Сания Әхмәтҗанова – күпсанлы шигырь җыентыклары, популяр җырлар авторы.

Сания Әхмәтҗанова

ТОЛЫМ

***

Аңа гомерлек сабак биргән ул көн мәңге оныттырмас үзен, мөгаен. Онытырлык кына булмады шул.

«Коммунизмга» газетасы редакциясеннән «Тукай якташы» әдәби түгәрәгенең чираттагы утырышыннан кайтып барышлый, аскы каттагы бер бүлмәсенең тәрәзә пыяласына зур хәрефләр белән «Парикмахерская» дип язып куелган ике катлы йорт яныннан инде бу юлы да тукталмый үтеп киттем дигәндә, ул кинәт кырт кына борылды да, кара брезент белән тышланган авыр ишекне көчкә ачып, салон эченә керде... Зал әллә ни зур түгел икән. Аниянең мондый җирне әле беренче күрүе. Кинофильмнардагы ымсындыргыч матурлык салоннарына бер дә охшамаган иде бу зал. Бүлмәнең тынчу һавасында әллә ничә төрле ят ис – барысы бергә буталган. Кечерәк кенә өстәлдә төрле зурлыктагы пластмасса банкалар, пыяла шешәләр, аэрозоль савытлары тезелеп киткән. Пыяла шешәләрнең кайсында яртылаш, кайсының төбендә генә төсле сыекчалар, буяулар, порошоклар, тагын ниләрдер бар. Зәңгәр буявы купшаклана башлаган түр стенадагы радиодан «Малиновый звон» җыры ишетелә. Бу яңа җырны аларның классында яратмаган кеше юк бугай...

Исәнләшкәч, чират-фәлән булмаганга сәерсенеп, Ания чәч кисүче апага сораулы караш ташлады. «Нишлибез?» – диде куе зәңгәр болонья альяпкыч япкан ханым, уң яктагы зур көзге каршындагы урындыкка ишарәләп. Аның киңчә җилкәләренә муенсыз-нисез генә утыртып куелган бәләкәй башындагы ясалма көдрәле кыска чәчен күргәч, Ания бер мизгелгә никтер баягы уеннан кире кайтмакчы булып, икеләнеп тә куйды. Ул арада радиода «Верасы» төркемен тагын бер өр-яңа җыр – «Танец на барабане» алыштырды. Бу дәртле көй Аниянең бераз кәефен күтәреп, күңелен җилкендереп җибәрде. Гнатюк башкарган җырдагы барабанда биюче кызны ул бер мизгелгә үзе итеп күз алдына китерде. Менә ул, кыска чәчен җилфердәтеп, солнце-клеш итәктән, биек үкчәле туфлидән барабан өстендә бии...

Барабань, барабань,
Только каблучком его ты не порань...

Артында басып торган чәч кисүченең салкын куллары җилкәсенә менеп кунаклагач, ул, сискәнеп, җилкенчәк уйларыннан айнып, кире чынбарлыкка кайтты. «Нишлибез?» – дип кабатлады чәч кисүче. «Кисәбез!» дигән кискен җавапны алуга, ул, шуны гына көткәндәй, берни сорап та, Анияне үгетләп тә тормыйча, аның калын толымын симез учына чак сыйдырып тотып, иләмсез дәү кайчысы белән, шактый ук азапланып, төбеннән кисеп алды да кыз алдындагы көзгеле өстәлгә китереп тә салды... Ания, көзгедә үзе урынына ят кыяфәтле кызыйны күреп, өнсез калды...

– Аһ! Мин... җилкәдән калдырып... бераз гына кистермәкче идем...

Аның сүзенә каршы чәч кисүче тоныкь тавыш белән нидер җавап бирде. Әмма Ания аны аңларлык хәлдә түгел иде. Кыз томанлы карашын көзгедәге сурәткә төбәде.

– Болай аны сатарга выгоднорак, – дип дәвам итте шактый мул гына шәрә беләкле, кабартма кебек кабарып торган ап-ак куллы «палач» хатын. – Озын толым кыйммәтрәк йөри. Теләсәң, үзем сатып бирәм. Не переживай... Кыркытып тормасаң, ярты ел да үтмәс, көлтә койрыгың әле җилкәңнән дә узып китәр.

Менә шул мәлдә генә Ания ашыгычлык белән ярамаган эш эшләп ташлаганын аңлады. Ник туктатмады аны бу апа? Ник ичмасам чәчен кисмәскә киңәш итмәде? Авылга кайтып, әнисенең күзенә ничек күренер? Әнисе, аны бу кыяфәттә күргәч, нәрсә дияр? Ул әнисенә нәрсә дип җавап бирер?.. Әйтерсең аның бу ялгыш адымына нәкъ шушы чәч кисүче хатын гаепле иде. Көзге алдында хәрәкәтсез елан күк бормаланып яткан, елкылдап торган коңгырт төсе сүнеп калган толымыннан курыккандай, аны нишләтергә дә белмичә, бер – кулына алып, бер кире куеп бераз матавыкланганнан соң, портфеленә салып куярга булды. Толымы җансыз иде... никтер авыр һәм салкын иде. Кыз, кире уйлап, сары тышлы шигырь дәфтәренең уртасыннан куш бит ертып алып, толымын шуңа төргәндәй итте дә төргәкне сумка төбенә шудырды... Дөресрәге, толым – кулыннан үзе шуып төште. Чыгар ишекне тапмыйча, бер мәл исәңгерәп торды. Чәч кисүче, берни булмагандай, үз эшеннән канәгать калган рәвештә, бакыр биш тиенне учында биетеп, «Возьми сдачу, дурочка», – дип, аның артыннан кычкырып калды. Тиле шул Ания, тиле, ти-ле!

Саф һавага чыккач, кыз иркен сулап куйгандай булды, әмма бер-ике адым атлауга ук, үзендә ниндидер бер сәер халәт тойды. Нидер җитми... Әйе... уенчак толымы, аның сыгылмалы гәүдәсенең иркә борылышларын кабатлап, аркасын рәхәт кытыклап, әле бер якка, әле икенче якка тирбәлми... Башы никтер җиңеләеп киткәндәй тоелды... Шәрәләнеп калган муенына арттан салкын җил килеп бәрелгәндәй булды. Ания, күшеккән кошчык кебек, нәфис муенын җилкәсенә батырды. Шактый кыска калдырып киселгән дулкын чәче җил уңаена йөзенә сибелеп иркенли, тыңлаусызлана, тузгый иде. Әйтерсең ул шыр ялангач калган, бөтен кеше аңа карыйдыр кебек тоелды Аниягә. Юк, яныннан узып баручыларның берсенең дә анда эше юк бугай. Шулай да ул, яңа үзеннән качарга теләгәндәй, муенына салган юка зәңгәр косынкасын чишеп алып, башына бәйләп куйды.

Ания тормышында беренче мөстәкыйль адымны ярамаган эштән башлаганын аңламый иде әле...



Иллюстрация: «Автопортрет». Зинаида Серебрякова.

***

...Калкулыктан караганда, тирә-як уч төбендәге кебек җәелеп ята, әнә. Кичке эңгердә Камырсаз никтер сәер-куркыныч булып күренә. Елак тәкърлек тавышын тыңлый-тыңлый, җәйге каникулда Ания энесе белән ул аланда ике көн сарык көтүе көткән иде... Мәскәүдә җәйге Олимпиада гөрли! Дөньякүләм вакыйга! Ә ул, булачак укытучы, телевизордан үзе яраткан спорт ярышларын карамыйча, торф өемнәре арасында, балакларын сызганып, ялан тәпи дымлы үлән ерып, сарыклар, кәҗәләр куып йөри. Гаҗәеп гүзәл картина – «Сарык көтүче Ания». Кич йокларга яткач та әле күзенә сарыклар, кәҗәләр күренеп азаплаганны исенә төшереп, кызыбыз моңсу гына елмаеп куйды. Ялансу буе да бушап калган. Җәй көне булса, әле бу вакытта анда аркандагы бозаулар үлән чемченер, берән-сәрән атлар утлап йөрер иде. Арырак, колхоз фермасы артында зират моңаеп утыра. Аниянең күңелен кинәт өшеткеч шом биләп алды. Ялгыз талга күп калмаган инде калуын... Ул, нидәндер шикләнеп, ялт кына артына борылып карады да адымнарын кызулатты...

Энесе капка төбенә чыгып каршы алды.

– Без сине кайтмый дип торабыз инде, апай! – диде дә, апасын кочаклап алам дигәндә, яулык астыннан тырпаеп чыгып торган кыска чәчен күреп алды. Күреп алды да тыныч кына:

– Әни үтерә, – дип куйды.

– Үтерсә-үтерер. Кайчан да бер үләсе.

– Сине үтергәнче, йөрәге ярылып, үзе үлмәсә...

– Теләсә нәрсә сөйләмә...

Үләргә тек үләргә! Капка төбендә таптанып торып булмый бит инде. Ания, бөтен кыюлыгын җыеп, эчкә атлады.

– Гомер булмаганны. Иң артка калып йөрисең. Аксак Казның төшкәненә дә әллә кайчан инде... Әнисенең «исәнме»се шул булды.

Аксак Каз дигәне – читтән күчеп кайткан, «Гусь» кушаматлы чатан күршеләре. «Хәзер мин дә аксак казга әйләнмәсәм ярый инде», – дигән уй йөгереп үтте кызның башыннан.

– Әни!.. Мин чәчне кистем...

Әнисе аны-моны абайламый әлегә...

– Бик кыҗрап йөргән иең. Кәҗә тәкәсе булгансың икән... Кая. Күрсәт.

Кызы маңгай чәчен генә кыркыткан дип уйлады, ахрысы, әнисе. Ания башыннан яулыгын шудырып төшерде. Мич буенда басып торган Бәгыйдә апа, берни аңышмыйча, беравык телсез калып торды да, егылмас өчен башта мичкә сөялде, аннан соң, башына ис тигән кеше кебек алпан-тилпән килеп, түр якка керде дә диванга авып төште:

– Бар икән күрәселәрем... – Сүзләре теш арасыннан сытылып чыкты. Агарынган иреннәре кысылып килде.

Башланды... Әнисенең әлек артык нык борчылган чакларында баш өянәге килә торган иде. Кан басымы бик нык күтәрелә дә, ул, бизгәк тоткан кеше шикелле, дер-дер калтырана башлый... Соңгы елларда бу хәлнең күптән кабатланганы юк иде инде.

– Фәнизә апайны чакыр! – дип кычкырды ул энесенә.

– Үзең кер! Әни янында мин калам!

Әйе шул... Энесенең башы эшли...

Фельдшер Фәнизә каршы йортта гына тора. Өйдә генә булса ярар иде! Өйдә генә булса ярар иде!

Фәнизә, чәче-башы тузып, сулышы кабып капкадан йөгереп кергән Анияне күргәч, бот чабып: «Әстәгъфирулла!!!» – диде дә, эшнең нәрсәдә икәнен тиз аңлады бугай, сумкасын алырга өйгә атылды.

...Бу юлы әтисе Анияне якламады. Тәмәкесен бармак арасында бөтергәләп, шактый озак кына мич каршында утырды. Аннан соң әллә ниткән ят, баздан чыккан тавыш белән: «Киләчәктә дә болай үзвуле кылансаң, кая барып чыгарсың, кызый, белмим... Бераз чама белергә кирәк... Йөрисе юк Чүриледән качкан самашушный нәрсә кук! Үтерәсең бит әниеңне... Матри, кызый! Андый-мондый булсаң, мин анагыз кук ачуланып кына калмам... Ир бала булсаң, белер идем мин сине нишләтәсен!» – дип, урындыктан сикереп торды. Ания, шурләп, артка чигенде. Гыйльмулла абый, мич буенда мөлдерәп утырган мал чиләген ачу белән эләктереп, суын чайпалдыра-чайпалдыра түгеп, өйалдына чыгып китте. Аның артыннан артсыз урындык шап итеп авып калды... Башка вакыт булса, Бәгыйдә апа: «Атагыз сугышта күп кан югалткан. Аңа кеше каны салганнар. Шуңа шундый кызу канлы ул. Барыгыз, чыгып торыгыз...» – дигән булып, үзенчә рәвешләп, энесе белән икесен ишегалдына чыгарып җибәрер иде... Әтисе булып әтисе чыгырдан чыккач, хәлләр шактый мөшкел бит әле.

Бәгыйдә апа ул көнне кеше була алмады. Төне буе даруын эчеп, ахылдап-ухылдап чыкты. Ания аның янына килергә курыкты. Ике арада энесен йөртте.

Әнисе икенче көнне сыер саварга да тора алмады. Башын бәйләп урында ятты. Сыерны Гыйльмулла абый сауды. Өйләгә таба стенага карап яткан җиреннән әкрен генә сүз башлады:

– Ирҗәнкә тәре! – диде ул. – Бүтәненнән куркып йөрдем... Болай ук имансыз булырсың дип, башыма китермәгән идем...

Бераз сүзсез яткач, әнисе торып утырды да, сулкылдый-сулкылдый, тыйлыга алмыйча елап җибәрде. Эчендәге гомерлек хәсрәт-борчуларыннан арынырга теләгәндәй, чарасызлыктан, бәгыреннән елады ул. Озак елады... Елап туктагач:

– Ышаныч бетте сиңа, кызый! Болай булгач, ике дә уйлап тормыйча, сафлыгыңны югалту да берни түгел сиңа...

Әнисе торып басмакчы булган иде, башы әйләнеп, урынына кире утырды.

– Инде толымыңны да ташлаган булсаң, рәхим-шәфкать көтмә... Җилгә очкан һәр чәч бөртегең саны кадәр ләгънәт төшәр башыңа...

Ания зәңгәр яулыкка төргән толымын тотып әнисенә якыная башлаган иде:

– Күземә күрсәтмә! Сал әнә сандыкка... – дип, Бәгыйдә апа кире урынына ятты. Ания шулай эшләде дә.

МАХСУС ПРОЕКТ

22нче чыгарылыш

Татарстан юбилярлары

Авиатөзелеш новаторы

Александр Гомзин,
«М. П. Симонов ис. ТКБ» ФҖБ АҖнең генераль директоры, техник фәннәр кандидаты

Бөтен коллективыбыз һәм шәхсән үз исемемнән авиация тармагындагы иң эре предприятиеләрнең берсе – С. П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы хезмәткәрләрен оешмалары оешуының 90 еллыгы белән котлыйм. Завод тарихы илебез авиациясе үсеше тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Сезнең бүгенге көнегез – хәрби һәм граждан самолётлары җитештерүдәге саллы уңышларыгыз, аларның күбесе – илебез һәм дөнья авиатөзелешендә күренекле урын били. Казан авиазаводы, үз җитештерүен уңышлы үстерә барып, гамәлдәге егәрлекләрен модернизацияләп һәм баетып, алдынгы технологик процессларны үзләштереп, яңа буын техникасын булдыруда мөһим роль уйный. Без нәтиҗәле партнёрлык өчен сезгә рәхмәтле һәм аның киләчәктә дә уңышлы үсәчәгенә ышанабыз. Хөрмәтле завод хезмәткәрләре, коллегалар! «М. П. Симонов ис. ТКБ» ФҖБ АҖ коллективы сезгә ныклы сәламәтлек, иминлек, илебез авиациясен үстерү, Ватаныбызның куәтен һәм аның глобаль сәнәгать индустриясендә имиджын ныгыту хакына хезмәтегездә уңышлар телибез!

М. П. Симонов ис. ТКБ, югары технологияле продукция булдыру операцияләренең тулы циклын башкарып, пилотсыз очу аппаратлары комплексын эшләү һәм җитештерүдә махсуслаша. Предприятие уникаль фәнни-җитештерү базасына һәм югары квалификацияле кадрлар составына ия. ТКБнда композит технологияләрнең, цифрлы технологияләрнең инжиниринг үзәкләре, көч корылмаларын тикшерү һәм җитештерү буенча инжиниринг үзәге булдырылган.

Реклама

Завод тарихы – илебез авиатөзелеше тарихы

Альберт Гыйльметдинов,
А. Н. Туполев исемендәге Казан милли-тикшеренү техник университеты – КАИ (КМТТУ – КАИ) ректоры

Үзенең бай эчтәлекле тарихы дәвамында С. П. Горбунов исемендәге авиация заводы «Туполев» ГАҖ коллективы, лаеклы юл үтеп, үзенә ышанычлы партнер, хәрби һәм гражданлык билгеләнешендә уникаль самолётлар төзүче абруен булдырды.

Совет вакытында Казан авиация заводы, илдә иң эре авиация предприятиеләренең берсе буларак, елына 50шәр самолёт төзеп, әһәмиятле дәүләт бүләкләренә лаек булды. Үз эшчәнлеге дәвамында завод 20 меңнән артык берәмлек самолёт төзеде, алар арасында бөтен дөньяга билгеле ПЕ-2, ПЕ-8, Ту-16, Ту-104Б, Ту-22М3, Ту-160, Ил-62М бар. Заводның тарихы – бөтен илнең авиация сәнәгате тарихы, илебез авиатөзелешенең интеллектуаль-техник куәте символына әверелгән конструкторлары һәм инженерларының лаеклы хезмәтләренең тарихы да.

Без С. П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводының булдыклы коллективы белән озакка сузылган һәм нәтиҗәле хезмәттәшлегебез белән горурланабыз, ә бит предприятие белгечләренең зур армиясен безнең вуз чыгарылышлары тәшкил итә. Студентлар даими рәвештә заводта була, җитештерү белән таныша, ә укуларын тәмамлагач, белгечлекләре буенча эшкә урнаша. Завод шулай ук нанокомпозит материаллар куллану буенча университет белән уртак фәнни-тикшеренү эшләре алып бара.

Завод хезмәтчәннәренә киләчәктә дә авиатөзелештә лидерлык позицияләрендә торуларын, чәчәк атуларын, яңа казанышлар, яңа уңышлы контрактлар һәм ышанычлы партнёрлар телим!

Реклама

ПЫЧАКСЫЗ ПЫЧАКЛЫЛАР

Бездә сәер, кызык исемле авыллар байтак. Кайберләре турында ишеткәч көлеп тә куясың. Ә менә Пычак авылы дигәч күз алдына кораллы кешеләр килеп басты. Тик усал исемле бу авылда, киресенчә, йомшак кешеләр яши булып чыкты. Һәм аларны явызлардан пычак түгел, ә башка нәрсә яклый...

Автор:
Руфия Фазылова

БӘРӘҢГЕ УРЫНЫНА – ҖИЛӘК!

Кукмара районының Пычак җирлеге өч авылны берләштерә: Әсән-Елга, Арпаяз, Пычак. Шулар арасыннан Пычак, халык, хуҗалык саны буенча иң кечкенәсе булса да, үзәк җирлек булып тора. Урта мәктәп, «Әсәнбаш Агро» җәмгыяте бүлекчәсе биредә урнашкан.

Авыл башында безне Пычак җирлеге башлыгы Гәбделфәт Нәфыйков каршы алды:

– Безнең халык җитмеш төрле һөнәргә ия: күп итеп сарык үрчетүчеләр, сыер асраучылар байтак. Теплица ясап җиләк, чәчәк үстереп сатучылар да бар. Сезне кайсы өлкә кызыксындыра? – диде.

«Җиләк» дигән сүзне ишеткәч, кызыксынып киттек. Июнь башы гына бит, ә монда, берәүләрнең теплицаларында, татлы җиләк инде өлгергән дә икән. Шуңа да иң беренче эш итеп җиләкчеләргә киттек.

Бариевларга арт бакчадан кердек. Бәрәңге бакчасын тутырып җиләк үсеп утыра! Җирне махсус кара пленка белән каплаганнар. Болай иткәндә җиләк җиргә тими, ә димәк, череми, кортларга бирешми икән. Пленка астыннан нәзек торбалар үтә – җиләккә су күп кирәк.

– Бәрәңге урынына җиләк кенә ашыйсызмы әллә? – дим, каршыбызга килгән ханымга шаяртып.

– Бәрәңгене сатып алдык, – дип елмайды хуҗабикә Эльза Бариева. – Шул биш капчык җәйгә кадәр җитте. Хәзер бит бәрәңге элеккеге кебек ашалмый. Әллә ризык күп булганга, әллә башка сәбәп шунда.

– Димәк, бәрәңгегә караганда җиләк үстерү отышлырак булып чыга? – дим.

– Бу турыда сөйләргә иртәрәктер әле. Җиләкне узган ел гына утырттык. Дөрес, узган ел да җимеш бирде ул. Ирем Таһир утыртышырга килгән кешеләргә: «35 көннән җиләк җитешәчәк, ашарга килерсез», – дигән иде, чыннан да шул вакыт эчендә өлгерде.

– Егерме биш сутый җиләкне кем карый, кем җыеша? – дим.

– Узган ел бакчадан кермәдем. Түтәл араларында чүп үстермәскә тырыштым. Мыеклары чыга торды, кисә бардым. Ә җиләкне җыярга Кукмарада яшәүче кызым Гөлнур килде, бергәләп инде...



«Яшелчә, җиләк-җимеш үстерү иремнең теләге, нияте иде», – диде Эльза апа Бариева.

Фото: Ната Смирнова

БАЛ КОРТЛАРЫ БЕЛӘН ДУСЛЫК

Бариевлар яшелчә бакчаларына 10га 10 метрлы теплица ясаганнар. Җылыта торган электр миче дә алып куйганнар. Суны да шунда җылытып сибәләр. Май азагына җиләк, кыяр өлгергән инде. Ә без килгәндә зур-зур помидорлар, кечкенә карбызлар үсеп утыра иде.

Кызганыч, гаилә башлыгы белән күрешеп булмады, Мәскәүгә киткән чагы иде. «Яшелчә, җиләк-җимеш үстерү иремнең теләге, нияте иде», – диде Эльза апа. Белгечлеге буенча агроном Таһир абый белән телефоннан аралаштык:

– 2015 елда «Яшь фермер» программасы буенча 800 мең сум грант оттым, – диде Таһир Бариев. – Шуның 400 мең сумын-җиләк үстерүгә, 400 мең сумын теплица төзүгә тоттым. Узган ел эшне башладым. Әлегә өйрәнәбез, тәҗрибә туплыйбыз.

– Ни өчен нәкъ җиләк үстерергә булдыгыз? – дим.

– Кукмара районында моның белән шөгыльләнүче юк, шуңа да алындым. Саба, Мамадыш районындагы җиләк үстерүче фермерлар янына барып эш тәртибен өйрәндем. Җиләкнең төрле чирләре була, кортлар ашый. Вакытында карап торырга кирәк. Күз тимәсен, әлегә безнең бакчада кортлар юк. Алай-болай үсентеләр чирли башласа, көзен агуларга кирәк. Ләкин җиләк чәчәк аткач, җимеш биргән чорда химикатлар кертергә ярамый. Безнең җиләкләр «натуральный», агу сипкән юк әле.

– Җиләк үстерү табышлы эшме?

– Шулай дип ышанасы килә инде, тик әлегә әйтергә иртәрәк. Керемне санаганда, ике ел буе ике үгез үстергән кебек акча керде. Даими сатып алучыларым булып, гел шушы юнәлештә эшләсәм, уңышка ирешеп булыр, дип уйлыйм.

Бариевлар өч ир бертуган, барысы да туган төбәкләрендә калган, төрле авылларда яшиләр. Уртак эшләре – умартачылык. Пычак авылы урманында йөз баштан артык кортлары бар. Тагын Кукмараның үзендә махсус кибет тоталар, анда умартачылык өчен нәрсә кирәк, барысы да кайтарылган.

– Бал кортлары белән «дуслашканга» ун елдан артык, – дип сүзен дәвам итте Таһир абый. – Бу өлкәдә шактый тәҗрибә тупладык. Сыйфатсыз балдан яхшысын аерабыз. Кайвакыт, аерым кешеләр, акча эшләү максатыннан, начар бал алып кайтып саталар. Әлбәттә, аның бәясе түбән була, халык шуңа алданып ала. Шуңа да сезон вакытында базарларга чыгып балны карап йөрибез. Закон буенча, начар балны саткан өчен штраф каралмаган. Алай да аерым оешмаларга бу хакта җиткерергә була. Кеше чын бал ашаса гына сау-сәламәт була. Мин гел әйтәм: һәр умартачының – үз сатып алучысы, ә кулланучының үз умартачысы булырга тиеш!

ТАУЛАР ЧЫЛБЫРЫ

Пычак авылында 158 кеше яши, җәен кайтучылар белән исәпләсәң, 58 хуҗалык бар. Шушы зур булмаган салада мине иң сокландырган нәрсә авыл тирәли сузылган таулар чылбыры булды. Әйтерсең, ул авылны җил-давылдан саклап, усаллардан яклап тора... Тау чылбырының озынлыгы 213 метр! Итәкләрендә 25 мең нарат күкрәп утыра.

– 1978-1979 елларда бу агачларны элеккеге авыл җирлеге башлыгы Мәфруза апа Кәлимуллина Саба урман хуҗалыгыннан алып кайткан, – дип сөйләде җирлек башлыгы Гәбделфәт Нәфыйков. – Аны бөтен авыл: яше, карты бергә утыртты. Яшь наратларны күз карасыдай саклап, көн дә тауның түбәсенә кадәр су буеннан чиләкләп су ташып тордылар. Элек бу таулар кызыл балчыклы, ерактан кызыл булып күренеп тора иде, ә хәзер, әнә ничек матур, Европаның Карпат тауларына охшап калды.

PRESSA.RU

Пычак урта мәктәбе бүген Мәсәгут Гомәров исемен йөртә.

Тирә-якны нарат урманы чолгап алгангамы, Пычакта һава рәхәт. Әйтерсең лә Кукмарада түгел, ә Кырым яки Абхазия тауларында йөрисең. Җәйге эсселәрдә, яңгырдан соң һава бигрәк тә шәп була икән: «Нарат исеннән исерешәбез», – диде авыл кешеләре.

Пычак – серле авыл. Монда XVIII гасырга караган кирпеч йортлар бүген дә бар. Заманында аларны Дәүләт Әхмәтов, Хисам Фәрхетдинов, Шәймәрдән Хисамов, Хаҗи Хәмзин исемле атаклы байлар салдырган.

– Пычак Иван Грозный яуларыннан соң оешкан, – дип сөйләде Чыршы урта мәктәбенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Фәния Гарипова. – Безнең авыл урман белән капланган булган. Нократ елгасының көньяк ягында урнашкан Кубәләү авылыннан Газиз һәм Гафар исемле кешеләр, агачларны кисеп, үзләренә йорт сала. Ике бертуган, ерак түгел бакыр чыганагы табып, бакыр чыгару белән шөгыльләнә. Бу җирнең байлыгы турында ишетеп, башка кешеләр дә килеп урнаша. Шулай итеп авыл зурая. Бакыр табудан тыш, ир-атларның күбесе аучылык белән шөгыльләнә. Ерткыч хайваннарга һөҗүм итәр, явыз кешеләрдән сакланыр өчен дип, алар үзләре белән һәрвакыт пычак йөрткәннәр. Чит авыллар, безнең борынгы бабайларны күргәч: «Пычаклылар килде», – дип әйтә торган булган. Шуннан авыл атамасы да «Пычак» дип калган. Тарихи истәлекләрдә менә шундый язулар бар.

Пычак борынгыдан һөнәрчеләр төбәге булып саналган. Заманында монда атаклы ташчылар, тимерчеләр, балта осталары, итек басучылар яшәгән. Аларның даны тирә-як авылларга гына түгел, күрше районнарга кадәр танылган була. Бүген исә халыкның күбесе (70% диделәр), Кукмарага йөреп эшли. Фермалар «Вамин» үз канаты астына алган вакытларда ук беткән. Аны яңадан торгызу өчен, миллионнар кирәк икән: биналар иске, ишелгән хәлдә. Шуңа да «Вамин»нан соң уңышлы гына эшләп килгән «Әсәнбаш Агро» җәмгыятендә, нигездә, ир-атлар механизатор булып хезмәт куя.

АВЫЛНЫ КҮТӘРҮЧЕЛӘР

Һәр авылның ихтирамга лаек кешеләре була. Пычак авылында андый шәхесне чын мәгънәсендә легенда дип әйтеп була. Авылдашлары Мәсәгут Гомәров 1773–1775 елларда бөтен Россияне тетрәткән, милли изүгә каршы беренчеләрдән булып баш күтәрүне оештырган Емельян Пугачевның иң дәрәҗәле полковнигы булган. Пычакта бу легендар кеше белән бәйле менә тагын нинди истәлекләр ишеттем: «Мәсәгут Гомәров яу бастырылгач туган ягына кайтарылып, авылдан авылга йөртеп рәхимсез җәзалана. Колагы, борыны киселеп, битләренә һәм маңгаена кыздырып мөһерләр сугыла. Соңыннан Таганрогка гомерлек сөргенгә каторга эшенә җибәрелә, шундагы газаплардан вафат була. Әтисе Гомәр Әширов, ике абыйсы Мәгъсут һәм Мансур, йөкле хатыны Мәрфуга да кулга алынып, Казан төрмәсенә озатыла. Аларның шуннан соңгы язмышы билгеле түгел. Гасырлар үтсә дә, без бу нәселне, куркु белмәс авылдашыбызны онытмыйбыз. Мәсәгут Гомәровның батырлыкларын балаларга сөйлибез».

Пычак урта мәктәбе бүген Мәсәгут Гомәров исемен йөртә. Белем йортында әлеге легендар шәхескә һәйкәл торгызганнар.

Мәктәп турында сүз чыккач, Зыятдин абый Гәрәфиев турында әйтми мөмкин түгел. Пычак урта мәктәбенең бүгенге бинасын салдырган, белем йортын районга, республикага таныткан шәхес ул. 22 ел буе биредә мәктәп директоры булып эшләгән Зыятдин абыйга бүген 70 яшь икән. Тормыш иптәше Гөлсәрия апа белән икәү генә яшиләр. Кызлары гаиләсе белән – Казанда, улы Кукмарада төпләнеп калган.

– Мин эшләгән чорда мәктәптә 250 бала укый иде, – дип сөйләде Зыятдин абый. – Хәзер менә йөзгә дә тулмый. Нишлисең, авылда яшьләр бик калмый шул. Әле ярый, дүрт авыл җыелып укыйлар. Мәктәп ябыла күрмәсен дип борчылам, авыл күрке бит. Мин эшләгән чорда мәктәп миллион сум акча отты, шуңа бөтен матди-техник базаны яңарттык. Бер дигән тарихи белем йорты әле ул.

Пычак мәктәбенең бинасы да, мәйданы да зур, ә иң кызыгы – урман эчендә утырган кебек. Мәктәпнең тирә-юнен озын агачлар каплап алган. Бу да Зыятдин абыйның хыялы булган:

– Яшеллекне, табигатьне яратам, – диде Чыршы авылының элеккеге мәктәп директоры. – Өйдә дә шулай, төрле-төрле агачлар, куаклар утырттым. Әтием Заһри умартачы иде. Мин дә аның эшен дәвам итәм – егерме баш кортым бар. Узган ел бал әйбәт булды, балаларга да, сатарга да җитте. Быел бал булмаска охшап тора. Көннәр салкын, кортлар «перга», ягъни үзләренә ашарга ипи генә җыялар. Бал алып кайтмыйлар әле.

Әлфия Сабирова бакчасында 200дән артык төрле чәчәк, дару үләне үстерә.

НАРАТ – ЗАМАН ТАЛӘБЕ

Мәфрүза апа Кәлимуллина йортына да сугылдык. Заманында тау итәгенә яшь наратлар утыртуны башлап йөргән ханым бүген ялгызы яши икән.

– Безнең авыл бик бердәм, авыл җирлеге башлыгы булып эшләгәндә дә шуңа игътибар итә идем, – дип сөйләде Мәфрүза апа. – Эшне күмәкләп башкаралар. Халык та бердәм. Әнә, яңа мәчетне күрегез, ничек итеп бергә салып чыктылар. Пычакта туып-үскән балалар да туган ягын онытмый: кайтып йөри, ярдәм итә. Әнә, безнең Әлфияләр атна саен, җәен-кышын авылда.

Мәфрүзә апаның олы кызы – Әлфия Сабирова тормыш иптәше белән төп нигез янына бурадан йорт, мунча салган. Бик матур, зәвык белән эшләнгән алар. Һөнәре буенча фармацевт әлеге ханым бакчасында 200дән артык төрле чәчәк, дару үләне үстерә икән.

– Мәфрүза апа, 25 мең төп нарат утырту кемнең уе иде? – дим.

– Ул чорның сәясәте белән бәйле иде ул: тирә-юньдә яшеллек үсәргә тиеш! Гомер-гомергә Кызылтау дип аталып йөргән бу табигать могҗизасы шулай итеп наратлы таулар чылбырына әйләнде. Наратлар китмәс дип борчылган идек, китте тагын. Әлеге дә баягы, авылдашларның тырышлыгы, бердәмлеге аркасында. Ничә еллар карап, көн дә чиләкләп су ташып тордык. Бездәге кебек наратлы тау республикада башка юк дип беләм.

«Эш бер көнгә дә туктамады, бер ел дигәндә мәчетне салып чыктык», – диде авыл кешеләре.

«Әтием Заһри умартачы иде. Мин дә аның эшен дәвам итәм», – ди Зыятдин абый Гәрәфиев.

...Авыл Сабан туе көнне Пычак авылында мәчет ачарга җыеналар. Аны бөтен авыл бергә төзегән. Кемдер төзелеш материалларына акча биргән, кемдер кирпечен салган. «Эш бер көнгә дә туктамады, бер ел дигәндә мәчетне салып чыктык», – диде авыл кешеләре. Иман йортын күреп чыктык: заманча, юыну, аш бүлмәләре белән, бик зәвыклы ул. Беренче катында мәдрәсә дә бар.

Тагын Пычакта яңа кибеткә нигез салганнар. Әлегә кадәр халык кибетсез яшәгән. Дәүләт программасы нигезендә пычаклылар кибетле дә булачак икән. Кыскасы, авыл яши, яшәрә!

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: АЛАБУГА КҮРӘЗӘЧЕСЕ

Алабугада бүгенгә кадәр иң борынгы риваятьләр «яши». Елдан-ел алар яңадан-яңа вакыйгалар белән баетыла, шулар белән тагын да матуррак, тагын да кызыклырак була бара – шуның өчен риваять тә инде алар.

Алабуга дигәндә һәркемнең шәһәрнең визит карточкасына әверелгән Шайтан-кала һәм аның манарасы исенә төшә. Шәһәрнең элекке кешеләре телдән-телгә шул манарада яшәүче куркыныч ерткыч турында сөйләгәннәр. Кемдер аны – Шайтан, кемдер – Җен, кемдер – Елан, ә кемдер хәтта Иблис дип атаган... Әмма синоним диярлек бу сүзләрнең асылы үзгәрмәгән, шулай да башны бутамый калмаган. Ә бит кала Шайтан исеме белән йөртелгәч, аның хуҗасы да Шайтан булып чыга, дип исәплиләр экскурсоводлар. Һәм куркудан каның катарлык шундый вакыйга сөйлиләр.

Ул куркыныч Шайтан күрәзәче-багучы булган. Кешеләргә киләчәген әйткән, һәм алар чыннан да дөреслеккә туры килгән. Шуңа да кызыксынучыларның юлы манарадан бер дә өзелеп тормаган. Әмма тормышта һәр нәрсә өчен түләргә кирәк. Бигрәк тә инде – ярдәм сорап Иблиснең үзенә мөрәҗәгать иткәндә. Күрәзәче өчен түләүне Шайтан... матур кызлар белән алган.

Күрәзәче Шайтанны беркем дә күрмәгән, чөнки аның карашы көйдерү үзлегенә ия булган. Шуңа күрә дә үтенечләр һәм теләкләрне манара уемына кычкырганнар, яисә анда керү юлына язып калдырганнар. Шайтан кеше телен белмәгән, шуңа манарадан өскә таба юнәлтелгән ялкын – «әйе» дигәнне аңлаткан, башкача булса – «юк»ны. Ә менә Карлсонның: «Сез иртә белән коньяк эчүдән туктамадыгызмы?» – дигән мәгълүм соравына дөрес җавапны ничек алырга?

Шуңа да карамастан, Алабуга кешеләре патшабикә Екатерина II нең дә, Күрәзәче-Шайтан турында ишеткәч, үзенә граф Орловка кияүгә чыгаргамы-юкмы дип сорар өчен бирегә килүенә ышаналар. Патшабикә корбан итеп кемне китергәндер, риваятьтә бу турыда әйтелми, ә менә җавап алу өчен фавориткасы Дашкова җибәрелгән, һәм ул хуҗабикәсенә тискәре җавап алып кайткан.

Ә шул ук вакытта күрәзәче Шайтанга корбан ителгән кызлар дөньяга коточкыч балалар тудырган. Монысы инде икенче риваять. Шайтанның балалары шүрәле дип аталган. Татарстан халкы бу геройны белә, ә читтән килгәннәргә аңлатабыз – ул кыска буйлы, бөкре, озын бармаклы һәм маңгаенда мөгезе булган әкият герое, урманда үзенә очраган кешене кытыклап үтерергә мөмкин.

Тик шунысы да мәгълүм: әзергә-бәзер булып утыра торгач – хәтта ул матурдан-матур кызлар булса да – бервакыт туясың. Шулай итеп, Шайтан Алабуга байларыннан берсенең кызына гашыйк булган да, аны урлап киткән. Батыр егет Чуранай гына аны коткара алган, ләкин шул чакта үзенең бер аягын югалткан. Икенче версиядә гүзәл кыз поп кызы булган, ә Шайтан поптан аны сорарга шәхсән үзе килгән, ди. Билгеле инде, поп, күренекле булса да, күрекле булмаган бу затка кызын бирергә теләмәгән. Һәм булачак киявенә шундый эш уйлап чыгарган: «Елга ярында чиркәү төзеп куй – кызымны бирәм!» – дигән. Шайтан төне буе эшләгән, тик эшен бетерә алмаган – әтәчләр кычкырган да – чиркәү таралып төшкән... Бу риваятьләрне 1797 елның 27 маенда биредән узган язучы Радищев язмалары гына раслый. Ул, Кама өстендәге манара белән кызыксынып, аның янына күтәрелгән, караган һәм көндәлегенә болай дип язып куйган:

«...Бу бина чыннан да Иблис тарафыннан корылган, бу турыда рухани идарәдә язмалар бар, әлеге ныгытманың чыннан да ниндидер баһадир тарафыннан яулап алынганлыгы, һәм һөҗүм иткәндә аның аягын чабып ташлаганнары, һәм аның әлегәчә чиркәү болдырында саклануы турында да».

АЙ КӘЕФЕ: АЛТЫН

20 майда Краснодарда «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia)-2017 V Милли чемпионат финалы тәгәлләнде. 113 өлкә, 1200 дән артык конкурсант, 1300 эксперт – әлеге хәрәкәттә катнашучы бер генә илдә дә милли чемпионатның мондый киң колач белән үткәрелгәне булмады.

WorldSkills Россия хәрәкәтендә әйдәп баручы төбәкләрнең берсе булган Татарстан күпсанлы сайлап алу сынаулары үткән конкурсантларын тәкъдим итте. Чемпионатта алар коллегалары – айтишниклар, кунакханә тотучылар, ресторан хуҗалары, дизайнерлар һ.б. белән көч сынашты. Республика өчен әһәмиятле булган 59 өлкәдә (чемпионат исемлегендә алар барысы 113 иде) катнашып, Татарстан җыелма командасы мәскәүлеләрдән генә бераз калышты; 31 медаль (шуларның 16 сы – алтын) алып, баллар һәм гомумкоманда зачеты буенча икенче урынга лаек булды.

Нәтиҗәләр татарстанлыларның милли чемпионатларда катнашкан узган еллардагыдан яхшырак. Шулай да күп кенә өлкәләрдә алар республика исәп тоткан дәрәҗәдән ерак әле.

– Без ресурс үзәкләре төзибез, мәгариф оешмаларын җиһазландырабыз. Нәтиҗә булмаса, мондый акчалар тотуның ни мәгънәсе бар? Әле бу Россия чемпионаты гына. Бөтендөнья дәрәҗәсендә без ничек ярышачакбыз? – Белем бирү сыйфатын бәйсез бәяләү һәм WorldSkills стандартлары буенча корпоратив чемпионатлар уздыру мәсьәләләренә багышланган хөкүмәт утырышында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ярышларга хәзерлек өчен җаваплы министрларга әлеге сорау белән мөрәҗәгать итте.

Республика Президентының борчылуы аңлашыла: Татарстан өчен WorldSkills ярышларында җиңүләр – халыкара үрнәк сыйфатының үзенчәлекле билгесе генә түгел, киләчәкнең зур башлангычы да. Машина төзелеше, нефть химиясе, махсус икътисадый зоналар үсеше, туризм өлкәсе, мәгълүмати технологияләр – әлеге динамик рәвештә үсеп килүче тармакларга һәм югары квалификацияле кадрларга ихтыяҗ көннән-көн арта бара.

Бүгенге көндә Россия җыелма командасы октябрь аенда Абу-Дабида (БГӘ) узачак бөтендөнья чемпионатына хәзерләнә.

– Һәр чемпионатта – дөньякүләмме ул, миллиме – без һаман яхшырак чыгыш ясый барабыз, – дип сөйли Профессиональ компетенцияләр үсеше үзәге директоры Эмиль Гобәйдуллин. – Россия җыелма командасының киңәйтелгән составына керүче барлык конкурсантлар soft skills үсеше системасы буенча хәзерлек үтә. Бу – аралашу, стресска каршы торучанлык, оешканлык күнекмәләрен үзләштерү; бөтендөнья чемпионатының кырыс шартларында әлеге сыйфатлардан башка җиңүгә ирешеп булмаячак.

ТЕЛЕМ МИНЕМ – ДУСТЫМ МИНЕМ
ТАТАРСТАН
КАМСКИЙ СУДАК
ТАТАРСТАН
«ТАТАРСТАННЫ» ТАТАР ҺӘМ
РУС ТЕЛЛӘРЕНДӘ УКЫГЫЗ!
Реклама. 16+